PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№11 (311) – НОЯБРЬ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Мегаполиска – вакыт машинасына утырып

Туган тел һәм тарих сәгате

Аутистлар: аралашу юллары

ТУГАН ТӨБӘК ТАРИХЧЫСЫ



16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Роза Мулланурова, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фото: Ната Смирнова

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды:** 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-2848

Басарга кул куелды: 24.11.17

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Екатерина Благодарова,
eblagodarova@inbox.ru, тел. (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ГАДИ БӘХЕТКӘ СӨЕНЕП…

Сүрән ноябрь кичендә моңсу-боек кәефне нәрсә күтәрә ала? Бу сорауга җавапны, күпсанлы сораштырулар күрсәткәнчә, иң бәхетле илдә яшәүче данияләләр төгәл белә икән. Алар яшәгән киңлектә безнекенә караганда күпкә ешрак хөкем сөрүче яман һава торышыннан бу халыкны хюгге саклый, имеш. Безнеңчә итеп әйтсәк, хюгге – һәр кешенең үзенеке генә булган бәхет рецепты ул.

«Татарстан» менә инде 100 ел буена ватанының авыллары һәм салалары буйлап сәяхәт итә. Рус мичләре каршында җылынганы да булды аның, телне йотардай коймак-бәлешләр белән сыйланганы да, күз явын алырдай мендәр тышлары белән тастымалларга гаҗәпләнгәне дә… Ягъни гади дә, җанны иркәләрдәй рәхәт тә бәхет төшенчәсенең ни икәнен ул әле елмаю уята торган Дания сүзен ишеткәнче үк белә иде. «Татарстан»лылар мәктәптә Дания телен өйрәнмәде – менә нәтиҗәсе! Шулай да, сез һәр айда кулыгызга безнең журналны аласыз һәм аның белән кичләрегезгә ямь вә гамь өстәлә. Без шулай бергәләшеп гади генә нәрсәләргә дә сөенергә өйрәнәбез: әби вареньесы белән кайнар чәй эчәргә, яңа пешкән камыр ризыкларының хуш исенә йотылырга, йон оекбашларның җылысын тояргa, мичтәге утынның чатнавыннан изрәргә, яраткан китабыңның яки журналыңның һәр битеннән мәгънә сөзәргә… Хәер, Дания халкы өчен кадерле булган нәрсәләр белән безнең кыйммәтләр бер-берсеннән әллә ни аерылмый да. Аермалы нәрсәләрдән аларда плед бар (бездә шәл) һәм глинтвейн (бездә чәй). Монысы инде – кем нәрсә яратуга бәйле… Без сезгә авыл җирендә дә бик бәхетле яшәргә мөмкин булуын дәлилләп бирә алабыз. Бары шәраб янына устрицы гына куя күрмәгез, алар дөньяны ямьли дип тә ышандырмагыз. Бу без яраткан бәхет түгел… Зиннәтлелек белән ялтыравык байлык арта барган саен хюггеның бәһасе төшә генә. Шуңа да бүген бездә Кужак авылының фәлсәфи әбиләре… гафу, туташлары тапшырган бүләк. Аны хәбәрчеләребез Сарман районыннан алып кайтты. «Татарстан» журналы исә – десертка кала, чөнки нәкъ менә ул тормышның барлык татлы мизгелләрен тагын да татлырак итәргә сәләтле. Һәм… депрессиягә «сау бул» дип кул болгарга да! Ноябрь – дөньядагы иң шәп ай, сизәсезме?!

СЕЗНЕҢ НОЯБРЬ РЕДАКЦИЯСЕ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзүм Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ®



Валерий Скобеев. "Прибытие раненых на Казанский вокзал". 1940нчы еллар.

НОЯБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Иксез-чиксез һава.
«Россиянең һава капкасы» премиясен нәрсә өчен бирәләр

12. Идеаль шәһәр – нинди ул?
Архитекторлар әлеге сорауга җавап таптылар

22. Геройлар: без аларны башкача белә идек.
Уникаль фотопроект турында

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

34. Туган тел һәм тарих сәгате.
Мәктәптә татар теле дәресләре турында – ярты гасыр элек

38. Татар теле:
чыгу юлы бармы?

42. Редакция кухнясы.
Кабактан мантый

46. Спорт.
Татарстанны таныткан бертуганнар...

50. Аутистлар һәм җәмгыять.
Аңлашуга таба беренче адымнар

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

56. Тарих битләре.
Казан ханлыгы

60. Тарихи күргәзмә.
«Тере музей»га рәхим итегез!

63. Хуҗа Хәсән авылы.
Туган төбәк тарихчысы

66. Безнең киштәдә.
Мультикультур әдәбият

72. Әдәбият дөньясы.
«Татарстан»ның әдәби премиясе»ндә җиңүчеләрне кем билгели

78. Сарман рецепты.
Авыл тормышының тынычлыгын эшкуарлык белән ничек бәйләргә

92. Бәхетле тормыш рәвеше.
Татар чигешенә бай авыл

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

27.10

Епископ Тихон (Георгий ШЕВКУНОВ), РФ Президенты каршындагы мәдәният һәм сәнгать советы әгъзасы, мәдәният буенча Патриархлар советы рәисе, – Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН белән очрашуда:

– Хәзер балаларга берьюлы өч-дүрт чит тел өйрәтү модага керде. Мин бу тенденциягә каршы түгел, әмма бала беренче чиратта туган телен камил белергә, аннары гына башка телләрне өйрәнергә тиеш.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

02.11

Константин КОСАЧЕВ, РФ Федераль Җыены Федерация Советының Халыкара эшләр комитеты рәисе, – Казанда, «РФ төбәкләренең тышкы элемтәләре. Татарстан Республикасы тәҗрибәсе» дигән темадагы фәнни-гамәли конференциядә:

– Татарстан Республикасы – чит ил партнёрлары белән элемтәләрне үстерүнең уникаль, чын мәгънәсендә алдынгы, кыю, новаторларча тәҗрибәсе. Һәм бу тәҗрибә, әлбәттә инде, Россия Федерациясенең бүтән төбәкләре өчен дә, гомумән, тулаем илебез өчен дә әһәмиятле.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

22.10

Нино КАТАМАДЗЕ, грузин джаз җырчысы, Казандагы концерты алдыннан:

– Казан – тормыш кайнап торган шәһәр ул. Төрле мәдәниятләр һәм диннәр тыныч һәм килешеп яшәгән башка мондый урынны белмим. Оркестр белән монда беренче генә тапкыр гына килүебез түгел. Һәр сәфәр вакытында үзенчәлекле хисләр белән киләбез. Шәһәрнең мәдәни потенциалы һәм фантастик атмосферасы Җиребезнең бу почмагын искиткеч зирәклек һәм тирәнлек бөркелеп торырдай итә.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

НИ ӨЧЕН Казан һавасының чикләре юк

Фатирдан **НИЧЕК** шәхси микроклиматлы капсула ясарга

Беркем күрмәгән геройлар **НИНДИ** була

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ – «ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!

Яңа язылу кампаниясенә старт бирелде. Безнең элекке дусларыбыз, киләсе яртыеллыкка да язылып, «Татарстан» журналы белән дуслыгын дәвам итә. Әлегә безнең белән булмаганнарга тиз арада безнең «Татарстан» коллективына кушылырга тәкъдим итәбез!

ӘЛКИ РАЙОНЫ

ИГЕЛЕКЛЕ ТРАДИЦИЯ ИГЕЛЕКЛЕ ГАДӘТКӘ ӘВЕРЕЛДЕ

Александр Никошин,
ТРның Әлки муниципаль районы башлыгы:
– Журналга инде 100 яшь диярлек, ә ул елдан-ел үзгәрә, яшәрә бара. Һәр укучы аннан үзе өчен кызыклы, дулкынландыргыч, мәгълүматлы язмалар таба ала. Аны югары дәрәҗәдәге җитәкче дә, авыл җирлеге башлыгы да, шәһәр һәм авыл кешесе дә хаклы рәвештә «үзенеке» дип саный ала. Яшермим, мин башта «Татарстан» яңалыклары белән сайт аша танышам, бу үзенә күрә анонс, интрига. Шулай да журналның типография буяулары аңкып торган яңа санын укыганда аерым бер рәхәтлек кичерәсең. Районның битараф булмаган шактый кешесе республика тормышы белән танышу мөмкинлегенә шушы журнал аша ирешүләре белән уртаклаша. Мин үзем дә ялгыз һәм өлкән яшьтәге кешеләрне яраткан басмаларына яздыру кебек кирәкле һәм мөһим эштән читтә калмыйм. Бу үзенә күрә инде гадәткә кергән бер традициягә әверелде. Игелекле традициягә.

ПИТРӘЧ РАЙОНЫ

КЕМ МӘГЪЛҮМАТКА ИЯ, ШУЛ ВАЗГЫЯТЬКӘ ИЯ!

Эдуард Дияров,
ТРның Питрәч муниципаль районы башлыгы:
– Бүгенге дөньяда мәгълүматка ия булган кеше вазгыятькә дә ия була, хәтта аның барышына да йогынты ясый. Минем күзлектән караганда, бүгенге көндә мәгълүматны укучыга, максатчан аудиториягә оператив ирештерү таләпләренә туры килгән, һәм шулай ук укучыга нигезле тематик аналитика бирү мөмкинлегенә ия булган басмалар актуаль санала.

Миңа «Татарстан» журналы ошый. Аны уку уңайлы һәм рәхәт. Басма үзендә төрле юнәлешләрне берләштерә, дип саныйм. Журнал үзенең укучыларын кызыклы һәм файдалы материаллар белән мавыктыра. Аның «кыздырылган» фактлар артыннан кумавы да сөендерә. «Татарстан»ны рәхәтләнеп укыйм.

Реклама 16+

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2018 елның I яртыеллыгына

«Татарстан» журналына язылу дәвам итә

Реклама 16+

П 2381 **татар телендә** 900 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 900 сум 00 тиен

PRESSA.RU

ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗ **КҮК БИТ УЛ...**

Һәрнәрсә чагыштыруда беленә. Бүген Татарстан башкаласыннан Истанбул, Франкфурт-на-Майне яки Хельсинкига очып барып кайту Екатеринбург, Сочи яисә Уфага самолетта сәфәр кылудан һич аерылмый диярлек. Ә егерме биш ел элек ТУ-154 самолетының Казаннан Истанбулга тәүге очышы чын тарихи вакыйгага әверелгән иде. Гомеренең күп өлешен тимер чаршау артында үткәргән ватандашларыбыз өчен кассадан билет алып чит илгә очу мөмкинлеге чын фантастика булып тоелды.

Республикабызның төп һава капкасыннан башкарылган тәүге даими халыкара рейс меңләгән татарстанлы өчен дөньяга юл ачты. Һәм аэропортның киләчәккә үсеш юнәлешен күп елларга алдан билгеләде. Әңгәмәдәшебез – Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Ленар Сафин әнә шул фикердә.

Фотолар ТР Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгыннан алынды.

– Ленар Ринатович, «Казан» аэропортыннан беренче даими халыкара рейс илнең башка төбәкләре белән чагыштырганда шактый әүвәлрәк – 1992 елның 26 октябрендә ясала. Моңа ни этәргеч булды?

– Әйдәгез, искә төшереп карыйк. 1992 елда аэропорт Татарстан гражданлык авиациясе җитештерү берләшмәсеннән аерылып чыгып, мөстәкыйль авиапредприятие булып эшли башлаган иде инде. Бу аңа маршрут челтәрен үстерү мәсьәләсендә иректе карарлар кабул итәргә мөмкинлекләрне арттырды. Беренче халыкара рейс ни өчен нәкъ менә Истанбулга булырга тиеш, дип карар кылдылармы? Монда болай да һәрнәрсә аңлашыла. дип уйлыйм: Татарстанның Төркия белән сәүдә, икътисадый һәм мәдәни багланышлары ул чакта үсештә иде, бу исә рейсларның җитәрлек дәрәҗәдә пассажирлар белән тәэмин ителәчәгенә ышаныч уята иде. Сүз уңаеннан, вакыт алдан кузалланган мондый хисапның хаклыгын раслады. Белгәнегезчә, Төркия юнәлеше бүген дә «Казан» аэропорты пассажирлары арасында иң популярлардан. Ә беренче даими рейс моннан егерме биш ел элек, 26 октябрьдә, «Татарстан һава юллары» авиакомпаниясе тарафыннан тормышка ашырылды. Әлеге вакыйганың аэропорт һәм, гомумән, бөтен республика өчен әһәмияте бәяләп бетергесез.

– Пассажирларның, Мәскәүгә барып тормыйча, беренче тапкыр туры даими рейс белән чит илгә оча алу мөмкинлеге турында әйтергә телисезме?

– Ул гына түгел. Шул мизгелдән башлап, җитештерү процессына караш үзгәрә башлады – базар мөнәсәбәтләренә күчү керем алуга һәм финанс ягыннан нәтиҗәлелеккә йөз тотуны таләп итте. Республика җитәкчеләре икътисадка бары киң халыкара мәйданда хезмәттәшлек кенә ярдәм күрсәтә алганын ачык аңлый иде. Ә киң фюзеляжлы чит ил лайнерларын кабул итәргә сәләтле, яңа техника белән җиһазланган, заманча аэропорт булмаганда, мондый ниятләрне тормышка ашыру авыр.

Шунлыктан 2005 елга кадәр аэропортны комплекслы үзгәртеп кору проектын тәкъдим итү турында карар кабул ителде. Бу проектка һавадагы хәрәкәт белән идарә итү чараларын яңарту, аэродром зонасын үзгәртеп корып, очып китү һәм төшү полосасын 3750 метрга кадәр озынайту, ягулык салу комплексын, аэровокзалны үзгәртеп кору, йөк комплексы, кунакханә һәм очкычларга хезмәт өчен ангар төзү керә иде.

– Сезнеңчә, «Казан» аэропортының бүгенге үсеш дәрәҗәсе хезмәт күрсәтү сыйфаты, маршрут челтәре, авиакомпанияләрне сайлап алу мөмкинлеге һ.б. ягыннан татарстанлыларның һәм күрше-тирә төбәк кунакларының таләпләренә никадәр туры килә?

– Бүген аэропорт – дөнья стандартларына җавап бирерлек хезмәт күрсәтә торган заманча предприятие. Соңгы өч елда, аэропорт үзгәртеп корылып, Универсиада уздырылганнан соң, «Казан» аэропортында еллык пассажирлар саны якынча 2 миллион кешене тәшкил итте. Югары сыйфатлы хезмәт күрсәтү дәрәҗәсе һәм киң маршрут челтәре булганда гына пассажирлар санын шулкадәр арттырырга мөмкин. Өстәвенә, пассажирлар агымы хәзерге вакытта ышанычлы рәвештә арта гына бара, яңа маршрутлар, авиакомпанияләр ачыла.

Бер үк вакытта Татарстан эчке туризм юнәлешен дә үстерә: республикага карата кызыксыну уятуга игътибар бирә. Җитәкчелек әлеге тенденцияне бик вакытлы тоемлап алды: аэропортны камилләштерүгә игътибарын юнәлтеп, Татарстан хөкүмәте төбәк киләчәген алдан күреп эш итте.

Бу өлкәдә әйдәп баручы экспертлар, Казанның һава капкалары эшен югары бәяләп, аны дөнья аэропортлары арасында берничә тапкыр иң алдынгылар исемлегенә кертте. Агымдагы елда аэропорт дүртенче тапкыр Skytrax консалтинг компаниясенең «Россия һәм БДБ илләренең иң яхшы төбәк аэропорты» премиясенә лаек булды, топ-100 рейтингында ике баскычка югары күтәрелде, аңа өченче тапкыр рәттән «Россиянең һава капкасы» премиясе тапшырылды.

> **“ – Бу өлкәдә әйдәп баручы экспертлар, Казанның һава капкалары эшен югары бәяләп, аны дөнья аэропортлары арасында берничә тапкыр иң алдынгылар исемлегенә кертте.**

– Эре халыкара аэропортлар – авиатранзитлар өчен камил шартлар тудырылган транспорт төене ул. Аларга якын-тирә (һәм алай гына да түгел) шәһәрләрдән килү уңайлы, әлеге аэропортлар төрле калалар белән автобус һәм тимер юл маршрутлары аша тоташкан. Моның иң идеаль үрнәге – Франкфурт-на-Майне аэропорты. Ә бездә «Казан» аэропортына Татарстан калаларыннан, Чабаксар, Киров, Йошкар-Ола яисә Ижевск кебек шәһәрләрдән туп-туры килеп җитү мөмкин түгел. Бу хәл кайчан да булса үзгәрер микән?

– «Казан» аэропортына рейс автобусында, шәхси автомобильдә, такси яки электричкада барып җитәргә була. Шунысы да игътибарга лаек: пассажир Казаннан аэропортка электричка белән нибары 40 сумга 28-30 минутта барып җитә ала. Шулай ук аэропорт аша кайбер шәһәрара автобус маршрутлары да уза.

– Соңгы елларда «Казан» аэропортында берьюлы берничә чит ил авиакомпаниясе рейслар ачты. Татарстан башкаласына мондый игътибар ни белән аңлатыла?

– Әйе, чыннан да, халыкара рейслар турында сүз алып барганда, соңгы елларда Франкфурт-на-Майне, Хельсинки, Прага, Рига, Ашхабад, Джерба, Энфида кебек чит ил юнәлешләре ачылды... Безнең тышкы партнерларыбыз арасында –

PRESSA.RU

Finnair, Czech Airlines, Turkmenistan Airlines, Atlasglobal, airBaltic* һәм башка компанияләр бар.

«Казан» аэропорты белән очрашу шәһәребез һәм гомумән республикабыз турында иң беренче фикерләрне формалаштыра. Ә тәүге бәяләмә ике тапкыр була алмый. Ул гына да түгел, аэропортның тышкы күренешенә карап, потенциаль инвесторлар бөтен республикага бәя бирә. Ягъни хәзерге заман шартларында, Татарстан кебек туристик мөмкинлекләре, сәнәгать, спорт потенциалы булган эре төбәк турында сүз барганда, аэропорт – очып килүнең ахыр ноктасы яки транзит сәфәрнең вакытлы пункты гына түгел. Берьюлы күп пассажирга хезмәт күрсәтергә сәләтле лаеклы аэропорт булу инвесторлар өчен бик зур роль уйный.

– «Казан» юнәлешендә чит ил компанияләренең кайсысы башкалардан уңышлырак эшли?

– Кайсыдыр бер авиакомпанияне аерып күрсәтү кыен, болай чагыштыру дөрес тә булмас иде. Хикмәт шунда, һәр авиакомпаниянең диярлек үз пассажиры бар. Бу – маршрутның үзенчәлекләренә, рейсларның сезонлылыгына, ешлыгына һ.б. га бәйле. Шуны гына әйтеп уза алам: 2017 елда Казан аэропортыннан башкарыла торган даими рейсларның пассажир белән яхшы тәэмин ителүе мәсьәләсендә тотрыклылык күзәтелде.

– Чит ил компанияләренең Татарстан базарына килүе үз авиакомпанияләребезнең үзгәреше өчен ни дәрәҗәдә этәргеч бирә?

– Теләсә нинди авиакомпаниянең базарга керүе гадел көндәшлек мохите формалашуга шартлар тудыра, пассажирга исә авиахезмәт күрсәтүчене һәм сервис дәрәҗәсен сайларга мөмкинлек бирә.

– Ни өчен безнең аэропорттан чит илгә, ә кайчакта Россия төбәкләренә очыш хаклары да Мәскәүнекеннән кыйбатрак?

– Казаннан авиабилет бәяләре Мәскәүдәге очышларныкыннан кыйммәтрәк дигән сүзләрегез белән килешмәс идем. Тарифларны билгеләү процедурасы – гаять катлаулы механизм. Билет бәясе күп очракта пассажир-километр нисбәтенә бәйле, ягъни монда очышлар һәм компаниянең эшчәнлеге өчен таләп ителгән туры һәм өстәмә чыгымнар исәпкә алына. Авиабилет хакына компаниянең коммерция сәясәте дә, классик факторлар – теге яки бу юнәлешкә ихтыяҗ булу, пассажирларның даими хәрәкәт активлыгы да йогынты ясый.

– Ленар Ринатович, әле күптән түгел, күрше төбәккә эләгү өчен, башта Казанан Мәскәүгә очарга, аннан күчеп утырырга туры килә иде. Хәзер Татарстан башкаласыннан төбәкара рейслар географиясе шактый киңәйде, ләкин маршрут картасында «ак таплар» җитәрлек әле. Алар кайчан юкка чыгар икән?

– Эчке маршрут челтәрен киңәйтү, сез телгә алган «ак таплар» санын киметү юнәлешендә актив эш алып барыла. Яңа эчке рейслар исемлегендә Сургут, Салехард, Нарьян-Мар, Яңа Уренгой, Калининград, Ноябрьск һ.б.ны телгә алырга мөмкин. Күргәнегезчә, пассажирларыбызга уңайлы шартларда һәм, башка транспортка күчмичә генә, теләгән урыннарына барып җиту мөмкинлеген елдан-ел күбрәк тәкъдим итәбез.

– Татарстанда бүген ике халыкара аэропорт эшли. Андый көндәшлек кирәкме соң?

– Бүген Татарстан Республикасында оештырылган өч агломерациянең һәрберсе үз аэропорт комплексына ия.

«Бигеш» халыкара аэропорты зурлыгы буенча республикада икенче урында. Ул бер миллион халкы булган, Чаллы, Түбән Кама, Зәй, Алабуга һәм башка калалар урнашкан төбәккә хезмәт күрсәтә. Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерына илебезнең «КАМАЗ» ГАҖ, «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ, «ТАНЕКО» АҖ, «ТАИФ-НК» ААҖ кебек эре-эре предприятиеләре керә, «Алабуга» махсус икътисадый зонасы да шунда урнашкан. Кама инновацион территориаль-җитештерү кластеры җирлегендә халыкара статуска ия аэропорт булу һәм аны камилләштерү кластерның һәм республика икътисадының өметле үсеше өчен зур әһәмияткә ия.

> **“ – Казаннан авиабилет бәяләре Мәскәүдәге очышларныкыннан кыйммәтрәк дигән сүзләрегез белән килешмәс идем.**

– Казан аэропортында кайчан баш партнер авиакомпания барлыкка килер икән?

– Төп, база авиакомпания белән хезмәттәшлек теләсә кайсы аэропорт өчен мөһим. Бу аның маршрут челтәре киңәюгә булышлык күрсәтә. Аэропортларның көндәшлелек сәләте арта, яңа партнерларда кызыксыну көчәя. «Казан» халыкара аэропортының база авиакомпаниясе бар – Татарстанның ЮВТ АЭРО компаниясе. Казанлылар шулай ук «Аэрофлот», «Себер» компанияләре белән дә бик якын партнерлык мөнәсәбәтләрендә тора.

– Төп һава капкабызны 2030 елда нинди итеп күрер идегез? Ул халыкара аэропорт-хаб булырмы?

– Һичшиксез, без пассажирлар санын арттырырга, очышлар географиясен киңәйтергә, халыкара партнерларны күбәйтергә телибез һәм шуңа омтылабыз. Җитештерү тарафына килгәндә, без инфраструктураны алга таба да үстерергә, җитештерү мәйданнарын арттырырга, авиакомпанияләргә һәм пассажирларга тәкъдим ителә торган хезмәтләр исемлеген киңәйтергә планлаштырабыз. ■

Әзерләде:
Әскәр Сабиров

* «Финнэйр», «Чехия авиалинияләре», «Төркмәнстан авиалинияләре», «Атласглобал», «ЭйрБалтик».

Фото авторы : Марина Лысцева

Авиакомпания паркында 9 Boing 737 самолеты. Алар иң югары техник таләпләргә һәм куркынычсызлык буенча халыкара стандартларга җавап бирә. «Нордавиа» – «Россия канатлары» Бөтенроссия конкурсының берничә мәртәбә җиңүчесе һәм дипломанты. 2016 елда авиакомпания 969 мең пассажирны күчергән.

Санкт-Петербургка отышлы итеп һәм комфорт белән очыгыз!

«Нордавиа – төбәк авиалинияләре» авиакомпаниясе түбәндәге расписание буенча Казаннан Boing 737-500 лайнерында Нева буендагы иң матур шәһәргә көн саен даими очышлар оештырды:

Авиабилетлар инде сатыла. Бер якка очыш өчен билетның минималь бәясе 3 850 сумннан башлана. Аңа ягулык өчен җыемнар да керә.

Казаннан «Нордавиа» рейслары белән Санкт-Петербургка гына түгел, Пулково аэропортына төшеп, Россиянең башка кайбер шәһәрләренә һәм Грузиягә дә очарга мөмкин. Агымдагы елның кыш сезонында Пулководан оештырылган «Нордавиа» маршрут челтәре түбәндәге юнәлешләрне үз эченә ала: Архангельск, Воронеж, Нарьян-Мар, Самара, Сыктывкар, Тбилиси һәм Челябинск.

«Нордавиа»ның даими рейсларда «Проездной билет» хезмәте гамәлдә. Әлеге хезмәтне билгеләнгән тариф буенча 3 яисә 5 тапкыр очу өчен бердәм билет итеп рәсмиләштерергә була. Билетта очышлар саны күп булган саен, пассажир өчен очыш отышлырак була бара.

«Нордавиа»ның даими рейсларына авиабилетларны **www.nordavia.ru** сайтында һәм шәһәрегездәге агентлыкларында сатып алырга мөмкин. Сайтта сатып алганда «туда-обратно» юнәлешендәге тарифларга 5%лап ташлама ясала.

Рейларның расписаниесен тулырак белү һәм авиабилетка бронь ясау өчен мәгълүмати-белешмә хезмәте телефонына шалтыратырга кирәк: +7 800 200 00 55

(Россия буенча шалтыратулар бушлай)

Казан – Санкт-Петербург

Рейс номеры	Очып киту вакыты	Килеп җиту вакыты	Атна көннәре	Период
5H538	21:05	23:15	5, 7	29.10.2017 – 29.12.2017
5H538	19:00	21:10	1, 3	30.10.2017 – 21.03.2018
5H538	13:40	15:50	2, 4, 6	31.10.2017 – 24.03.2018
5H538	21:05	23:15	5, 7	05.01.2018 – 23.03.2018

Санкт-Петербург – Казан

Рейс номеры	Очып киту вакыты	Килеп җиту вакыты	Атна көннәре	Период
5H537	17:05	19:25	5, 7	29.10.2017 – 29.12.2017
5H537	15:50	18:00	1, 3	30.10.2017 – 21.03.2018
5H537	10:30	12:40	2, 4, 6	31.10.2017 – 24.03.2018
5H537	17:05	19:25	5, 7	05.01.2018 – 23.03.2018

«Nordavia – regional airlines» авиакомпаниясе («Нордавиа –Төбәк авиалинияләре», яки «Нордавиа» АҖ) 30дан артык Россия һәм чит ил аэропортларына 5N коды астында даими һәм чартер рейсларын башкара.

Реклама.

Фото: csridi.ru

PRESSA.RU

реклама

ELENA FURS
МЕХОВАЯ ФАБРИКА

elenafurs.ru

Москва • Санкт-Петербург • Екатеринбург • Новосибирск • Сургут • Уфа • Архангельск
Казань • Южно-Сахалинск • Нижний Новгород • Нижневартовск • Мурманск • Тюмень

СТЦ «МЕГА» ПРОСПЕКТ ПОБЕДЫ, Д. 141

ЛУЧШИЙ ВЫБОР ШУБ

«ЛУЧШИЕ ШУБЫ РОССИИ» • НАЦИОНАЛЬНАЯ ПРЕМИЯ «ТОВАР ГОДА 2015»
«ЛУЧШИЙ АССОРТИМЕНТ ШУБ» • НАЦИОНАЛЬНАЯ ПРЕМИЯ «ТОВАР ГОДА 2016»

PRESSA.RU

МЕГАПОЛИСКА – ВАКЫТ МАШИНАСЫНА УТЫРЫП

Шулай итеп, кая килеп җиттек әле без? Торак, гафу итегез, кешенең тору урыны, тән тиресе һәм киеменнән кала, өченче кабырчыгына әверелде. Хәзер инде ул өй дә түгел, фатир да түгел, ә үзенең микроклиматы һәм пространствода күчеп йөрү – турыдан-туры һавада – мөмкинлеге булган шәхси капсула. Урнашкан урынны һәм тышкы мохит функцияләре җыелмасын анда яшәүче кеше үзе билгели. Тели икән, шәһәр квартал ландшафтында парк яки шундый ук капсулаларның тоташ архипелагы барлыкка китерә...

Wall Архитекторлар бюросы торак төзелешенең футуристик проекты.

Автор:
Ольга Туманская

Гаҗәпләнмәгез, фантастик романнан өзек түгел бу, ә чынбарлыкта торак төзелеше буенча бәйге проекты... Бу эшне Wall Бюросы архитекторлары башкара, һәм, әйтергә кирәк, ул октябрьдә Татарстанда үткән Беренче Россия яшьләр архитектурасы биенналесының жюри әгъзалары тарафыннан махсус билгеләп үтелде. Безне ул яңа трендлар эзләүгә рухландырды, ихтимал, кайчан да булса алар безне киләчәк шәһәренә китерер.

«БЕЗ ТӘЭССОРАТЛАР БЕЛӘН ЯШИБЕЗ»

– Бүген иң кадерле нәрсә – тәэссоратлар, без шулар йогынтысында яшибез. Идеалдагы шәһәр – ул тәэссоратларның бердәмлеге һәм эстафетасы, ә аерым бер архитектура объектларының масаю ярминкәсе түгел.

Севастополь дәүләт университетының «Территориаль үсеш» фәнни-укыту үзәге җитәкчесе Алексей Комов яшь архитекторларга шушы фикерне җиткерергә теләде. Конференцияләр залы шыгрым тулы: Иннополиска яшьләр, уңайлылыгы белән җәлеп итсен өчен, шәһәр мохите нинди булырга тиеш дигән сорауга җавап эзләү максаты белән Россиянең бик күп төбәкләреннән килгән. Аларның күбесе жюри хөкеменә бүгенге һәм киләчәк кварталларының проектларын тәкъдим итте. Төп таләп – алар бу урында үзләре дә озак еллар буена яшәрлек булсын. Җиңүчеләрнең проекты мине чыннан да тәэсирләндерә: андый җирдә яшәсәң иде ул! Әйтергә кирәк, Мәскәүнең CITIZENSTUDIO архитектура төркеме беренче урынга гына лаек булып калмыйча, Россия Төзелеш министрлыгының махсус бүләгенә дә лаек булды. Аның төп идеясе: бергә була алмастайны – периферия белән үзәкне берләштерү. Әлеге торак кушылмасы читтәге зона белән үзәкнең бөтен өстенлекләрен үзенә җыйган, ә җитешсезлекләрен мөмкин кадәр азайткан. Биредә яшеллек күп һәм һәрвакыт мәшгуль булу мөмкинлеге бар. Тормыш кайный, шул ук вакытта ялгыз калырга да була. Үз мәйданың да бар – иҗтимагый тормыш үзәге, дип әйтик, ә гадәттәге ишегаллары урынына – квартал эчендәге парк. Ишегаллары да калган анысы – алар күршеләрне туганлаштырырга тиешле микропространстволар, ягъни подъезд яннары.

«Сез эшләгәннәр бик тә кызыклы, җәлеп итәләр», – бу сүзләрне финалдагыларның эшләре белән танышканнан соң ТР Президенты әйтә. Уй-кичерешләрен Рөстәм Миңнеханов биенналеда катнашучыларга да җиткерә.

– Без – бер, ә сез икенче дөньяда яшисез. Без яшьләрнең теләкләрен белергә, кайда яшиселәре килүенә колак салырга тиеш. Үзенчәлекле түбәләр, иҗтимагый пространстволар... Безгә дә ошады!

КИРТӘ ҺӘМ КОЙМАЛАРСЫЗ

– Әле җиде ел элек кенә койма белән әйләндереп алынган торак комплексы гадәти күренеш иде, һәм ул психологик дискомфорт тудыра иде, – дип сөйли КДАТУның Архитектура һәм дизайн институты директоры Карина Нәбиуллина. – Бүген, бәхеткә, бу күренеш үзгәрде. Проектны дөрес итеп, уйлап эшләгәндә, койма һәм капкаларсыз да уңайлылык белән куркынычсызлык тигезлеген тәэмин итеп була икән.

Карина Нәбиуллина сүзләренә караганда, шәһәрнең архитектур яктан киләчәге гамәлдәге территорияләрне «яңадан уйлап эшләүгә» турыдан-туры бәйле. Бүген, мәсәлән, мәктәп ишегаллары койма белән әйләндереп алынган һәм аларның вазыйфасы бик тар. Өстәвенә, ул участоклар төзекләндерелмәгән, җитәрлек дәрәҗәдә яктыртылмаган. Бүген андый пространстволарны рациональ файдалану буенча тикшеренүләр алып барыла, һәм киләчәктә алар уен һәм спорт белән шөгыльләнү өчен муниципаль мәйданчыклар булдыру хисабына тарайтылырга мөмкин. Ул мәйданчыкларга мәктәп укучылары да, якын-тирә йортларда яшәүчеләр дә йөри ала.

Әлеге торак төзелешенең төп идеясе – берләштерү мөмкин булмаган периферия белән үзәкне берләштерү. Шушы проекты өчен CITIZENSTUDIO Архитектура төркеме Беренче Россия яшьләр архитектурасы биенналесы бәйгесендә беренче урынга лаек булды.

Фото: Александр Ефремов. Беренче Россия яшьләр архитектурасы биенналесы матбугат үзәгеннән алынды.

PRESSA.RU

Казанның авторлар коллективы проекты Беренче Россия яшьләр архитектурасы биенналесы бәйгесенең финалистлары исемлегенә кергән. Аның шартлары буенча Владислав Куликовский, Арсен Хаиров, Михаил Капитонов һәм Тимур Степанов үзләре яшәргә теләгән торак төзелешен иҗат иткән.

ЙӨРЕРГӘ ЯРАТЫЛГАН ОЧА АЛМАС

Яңа елга тагын бер ай вакыт бар әле, ә мин биенналеның жюри рәисе һәм кураторы Серей Чобанның чыгышы вакытында «Ирония судьбы, или С легким паром!» фильмын искә төшереп утырам.

– Без озак вакытлар «таякчык» һәм «еланнар» парадигмасында яшәдек, 1960нчы еллардан башлап, безнең шәһәрләр барысы бертөрле итеп төзелде. Бигрәк тә өстән караганда күренә бу. Әйтергә кирәк, еш кына архитекторлар пространство проблемаларын нәкъ менә өстән карап хәл итәләр. Алар ниндидер абстракт схемалар төзи, һәм җәяүле турында оныта. Нәтиҗәдә, җәяүле зур, җил уйный торган, детальләргә игътибар ителмичә, яратусыз барлыкка килгән пространстволарны кабул итәргә мәҗбүр була... Хәзерге заман архитектурасына архитектор булмаган кешеләрнең төп дәгъвасы шушы. Шуңа да яңа телдә сөйләшүче яшь белгечләрнең проектлары сөендерде мине.

Бәйгедә катнашырга ил буенча өч йөздән артык гариза килгән. Финалга 29 проект чыккан, шуларның икесе – Татарстаннан.

ҮЛЕМСЕЗЛЕККӘ БЕР ШАНС

– Монда балалар бакчасы бармы?
– Бар.
– Ә мәктәп?
– Мәктәп тә.
– Нәрсә, әллә зират та бармы?
– Ә менә зират юк...

Бу сөйләшү Новосибирск урбанисты Александр Ложкин белән аны Россиянең иң яшь шәһәренә алып баручы машина йөртүче арасында булган.

– Яңа тренд шәйләнә – табигый шәһәр тукымасын тудыру, – дип сөйләде Александр инде биенналеда. – Казанның мондый тукымасы бар, ә менә Иннополиска «төренергә» кирәк әле. Тулы канлы шәһәр мохите төрле буын кешеләрен үз эченә ала, һәм монда үзенең картлары һәм аларның җыелу урыннары барлыкка килүгә, шәһәрнең үлемсезлеккә шансы булачак.

Кайчандыр Ложкин картлар йортын проектлау белән шөгыльләнгән. Башта Европа буйлап йөреп чыккан – анда ничек? Бөекбритания тәҗрибәсе күңеленә хуш килгән: анда картлар йортларын студентлар кампуслары белән янәшә төзиләр икән.

– Шул рәвешле буыннар арасында матур бәйләнеш барлыкка килә, – ди ул. – Картлар өчен бу һәрвакыт аралашуда төрлелек, яшьләр өчен – шуның өстенә акча эшләү мөмкинлеге дә. Шушындый табигый бәйләнешләр шәһәрне тере итә. Аларны алдан күрә белергә кирәк.

«Буыннар бәйләнеше» яки «һәркем өчен пространство» – безне матур киләчәккә илтә торган тагын бер тренд. Шушы ук идеяне

биенналеның финалисты – Казан архитекторы Анастасия Еременко «Оя» проектына нигез итеп алган.

– Хәзерге заман шәһәрен анализлап, мин аның агрессив булуын аңладым, – дип сөйли ул. – Ул әле дә бик күп чикләүләргә, стереотипларга буйсынып яши. Йортлар – таш джунгли, юллар – автомобиль йөртүчеләр өчен генә, гаилә – җәмгыятьнең бер ячейкасы...

Казанның яшь архитекторы Анастасия Еременко үзенең проектын «Оя» дип атаган. Аның төп идеясе – гаилә кыйммәтләрен саклау.

Мин кеше үзе яшәгән кварталны өе итеп кабул итсен дигән бурыч куйдым. Гаилә традицияләрен торгызу һәм күршеләр арасында үзара дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен уңай шартлар тудыруга басым ясадым.

Анастасиянең торак кварталында йортлар биек түгел, алар тоташып, уңайлы ишегаллары хасил итә. Җәяүлеләр сукмагы ял итү зонасына алып бара: сәхнә, фонтан, спорт зонасы – шау-шулы мәйданчыклар нәкъ шунда урнашкан. Җәяүлеләр һәм чаңгыда шуарга яратучылар өчен каенлыгы бар. Бик күпләрнең күңеленә хуш килердәй мунча комплексы үзе ни тора! Ул традицияләрне заманча укылышлы итүче бер билге – фитнесы, спа-үзәге бар: кешенең тәне генә түгел, рухы да чистара торган урын.

– Кварталлап төзү – иске тема, – дип сөйли Анастасия. – Әле совет чорына кадәр үк шәһәрнең үзәк өлеше нәкъ шушы типта төзелгән, әйтергә кирәк, ул кеше өчен бик уңайлы. Әмма тора-бара мондый төзелешнең төп идеясе, ягъни уңайлы шартлар тудыру максаты кешеләрне торак белән тәэмин итүгә кайтып кала. Бүген без яши торган микрорайоннар шуның ачык мисалы.

Мин Анастасиядән киләчәккә алып баруын сорыйм. Утыз елга алга, мәсәлән. Киләчәкне күзаллап карыйсы килә.

– Беләсезме, мохит уңайлы булса, ул үзеннән-үзе озак яши, – ди ул. – Моның өчен безгә көн кадагындагы проблемаларны бүген чишәргә кирәк. Казанлыларның күпчелеге бүген уңайлы шәһәр мохитенә туры килми торган шартларда яши. Без һаман да кешегә карата гуманлы мөнәсәбәттә булмаган биналар төзүне дәвам итәбез. Территорияне максималь дәрәҗәдә тутырырга, бюджетны үзләштерергә – күпчелек төзүчеләрнең максаты шушы бугай. Алга таба нәрсә? Оча торган машиналармы? Бу турыда да алдан уйларга кирәк, микрорайоннарны төзегәндә, гаиләдәге һәркемнең үз автомобиле булыр дип, берәү дә башына китермәгән иде бит... Һәм тагын. Киләчәк шәһәре – кешенең табигать белән бәйләнешләрен өзми торган шәһәр. Аңа тоташ яшел капкач кирәк. Һәм оча торган машиналар да, арканлы җәмәгать юллары турындагы фаразлар моңа берничек тә комачауламый.

КДАТУ магистратурасының икенче курс студенткасы Илсөяр Габдрахманова киләчәктә шәһәрләр биеклеккә үсәчәк, дип фаразлый. Үзенең идеаль шәһәрендә ул вертикаль фермалар кора – шәһәр кешеләре түтәлдән яңа гына өзгән яшелчә, җиләк-җимеш белән туклана алсын өчен.

Фото: Александр Ефремов

КИҢЛЕККӘМЕ, БИЕКЛЕККӘМЕ?

– Берничә дистә еллар элек үк Америка архитекторы Фрэнк Ллойд Райт шәһәрләр горизонталь булачак, һәркемнең үз җире, күршегә кадәр машинада барырга кирәк булачак, дип уйлаган. Әмма чынбарлыкта башкачарак килеп чыкты, – дип сөйли Сергей Чобан. – Без шәһәрдә яшәргә яратабыз. Һәм бүген иң зур сорау: кешене шәһәр тормышының нинди формасы җәлеп итә?

Бу җәһәттән мин аралашкан архитекторларның фикере төрле булып чыкты. Берәүләр киләчәк шәһәрен агрессив түгел, кеше масштабларына ярашлы булырга тиеш, дип күрсә, икенчеләре мегаполислар киңлеккә түгел, биеклеккә үсәргә тиеш, дип фаразлый.

Шундый шәһәр макетын мин КДАТУның TIArch студиясендә таптым. Авторы –магистратураның икенче курсы студенткасы Илсөяр Габдрахманова, үзенең киләчәк шәһәрендә бүгенге Казандагы кебек катгый рәвештә үзәк, торак һәм сәнәгать зоналарына бүленеш юк, дип сөйли. Илсөяр фикеренчә, киләчәктә без күпфункцияле пространстволарда яшәячәкбез. Аларның үзәкләре, аларны әйләндереп алган торак зоналары булачак.

– Пространство ресурслары чикле, алай гына да түгел, шәһәрләрнең киңлеккә җәелүе икътисадый яктан максатка ярашлы түгел, чөнки ул коммуникацияләрнең озынлыгын арттыра, ахыр килеп ягулык һәм вакытка киткән чыгымнар да арта, – ди Илсөяр. – Вертикаль шәһәрдә бөтен функцияләр дә бер-берсенә бик якын урнашкан, шуңа да кешегә эшкә яисә кая да булса ял итәргә барып кайту өчен ерак юллар үтәргә кирәкми.

Аның киләчәк шәһәрендә эко-җитештерү генә түгел, хәтта авыл хуҗалыгына да урын бар! Яшелчә һәм җиләк-җимешне вертикаль фермаларда үстерү каралган – бу исә басу-кырларның мәйданын киметә, логистиканы гадиләштерә һәм шәһәр кешесенә яңа гына түтәлдән өзгән яшелчә-җимешләр ашау мөмкинлеге бирә. Супермаркетлар аша түгел, ә җирле шәһәр фермерларының үз кибетләреннән сатып алып. Искиткеч бит!

Ләкин шәһәрдә күпме азык-төлек үстереп була соң? Бу сорауга Калифорниядә яшәүче бер гаилә күптән җавап тапкан инде. Аларның Urban Homestead дигән шәһәр фермасы нәкъ менә вертикаль бакча һәм яшел диварлар принцибына көйләнгән: дүрт сутый җирдә 400 сортлы яшелчә, җиләк-җимеш үстереп, елына өч тоннага якын уңыш җыеп алалар.

PRESSA.RU

Иллюстрация проект авторыннан алынды

Фотосинтезлаучы махсус үсемлекләр һәм бактерияләр көн яктысын үзенә туплый һәм кояш баегач, кирсенчә, бүлеп чыгара. КДАТУ тәмамлаган Анна Андронова киләчәктә биналарны яктыртуның шундый футуристик концепциясен тәкъдим итә.

«Экологиягә йөз тоту – иң көчле архитектур трендларның берсе», – дип сөйли КДАТУның өлкән укытучысы Резеда Әхтәмова. Үзләренең проектларында яшь архитекторлар – аның студентлары да бу турыда онытмыйлар.

Фото: Александр Ефремов

БУ ЯШЕЛ ДӨНЬЯ

Табигый яктылык чыганаклары гына кулланыла торган сәүдә үзәген күз алдына китерә аласызмы? Хәтта төнлә дә! Шундый футуристик концепцияне КДАТУ тәмамлаган Анна Андронова тәкъдим итә. Аныңча, бинага махсус рәвештә фотосинтезлаучы үсемлекләр һәм бактерияләр урнаштырыла, алар көндез яктылык җыя, ә кояш баюга, киресенчә, яктылыкны бирә башлый. Уйдырма, дисезме? VELUX Халыкара премиясенең мәртәбәле жюри әгъзалары алай дип уйламый. Аннаның «Сүнмәс утлар» дигән эшен алар иң яхшы унлыкка керткән һәм «илһамландыра» дип бәяләгән.

– Экологиягә йөз тоту – дөньяда 1980нче елларда ук барлыкка килгән тренд, әмма бүген аңа торган саен ешрак мөрәҗәгать итәләр, – дип сөйли КДАТУның өлкән укытучысы Резеда Әхтәмова. – Мәсәлән, биналарны табигый җиллләтү системасына ихтыяҗ бар, белүебезчә, кондиционерлар экология өчен зарарлы гына түгел, энергетик яктан чыгымлы да. Һәрнәрсәгә рациональ якын килү – архитектураның эволюцион үсеше ул.

Уйлап кына карагыз әле: атмосферага бүленеп чыккан углекислый газның 40 процентка якыны төзелеш өлкәсенә туры килә. Бәлки, шуңадыр да архитекторлар «яшел» (аны әле тотрыклы дип тә йөртәләр) төзелеш турында ешрак сөйлидер. Ул әйләнә-тирә мохиткә зыян салмый һәм экологик материаллар җитештерү белән куллануны гына күздә тотмый, ә биналарны проектлауны, төзүне, куллану вакытын һәм хәтта гомер циклы ахырында утилләштерүне дә үз эченә ала.

Әлеге «яшел» принципларга таянып проектланган биналар турыдан-туры кешенең сәламәтлегенә һәм хезмәт җитештерүчәнлегенә йогынты ясарга сәләтле. Мәсәлән, тәрәзәдән күзне иркәли торган манзара гына да мәктәп укучыларының һәм студенларның фикерләвен 25 процентка яхшырта, офисларда телефоннар аша эшлекле сөйләшүләрнең нәтиҗәлелеген 12 процентка күтәрә, авыруның дәвалану вакытын (нәтиҗәдә, хастаханәдә яту көннәрен дә) 8,5 процентка киметә. Бу саннарны әле узган ел ук Казанда конференция вакытында Россия Архитекторлар берлегенең Экологик тотрыклылык буенча советы рәисе Александр Ремизов яңгыраткан иде.

– Ничек итеп бу саннарга битараф калырга була инде? – дип мөрәҗәгать иткән иде ул залда утырган чиновникларга һәм архитекторларга. – Әлеге характеристика бер генә төзелеш стандартына да кертелмәгән. Безнең ГОСТлар һәм СНиПлар кешенең минималь ихтыяҗларына нигезләнгән. Монда эшлисе күп әле.

Безгә исә бүген экологиягә йөз тотучы трендның киләчәк шәһәрләре нигезенә салыначагына өметләнергә генә кала.

– Идеаль шәһәр? Күпме генә проект эшләмәсеннәр, берне дә төзегәннәре юк әле. Юк бит ул! Без «Y» буынына дип төзиячәк шәһәр «Z» буыны өчен котылгысыз рәвештә искерергә өлгерә.

МЕГАПОЛИС-ТРАНСФОРМЕР

Италиянең күренекле архитекторы Фабио Панцери Казан архитектура-төзелеш университетына лекция укырга килгән. Мин исә форсаттан файдаланып, аннан киләчәк архитектурасы турында бүген ниләр хәбәр итә, дип сорарга җай таптым.

Сүз уңаеннан, Фабио шәһәрләрне регенерацияләү яклы булуы белән дан тота: ул ташландык биналарга, завод-фабрикаларга җан өрә. Шуңа да аның киләчәк шәһәре трансформер булуына гаҗәпләнәсе юк.

– Минемчә, биналарның кулланылышында һәм аларның билгеләнешендә сыгылмалылык барлыкка килергә тиеш, ягъни алар кеше ихтыяҗларына бәйле үзгәрәләр, – ди ул. – Мисал өчен, бина торак буларак төзелә, соңыннан җиңел генә кунакханәгә әверелә. Минемчә, әлеге сыгылмалылык – киләчәк архитектурасының бер ягы, һәм ул якын арада күренә башлаячак.

Фабио Панцериның җавабы, миңа калса, биенналеда «Северин Групп» компаниясенең идарәче партнеры Александр Балабинның яшь архитекторлар алдында ясаган чыгышы белән аваздаш.

– Идеаль шәһәр? Күпме генә проект эшләмәсеннәр, берне дә төзегәннәре юк әле. Юк бит ул! Без «Y» буынына дип төзиячәк шәһәр «Z» буыны өчен котылгысыз рәвештә искерергә өлгерә. Бу шәһәрне проектлап булмый – аның «скелетын» гына проектта күрсәтергә була, дигәнне аңлата. Аннан соң төзәткәләп, бала кебек тәрбияләп торырга.

«ШАТЛЫК БУЛСЫН ӨЧЕН!»

Мөгаен, киләчәк шәһәре турында анда яшәячәк кешеләрдән башка гына фикер йөртү дөрес түгелдер. Аның нинди булачагы турында «АРХИБАЛАЛАР» проектының «А дәрәҗәсендәге архитектура» остаханәсендә шөгыльләнүче балалар белән хыялга бирелеп алдык. Мин килгәндә, алар үзләренең футуристик макетларын төгәлләп яталар иде.

– Иң гаҗәбе: балалар үзләренең биналарында без күреп гадәтләнгән классик формаларны кулланмый, – дип аңлатып китә остаханәнең кураторы Айгөл Хәсәнова. – Аларның фикерләве стереотиплар белән богауланмаган, һәм аларның иҗаты бик кызыклы.

Башка сыймаслык биналар, биек юллар һәм әллә ничә функциясе булган футуристик технопарклар – бәләкәй архитекторларның шәһәре теләсә кайсы олы кешене таң калдырырлык. Менә эшкә нокта куелды һәм без хыялга бирeләбез.

– Киләчәк шәһәрендә махсус чистарткычлар булуын телим – һәм сулар һава һәрвакыт чиста булачак! – дип хәл итә экологик бурычны Гоша. – Агачларның гына көче җитми, аларга ярдәм итәргә кирәк.

– Җәяүлеләр өчен юллар җирдә генә түгел, өстә дә булачак, ә оча торган машиналар өчен йортларның түбәләрендә парковка урнашачак, – дип тагын бер проблеманы хәл итә Женя. – Шунда ук махсус заряд җыю җайланмалары да куела, машиналар электр энергиясенә эшләячәк – алай табигать азрак пычрана.

– Утыз елдан соң миңа кырык бер яшь булачак! – дип саный Милан. – Минем балаларым өчен идеаль мәктәп – дүрт катлы, ләкин безнеке кебек гадәти түгел, мәсәлән, өчпочмаклы – анда керәсе килеп торырга тиеш. Алар төрле төстә – күңелле булсын өчен! Мәктәпкә яр буе кебек җәяүле зона илтә. Барасың: бер якта – кибет, икенче якта – ипи пешерәләр. Бөтен җирдә матур сыннар, ләкин билгеле кешеләрнең һәйкәлләре түгел, мәсәлән, тамам-тамам дип торган тамчы. Әйләнә-тирәдәге табигать ничек бар, шулай: аны туракларга кирәкми.

Малайлар дәррәү көлеп җибәрә. Миңа калса, әйбәт кенә шәһәр килеп чыгасы. Ә сезнең шундый шәһәрдә яшисегез киләме?

Түбәләрдәге машина кую урыннары, шәһәр һавасын чистартучы җайланмалар, шатлык хисе генә уята торган мәктәпләр – «А-дәрәҗәсендәге архитектура» остаханәсенең укучылары хыялындагы шәһәр шундый.

Фото: Александр Ефремов

PRESSA.RU

Фото «Татинвестгражданпроект» ДУП оешмасы архивыннан алынды. Реклама.

РФ Хакимияте Рәисенең урынбасары Ольга Голодец, «Татинвестгражданпроект» ДУП генераль директорының беренче урынбасары Тимур Ажимов, Россия Архитекторлар берлеге президенты Николай Шумаков, генераль директорның урынбасары – «Татинвестгражданпроект» ДУП баш архитекторы Максим Быков.

«ТАТИНВЕСТГРАЖДАНПРОЕКТ» ДУП ПРОЕКТЛАРЫ
BUILD SCHOOL 2017* БЕРЕНЧЕ ХАЛЫКАРА КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

2017 елның 26–29 сентябрьләрендә Мәскәүдә Build School 2017 Беренче Халыкара күргәзмәсе уза. Күргәзмәдә тәкъдим ителгән экспозицияләр балалар бакчасы һәм мәктәпләрне проектлаштыру, төзү, модернизацияләү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү буенча 50 компанияне берләштерә.

Татарстан күргәзмәдә «Татинвестгражданпроект» ДУП, ягъни республиканың баш проект институты аша тәкъдим ителгән иде. «Татинвестгражданпроект» ДУП генераль директорының беренче урынбасары Тимур Ажимов белән «Татинвестгражданпроект» ДУП генераль директоры урынбасары – «Татинвестгражданпроект» ДУПнең баш архитекторы Максим Быков докладлар белән чыгыш ясады һәм яңа заман Казан мәктәпләре белән таныштырды. Алар барысы да проектлаштыруга яңача карашны күрсәтә.

Күргәзмә кысаларында Россиянең смотр-бәйгесе дә булып узды, ул бәйгедә Россия, Бөекбритания,

*Мәктәпләр төзелеше 2017

«Татинвестгражданпроект» ДУП баш инженерының метрополитенны проектлаштыру буенча урынбасары Сергей Бакин, Россия Архитекторлар берлеге президенты Николай Шумаков.

> **Николай Шумаков:**
> **– Архитектура матур булса, кеше үзе дә тулы канлы һәм җанлы тормыш белән яшәячәк.**

Голландия, Испания һәм Латвия авторлар коллективыннан 60 эш тәкъдим ителгән иде.

Бәйге нәтиҗәләре буенча «Татинвестгражданпроект» ДУП эшләгән өч проект дипломга лаек дип табылды:

- «Казан шәһәре, Федосеевская урамы, 52 йорт адресы буенча урнашкан Халыкара Мәгариф үзәге» **объектын проектлаштыру практикасы өчен**;
- «Казан шәһәре, Хөсәен Мәүлетов урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан Мәгариф үзәген» **төгәл проектлаштыру һәм архитектура-планировка карары өчен;**
- «Казан шәһәре «Седьмое небо» микрорайонында урнашкан гомуми белем бирү мәктәбен» **рациональ һәм тәэсирле архитектура-планировка карарлы типик проекты өчен.**

Build School 2017 дипломы артында нинди казанышлар тора? Бу сорауга «Татинвестгражданпроект» ДУП генераль директорының беренче урынбасары Тимур Ажимов җавап бирә:

– Мәсәлән, «Седьмое небо» микрорайонындагы 181 нче мәктәп Россия Төзелеш министрлыгы типлаштырылган документация реестрына кертелгән кабатлап башкару проекты буенча төзелде һәм югары нәтиҗәле дип табылды. Бүгенге көндә ул Казан шәһәре һәм Татарстан буенча уңышлы тормышка ашырылып килә, алай гына да түгел – Россия Федерациясе территориясенең берничә субъектында да.

Шуны да әйтергә кирәк: Россия Төзелеш министрлыгы типлаштырылган документация реестрында безнең мәгариф учреждениеләре проектлары күпләп кергән: 100, 500, 560, 800 һәм 1224 кешелек мәктәп һәм 50, 80, 120, 140, 220 һәм 260 урынга исәпләнгән балалар бакчалары, шулай ук 50, 100, 200 һәм 300 кешегә исәпләнгән авыл клублары. Әлеге проектлар бөтен Россия буенча актив рәвештә гамәлгә ашырылып килә.

Дипломнар белән бергә без яңа идея дә алып кайттык: Татарстанда да шундый ук эш башкарырга. Максатыбыз – коллегалар белән мәгариф пространствосын оешты-

PRESSA.RU

«Седьмое небо» микрорайонындагы гомумбелем бирү мәктәбе.

BUILD SCHOOL PROJECT 2017

ДИПЛОМ

СОЮЗА АРХИТЕКТОРОВ РОССИИ

Фото «Татинвестгражданпроект» ДУП оешмасы архивыннан алынды. Реклама.

Ольга Голодец:
– Әгәр элегрәк төп максатыбыз мәктәптәгечә яшьтәге балалар өчен яңа урыннар булдыру дип саналса, хәзер мәктәп укучылары өчен принципиаль яңа пространство хасил итү – төп өстенлек.

руның заманча тенденцияләре белән бүлешү.

– Сезнең оешманың бүгенге көндә эшләнә торган ничаклы мәгариф учреждениесе проекты бар?

– Хәзер без республика өчен 6 мәктәп проектлаштырабыз, шуларның 2се – Казанда. Моннан тыш, ТР буенча 36 мәктәптә ремонт эшләрен алып барабыз.

«Татинвестгражданпроект» ДУП генераль директоры урынбасары – «Татинвестгражданпроект» ДУП баш архитекторы Максим Быков җавап бирә:

– Build School 2017 сезнең өчен нәрсәсе белән файдалы булды?

– Без барыбыз да мәгариф системасы, мөгаллимнәрнең компетентлыгы, белем бирә торган уку йортларының матди-техник базасы һ.б. шуңа бәйле мәсьәләләрне ишетергә, чишәргә күнеккәнбез. Ә менә бүгенге мәктәпләрнең архитектурасы мәсьәләсе ул дәрәҗәдә киңколачлы тема кебек каралмый, шуңа аны системалы рәвештә беренче күтәреп чыгулары.

Түгәрәк өстәлләрнең берсе проект эшләренә заманча психология, социология, урбанистика, экология казанышларын интеграцияләү проблемаларына багышланган иде. Мисал өчен, сөйләшү барышында мәктәпләрнең фасадлары һәм интерьерларындагы төсләр буенча сорау килеп туды: «Нишләп әле без, өлкән кешеләр, балаларга нәкъ менә шушы төсләр ошавын хәл итүне үз өстебезгә алабыз?» – дигән фикергә килдек. Асылда бит баланың психологик тынычлыгы белән төсләрнең үзара ярашуы мәсьәләсе шактый бәхәсле һәм катлаулы мәсьәлә. Шуңа да «төсләр өермәсе», бигрәк тә кече сыйныфларда, артык хупланмый. Ул бик исәпләнгән күләмдә генә булырга тиеш. Интерьер үзе дә сак якын килүне таләп итә.

– Заманча мәктәпне проектлауның төп үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?

– Соңгы 20 ел эчендә чит илләрдә шундый практика бар – анда яңа мәктәпләрне төзергә исеме дөнья күләмендә танылган архитекторлар алына. Бу, әлбәттә, мәгариф учреждениеләренең абруен да арттыра, Көнбатыш җәмгыятендә аларга зур әһәмият бирелүе хакында да сөйли. Без әлеге төзелеш тәҗрибәсен өйрәнәбез, позитив моментларны үзләштерәбез, шулай ук хезмәттәшлеккә дә чыгабыз.

Әйтергә кирәк, күп еллар дәвамында мәктәп идеология тарафыннан анык бурычлар йөкләнгән һәм бил-

геле бер белем бирү сыйфатын күздә тоткан «фабрика» иде. Әмма без барыбыз да яхшы хәтерлибез: ул төр мәктәптә индивидуальлек белән шәхси мөнәсәбәтләр беренче планга чыкмады. Бүгенге мәктәп, киресенчә, баланың үзенә генә хас сыйфатларын ачуга зур игътибар бирә, аның потенциалын күрүне әһәмиятле саный, шулай ук сәләте белән кешелек сыйфатларын үстерүне дә үзәккә куя. Яңача якын килү аша чит ил компаниясе белән уртак проектта без мәктәпне башка ракурстан күрергә омтылыш ясап карыйбыз.

Мисал өчен, Федоссевская һәм Мәүлетов урамнарындагы мәктәпләр проектларын гына алыйк. Аларны без Fielding Nair International* компаниясе архитекторы Джей Литман (АКШ) белән берлектә башкарып чыктык.

Эчке пространствоны эшләгәндә, ни дә булса белән шөгыльләнүче балаларның ул эшне ирекле рәвештә башкарасылары килүен дә, шөгыльләрнең еш алышынып торуын да исәпкә алдык. Халыкара мәктәп биналарында (Федосеевская урамы, 52 йорт, Мәүлетов урамы, 5 йорт) төрле бүлмәләр белән уратып алынган зур зал планировкасы өстенлекле дип табылды. Шул рәвешле уку өчен дә, уен өчен дә бердәм пространство барлыкка килде. Күренеп тора: формасы һәм эчтәлеге буенча күптөрлелеккә ия булган планировка балаларда уңай тәэсирләр уята, ә менә төссезрәк, бертөрлерәк мохит, киресенчә, укуга булган мәхәббәтне дә, мәктәпкә атлыгып торуны да сүлпәнәйтә. Заманча мәгариф учреждениеләренең фокусында – балаларның психологик комфорты, коллектив һәм динамик шөгыльләр өчен пространство булдыру, шулар белән бергә, баланың үз индивидуаль шөгыльләре өчен дә уңай булырдай тыныч урыннарны исәптә тоту.

Әлеге заманча идеяләрне тормышка ашыру өчен бер ел элек дизайн һәм архитектура бүлеге оешты, аның төп бурычларыннан берсе – Россиядәге генә түгел, ә чит илләрдәге дә алдынгы тәҗрибәләрне барлау, өйрәнү, үзләштерү, шулай ук безнең проект

«Татинвестгражданпроект» ДУП
тел.: +7 (843) 236-08-12
факс: 236-06-61,
эл. почта: tigp@mi.ru
сайт: www.tigp.ru

Мәүлетов урамындагы мәктәп.


BUILD SCHOOL PROJECT 2017
ДИПЛОМ

Федосеевская урамындагы мәктәп.


BUILD SCHOOL PROJECT 2017
ДИПЛОМ

* Филдинг Нэйр Интернешнл

Фото: Ната Смирнова (бэкстейдж), Ольга Тупоногова-Волкова (фотопроект).

ГЕРОЙЛАР:

без аларны башкача белә идек

Безнең каһарманнарыбыз – нинди алар? Сугыш кырында түгел, тыныч урамда, хәрби форма киеп, орденнар таккан килеш түгел, бәлки көндәлек киемнән. Трибунада һәм Җиңү бәйрәмендә түгел, ә янәшәбездә, кул сузымында гына? Казанда «Буыннар хәтере» хәйрия фонды оештырган фотосессия – әлеге йөзләргә тутырып карау, аларны аңлау, тою өчен уникаль мөмкинлек ул...

Йәгез, таныш булыгыз: Советлар Союзы Герое, Бөек Ватан сугышы ветераны Борис Кузнецов. Иптәшләре белән әфган әсирлегеннән самолетта качкан Россия Герое, пилот Газинур Хәйруллин. Чечен сугышында катнашкан Россия Герое Александр Супонинский. Бөек Ватан сугышы ветераны, десантчы Павел Клетнев. Татарстаныбыз каһарманнарын фэшн-фотограф Ольга Тупоногова-Волкова үз сурәтләрендә менә шулай мәңгеләштергән.

ПРОЕКТ ТУРЫНДА

«Россия Геройлары: без аларны башкача белә идек» фотопроекты – «Буыннар хәтере» хәйрия фонды акциясе. Танылган фотографлар белән берлектә фонд Советлар Союзы Геройларын һәм Россия Геройларын тамашачыга күнегелмәгән образларда – орден-медальләрсез тәкъдим итә. Татарстанда проектта катнашучыларны fashion-фотограф Ольга Тупоногова-Волкова сурәткә төшерде. Моннан нәрсә килеп чыкканны ноябрьдә үк күреп булачак – Россиядәге башка шәһәрләр белән бер үк вакытта Казанда да фотокүргәзмә ачылачак.

Автор:
Ольга Туманская

PRESSA.RU

ГЕРОЙЛАР: *без аларны башкача белә идек*

ЯУЛАП БУЛМАСЛЫК БИЕКЛЕК

Александр Супонинский – бик кырыс репутацияле легендар шәхес. Ул беркайчан да диярлек интервью бирми, шунлыктан аның ниндирәк кеше булуын белүчеләр аз. Александр – чечен авылы Улус-Керт янындагы 776 нчы биеклекне алу өчен барган атаклы сугышта катнашучы, легендар 6 нчы ротаның могҗиза белән генә исән калган алты сугышчысының берсе. Бу рота турында фильмнар төшерәләр, китаплар язалар, аның сугышчыларын панфиловчылар һәм спартачылар белән чагыштыралар. Ул чакта, 2000 елның 29 февралендә, Шамил Басаев, Хаттаб һәм Әбү әл-Вәлиднең ике мең кешелек бандасына Дагыстанга юлны ябып, туксан солдат һәм офицер үзләре ут астында кала…

Шул сугышта күрсәткән батырлыгы өчен Александр Супонинскийга Россия Герое исеме бирелә. Ул чакта ул – зәңгәр беретлы яшь егет. Хәзер – төз сынлы, мәһабәт кыяфәтле һәм әле һаман яшь ир-ат. Без бик аз – берничә минут кына сөйләшәбез, мин: «Сезнең өчен бу сугыш нәрсә ул? Шәхсән сезнең үзегез өчен…» – дип сорарга өлгерәм.

– Вакытны кире кайтарасы иде, ротадагы сугышчыларыбызның барысы да исән калсын иде. Һәм бернинди мактаулы исемнәр дә кирәкмәс иде! Тик инде аларны кире кайтарып булмый…

Ул ашыгып барыбызга да рәхмәт әйтә, хушлашып, машинасына юнәлә. Проект авторлары иркен сулыш ала – барысы да барып чыкты, «Супонинский» биеклеге алынды…

PRESSA.RU

ГЕРОЙЛАР: *без аларны башкача белә идек*

КҮЗЛӘРЕНДӘ – КОЯШ

Ул «Кандагар» фильмын караргa яратмый. Ә бит анда аның образын хәзерге заман Россия киносының иң бруталь актеры Владимир Машков чагылдыра. Юк, Газинур Хәйруллинның картинага әллә ни дәгъвасы юк. Монда эш башкада.

– Танышлар шылтыратып: «Сезнең турында фильм бара! Карыйсыңмы?» – дип сорыйлар. Юк, карамыйм. Кыен миңа.

Казанның «Аэростан» компаниясенең Ил-76 самолеты экипажын талиблар Әфганстанга төшәргә мәҗбүр иткән көннән соң инде 22 ел үткән. Ә аннары – автомат көпшәләре астында бер елдан артыгракка сузылган әсирлек, һәм экстремаль шартларда, критик түбән биеклектә, үз самолетларында ук илгә качу… Кандагар кояшы аңа рәхимсез була. Әмма бүген инде Газинур Хәйруллин шулкадәр самими елмая ки, гүя бу кояш үзе аның күзләрендә чагыла.

Стилист һәр каһарман өчен киемне җентекләп сайлый. Зәңгәр пиджак, чалбар, ботинкалар – Газинур Хәйруллинның яңа образы бер үк вакытта кырыс та, уңайлы да. Ә менә аның үзенә төшерү мәйданчыгында рәхәт түгел. «Бу минем өчен бөтенләй яңа тәҗрибә!» – ди ул соңыннан.

– Әйдәгез, кулыгызны берәр ничек куйыйк әле, – ди Ольга. Алар аңа комачаулый кебек. Очучы Хәйруллин янып тишелгән полотно фонында басып тора, тишекләрдән зәңгәр күк йөзе күренә.

– Пиджак кыскарак, – дип, һәркемне үзенең кояшлы елмаюы белән җылытып ала Газинур.

Фотога төшкәннән соң җирле телеканалда эшләүче коллегаларым Хәйруллиннан аның качкан чакта нинди хисләр кичерүен сораша. «Ирек! Бу ирек хисен берничек тә аңлатып булмый…» Минем соравым исә – тоткынлык турында.

– Ул чакта, әсирлектә, бөтен гомеремне күздән кичердем, – ди Россия Герое. – Нәрсәне дөрес эшләмәдем, кемнәрне үпкәләттем… Аннан алып чыккан иң зур нәтиҗә – тормышка мөнәсәбәтемне үзгәрттем. Аның һәр минутының кадерен белергә кирәк! Һәм мин кадерен беләм дә. Көн саен, уянгач, урамга чыгам, шәһәр буйлап барам һәм сөенәм.

PRESSA.RU

ГЕРОЙЛАР: *без аларны башкача белә идек*

ДӘҮЛӘТ ӘҺӘМИЯТЕНДӘГЕ КЕШЕ

Борис Кузнецовны фотога төшерү моның өчен иң кулай урында – Борис Кузнецов исемендәге кадетлар интернат-мәктәбендә бара. Мөгаен, бу проектның иң күңелле мизгелләредер, чөнки Татарстандагы бердәнбер исән Советлар Союзы Героен малайлар урап алган. «Буыннар хәтере» фондының башкаручы директоры Екатерина Круглова әйтүенчә, ун кадет булырга тиеш булган, тик проектта катнашуга җидесе генә лаеклы дип табылган. Бөтен нәрсәдә тәртип булырга тиеш – һәм моның белән бәхәсләшеп булмый. Әмма балачак барыбер үзенекен итә – малайлар үзләренең малай икәнен бер дә онытмый шул.

Хәер, Кузнецовның моңа ачуы чыкмый – чөнки аның үзен дә дәрте, кыюлыгы, энергиясе иң кыен шартларда да әллә ничә тапкыр коткарып калган: Ленинград өчен сугышканда да, пуля һәм снарядлар яңгыры астында Днепрны кичкәндә дә, Украина, Молдавия, Румыния, Польшада дошманны тукмаганда да, Берлинны алганда да.

Аның әле бүген дә дәрте ташып тора. Проектта катнашырга шундук ризалыгын биргән.

– Яшьләргә кагылышлы мәсьәлә булса, мин беркайчан да баш тартмыйм. Мин бит инде гади кеше генә түгел – мин дәүләт кешесе. Герой исеме мәҗбүр итә. Камералар утына да күнеккән инде мин. Үземне пропагандист дип саныйм – җаным белән дә, йөрәгем белән дә яшьләргә үземнең Ватанга мәхәббәтемне тапшырырга тырышам.

Ольга төшергән фотоларның берсе Герой сүзләренә менә дигән дәлил булып тора. Анда Борис Кузнецов янәшәсендә аның эшенең турыдан-туры дәвамчысы – кадет мәктәбе укучысы, оныгының улы Алексей басып тора.

PRESSA.RU

ГЕРОЙЛАР: *без аларны башкача белә идек*

МЕДАЛЬЛЕ ДЖЕНТЛЬМЕН

Кич. Казансуның Кремль яр буенда фото төшерүгә соңгы әзерлек бара. Локация урыны – балалар каруселе. Операторлар утны, аппаратураны көйли, әз булса да җылыныр өчен кайнар каһвә эчеп куя…

Һәм менә ашыкмыйча гына ул пәйда була. Элеккечә үк төз сынлы, яңгыравык каты тавышлы, бик күңелле кеше. Павел Кузьмич Клетнев үзе белән бөтен әйләнә-тирәне тутыра кебек. Бөтен игътибар аңа – Татарстанның иң карт десантчысына! Зәңгәр берет, саклагыч форма, ә бүләкләре күкрәгенә көчкә сыйган.

– Без сезгә фотога төшү өчен кием алып килдек, – ди, сәламләшүдән соң эшкә күчеп Екатерина.

– Ә минеке ошамыймыни? – дип көлә ул. Әмма үзен озак үгетләргә туры килми. Ул сынауларга һәрвакыт әзер. Сынаулар – ул үзе. Былтыр 92 яшьлек Кузьмич, сугышчан яшьлеген искә төшереп, 4000 метр биеклектән парашют белән сикергән бит!

Ул Ленинград блокадасын өзүдә катнашкан, Венгрия, Австрия, Чехословакияне азат иткән… Үзенең сугыштагы батырлыклары турында Павел Кузьмич мактанмыйча гына сөйли: «Солдат солдат инде ул! Немец үтермәде, ачлыкка бирешмәдем…» Бары шул гына.

Тик кинәт шаян десантчы урынына яныбызга купшы европалы килеп чыга – модалы пальто, киң шарф… «Джеймс Бонд!» – дип, ах итә кемдер артта. «Джентльмен!» – дип сокланам мин. «Сезнең алдыгызда яшь егет!» – дип бәяли үзенең яңа образын Павел Кузьмич үзе.

Грим салуны да тыныч кичерә, фотога төшү өчен урынны да дөрес сайлый. Ольганың «Бик шәп!» диюеннән беренче кадрларның ук яхшы чыгуы аңлашыла. Карусель – чыннан да тынычлык символы, һәм бу фон Клетневка бик килешә. Үзенең кайнап торган энергиясе һәм тормыш сөючәнлеге белән ул теләсә кемне илһамландырырга сәләтле.

«Ә хәзер бик еракка карап торган булыгыз», – дип үтенә Ольга, һәм көтмәгәндә Павел Кузьмич карашын миңа төби. Безгә тынычлык бүләк иткән каһарманнар буыныннан булган бу Героебызга мин ихластан елмаям.

PRESSA.RU

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Как ясау осталары
Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Язмыш **НИЧЕК** кабатлана

Иң файдалы яшелчә **НӘРСӘ**

КЕМНӘР Татарстанны бөтен дөньяга таныттылар

Аутистларны җәмгыятькә **НИЧЕК** яраклаштырырга

КПСС өлкә комитеты секретаре, 1957 ел



Камил Фасиев (1919–2005 еллар).

Совет чорының күренекле дәүләт һәм партия эшлеклесе, КПСС Татарстан өлкә комитетының фән һәм мәдәният бүлеге җитәкчесе (1953–1957), КПСС Татарстан өлкә комитеты секретаре (1957–1959), Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Рәисе (1959–1960), РСФСР Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары (1959–1963), СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында директор (1960–1963), Казан дәүләт университеты доценты, профессоры (1963–1984).

ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ **ТАРИХ СӘГАТЕ**

Замандашларыбызга Камил Фатих улы Фасиев исеме танышмы икән? Күпләрнең, мөгаен, аның хакында ишеткәне дә юктыр. Югыйсә бу кеше үз вакытында республика тормышына гаҗәеп зур йогынты ясаган бит. Камил Фасиев үткән гасырның урталарында ук татар теленең юкка чыгу куркынычы, аның рәсми куллану, эш кәгазьләре, фәнни бәхәсләр даирәсеннән «чыгарылуы» турында ачыктан-ачык әйтергә батырчылык итә...

Таныш картина, әйеме? Бүген бик күп бәхәсләр тудырган вазгыять –татар телен өйрәнү, аны мәктәптә уку-укыту, телнең статусын саклау белән бәйле хәлләр, – баксаң, болар барысы да республикабыз тарихында булган икән инде... Тарих сәгатенең теле кай якка таба әйләнеп китте соң – алгамы әллә артка, 1950нче еллар ахырынамы? Камил Фасиевнең укучыларыбыз игътибарына тәкъдим ителгән «Үткәннәрне искә алып»* китабы бу сорауга җавап табарга булышыр? дип уйлыйбыз.

БОЗ КУЗГАЛДЫ

«Декада (1957 елның май ахыры–июнь башында Мәскәүдә зур уңыш белән узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы һәм партия өлкә комитетының шуңа багышланган бюро утырышы турында сүз бара. – Н.Ә.) нәтиҗәләре турында сөйләшү киң колач алды. Кайбер иптәшләр белән бәхәсләшеп, фикер алышып, мин бер тезисны яклададым: милли мәдәниятнең теләсә кайсы өлкәсендәге уңышлар һәм кимчелекләр мәктәп белән тыгыз бәйләнгән. Татар мәктәбе гаять тирән кризис кичерә. Ашыгыч чаралар кабул итмәгәндә, берничә елдан татар мәктәпләре бөтенләй юкка чыгачак, туганлык җепләрен югалткан, ата-ана телен белмәгән, милли шигърияттә, прозада, музыкада, драматургиядә шедеврлар иҗат итәргә сәләтсез, татар классикасы әсәрләре белән таны-

* Русчадан тәрҗемә. Фасиев К.Ф. «Вспоминая прошедшее». Казан, КДУ нәшр., 1999 ел.

1

2

шу мөмкинлегеннән тулысынча мәхрүм ителгән буын үсәчәк. Әлеге Декадада һәркемдә соклану уяткан мәдәни кыйммәтләрне арттырырга телибез икән, иң әүвәл эшне мәктәптән башларга кирәк».

С.Д. Игнатьевның (КПСС Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре – Н.Ә.) йомгаклау сүзе шактый өметле, хәерхаһлы булып чыкты. Ул татар мәдәнияте уңышларын мактау сүзләре белән искә алды, татар культурасының Урта Азия, Казахстан һәм Башкортстан халыклары мәдәниятенә уңай йогынты ясавы турында шәхси күзәтүләре нигезендә белүен ассызыклады. Игнатьев милли мәдәнияттәге тискәре тенденцияләргә борчылу белдергән чыгышларны хуплады, һәм проблемаларны хәл итү өчен анык тәкъдимнәрен җиткерде.

«Үзәк комитеттагы иптәшләр белән киңәшләшеп алырбыз. Ә сез җентекле доклад әзерләгез һәм бөтен мәдәният комплексын үстерү буенча эшләрнең төгәл планын төзегез», – дип күрсәтмә бирде С.Д. Игнатьев.

Тиздән план төзелеп, расланган иде. Без укытучылар, халык мәгариф бүлекләренең мөдирләре, язучылар, галимнәр, партия, профсоюз һәм комсомол хезмәткәрләре белән очрашулар уздырдык. Декабрь башында республиканың сәнгать әһелләре белән җыелыш үтте. Ул вакытта зыялыларның кайберләре турыдан ярып салды: партия һәм хөкүмәт бөтен илне руслаштыруга илткән сәясәт алып бара һәм милли мәктәпләрне ябу максатын тормышка ашыра; Татарстан идарәчеләре, Мәскәүгә ярарга тырышып, татар телен кураләтә кыса, туган телдә белем алуны тыя. Ни кызганыч, мондый ялгыш фикерләр очраклы гына барлыкка килмәде.

Татар әдәбиятыннан кала, татар мәктәпләрендә башка барлык предметларны рус телендә укытуга күчү, ә аннары татар балаларын рус мәктәпләрендә укыту эшенә керешү бернинди күрсәтмәсез-нисез башланды. Бу мәсьәләдә хөкүмәтнең бернинди карары да, мәгариф министрының һичбер фәрманы да юк. Процесс үзеннән-үзе барлыкка килде. Гадәттә эш болайрак булды: райком секретаре яки район башкарма комитеты рәисе вазыйфасына рус халкы күбрәк булган районнан берәр кандидат тәкъдим ителә. Аның балалары рус мәктәбендә укыган, татарча белми. Өстәвенә, районда рус милләтеннән тагын 3–4 җаваплы хезмәткәр бар. Менә шуларның балалары өчен рус сыйныфлары ачыла. Татар яшьтәшләре белән аралашып, бу балалар татарча сөйләшергә, укырга-язарга тизрәк тә өйрәнә алыр иде. Тик әти-әниләре каршы. Һәм җитәкчеләрдән үрнәк алып, татар ата-аналар да балаларын рус сыйныфларына күчерүне таләп итә. Монда русларга карата куптәннән килгән хөрмәт, рус телен яхшырак өйрәнергә омтылыш үзен сиздерә. Татарлар Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов һәм башка татар зыялыларының үгет-киңәшләрен яхшы хәтерли һәм рус телен белүне зур уңыш дип саный».

«Берникадәр вакыт уйланып торгач, С.Д. Игнатьев миннән сорап куйды:

– Ә рус сыйныфларында татар теле укытыламы?

– Юк дәрәҗәсендә, атнага ике сәгать кенә. Балалар онытып бетерә аны. Татар әдәбиятын укымыйлар диярлек. Нәтиҗәдә, ниндидер гайре табигый русча-татарча жаргонда сөйләшә торган, сай белемле, үз халкының тарихыннан, гореф-гадәтләреннән, мәдәниятеннән читләштерелгән татарлар буыны үсеп килә. Сүз уңаеннан, мондый чир белән партия, совет хезмәткәрләренең шактый күбесе авырый.

– Әйе, бер дә күңелле түгел, – диде Семен Денисович кәефсез генә. – Җитди уйланып алырга кирәк. Мондый зилзиләне туктатырга туры киләчәк. Син, зинһар, миңа тулы белешмә әзерлә».

КИҢӘШ ҺӘМ ФАТЫЙХА

«Тамчы таш тишә, диләр бит. Кабат-кабат сөйләшү нәтиҗәсе буларак, Семен Денисович татар мәктәпләре мәсьәләсен өлкә комитеты пленумында махсус тикшерергә ризалык бирде. Хәзер ҮК фатыйхасын алырга кирәк иде. Семен Денисович мин барында ҮК фән, мәктәпләр һәм мәдәният бүлеге җитәкчесе, академик А.М. Румянцевка шылтыратты:

– Алексей Матвеевич, сәламнәр сезгә. Монда иптәшләр бик җитди һәм четерекле мәсьәлә күтәрә. Баксаң, Татарстанда татар мәктәпләре юкка чыгып бара икән. Бу мәсьәләне пленумда тикшерергә ниятлибез. Ни диярсең?

– Туктале, ничек инде татар мәктәпләре югала?

– Казанда һәм башка шәһәрләрдә татар телендә укыта торган бер мәктәп тә калмаган. Татарлар

1. П. Поспелов, С. Игнатьев, А. Әбдрәзәков, К.Фасиев. 1960 ел.

2. М.Әмир, Г. Бәширов, С.Васильев, Л.Соболев, К.Фасиев.

PRESSA.RU

1. Укытучы. 1937 ел.

2. К.Фасиев, Ф. Табиев, А. Шамов, Ш. Хамматов, Г. Кашшаф.

балаларын рус мәктәбенә бирергә тырыша.

– Шуннан ни, бу начармыни? Рус телен яхшырак үзләштерерләр.

– Анысы шулай, әлбәттә. Ләкин хикмәт башкада. Монда милли сәясәт бозыла, дип уйлыйм. Татар яшьләре туган телен белми. Гомумән, милли мәдәнияткә куркыныч яный, ди иптәшләр.

– Әйе, башка республикалардагы аерым иптәшләрнең авызыннан да ничектер бу хакта ишеткәләгән идем. Проблема бик үткен төсмер ала башлады кебек. Киңәшләшергә кирәк. Минем адреска анык тәкъдимнәр белән җентекле хат юллагыз.

Ике көннән тиешле документ Үзәк Комитетка китте, ә бер атнадан Румянцев мине үз янына чакырды. Бүлмәсендә мәктәпләр буенча урынбасары В.Н.Дербинов та бар иде. Румянцев Василий Никитовичка РСФСРның мәгариф министры Е.И.Афанасенконы чакырырга һәм, минем белән бергә мәсьәләне яхшылап тикшереп, нәтиҗә чыгарырга кушты. Министр килеп җитте. Миңа хәлнең торышын җентекләп аңлатырга кушылды, фактларны, саннарны кабат-кабат ачыкладылар, сораулар яудырдылар. Дербинов милли мәктәпне шулкадәр түбән тәгәрәтүләренә ышану кыен икәнлеген белдерде. Афанасенко исә башка автоном республикалардан да мондый хәбәрләр ирешүен телгә алды, димәк, Татарстаннан килгән иптәшнең мәсьәләне гадел, дөрес күтәреп чыгуына ышанмаска нигез юк».

МИЛЛИ МӘКТӘП – ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

«Партия өлкә комитеты пленумы 1958 елның 21 маенда җыелды. Әлбәттә, мин бөтен докладымны сөйләп чыгарга җыенмыйм, шулай да аның төп урыннарына, мөһим мәгълүматларына тәфсиллерәк тукталу кирәк. Алар бүген дә актуальлеген югалтмады.

Мин докладымны Ленин сүзләре белән башладым. Милли телләрне һәм мәктәпләрне кысрыклаучыларга кырыс хөкем буларак, В.И. Ленин болай дигән: «Бездә, әйтик, Мәгариф комиссариатында яки шуның тирәсендә, «мәктәп бер, шунлыктан рус теленнән кала, башка туган телдә укыта күрмәгез» дип әйтүче коммунистлар бар. Минемчә, мондый коммунист – «великорусский шовинист». Бу шовинист күпләребезгә кереп утырган, аның белән көрәшергә кирәк» (Әсәрләр. – Т.29. – 172–173 б.).

Милли мәгариф тармагында партия яклаган принциплар әнә шундый иде. Һәм Татарстан үрнәгендә без бу принципларны тормышка ашыруның уңай нәтиҗәләрен күрәбез… Ләкин уңышлар белән канәгатьләнеп һәм горурланып, партия һәм совет органнары, беренче чиратта, Мәгариф министрлыгы торгынлык һәм кризис күренешләрен күрми калган, милли мәктәпкә игътибарны киметкән. Милләтләрне интенсив рәвештә бер-берсенә якынайтканда, имеш, балаларны туган телдә укыту зарурияте үзеннән-үзе төшеп кала, дигән фикер таралды. Татар мәктәпләренең абруе төшү тизәйде, аеруча соңгы унъеллыкта. Әгәр 1947–1948 уку елында татар балаларының 95% ы туган телендә белем алса, 1958 елда – андыйлар 70% кына, ә Казанда исә – нибары 16,8%. 16 татар мәктәбеннән икәү генә калды, алары да соңгы сулышта. 12 нче татар мәктәбе 1 нче сыйныфка нибары 11 бала кабул иткән. 18 нче мәктәптә әлегә татарча укыта торган ике сыйныф сакланып калган, тик аларда 19 укучы гына белем ала.

Авыл районнарында да хәлләр мактанырлык түгел… Нигездә, русча укытуга каршы чыгачак кеше табылыр микән. Җәмәгать һәм мәдәният эшлеклеләренең күбесе патша заманнарында ук рус мәктәпләренә һәм гимназияләренә эләгергә тырышкан. Әмма монда шуны истә тоту зарур: беренчедән, хәлле татарлар азмы-күпме төпле белем бирә торган милли мәктәпләр булмаганга күрә, балаларын рус мәктәпләрендә укытканнар, ә бездә хәзер андый мәктәпләр җитәрлек; икенчедән, нигездә, монда рус телен күпмедер дәрәҗәдә белгән һәм руслардан бер дә начаррак укымаган балалар турында сүз бара; өченчедән, алар туган телләрен һичкайчан онытмаган, чөнки моны ата-аналар һәм җәмәгать һәрдаим күзәтеп торган. Әллә ни күп санлы булмаган татар баласын рус яшьтәшләре белән укыту педагогик процесска зыян салмаган, татар мәктәпләренә комачаулык тудырмаган һәм милли зыялылар тәрбияләп үстерүдә уңай нәтиҗәләр биргән.

Татар балалары рус мәктәпләренә елга булып агыла башлагач, хәлләр кискен үзгәрде. Бу исә мәктәпнең төп принцибы – балага якынрак, аңлаешлырак туган телдә укыту принцибын үзгәртә, ахыр чиктә татар теленең аралашу, уку һәм язу чарасы буларак роле кими, татар тормышына хас кыйммәтле гореф-гадәтләр югала. Иң аянычы шул: нәтиҗәдә укучыларның белем дәрәҗәсе кискен түбәнәйде, бер сыйныфта икешәр елга утырып калучылар саны артты.

Милли мәктәп укучыларга тирән, төпле белем бирергә тиеш һәм шуңа сәләтле дә. Моның өчен аңа карата мөнәсәбәтне тамырдан үзгәртү зарур. Арабызда татар теленең кулланылыш дәрәҗәсе төшүгә, татар мәктәпләре азаюга зарланырга яратучы

иптәшләр бар, ә үзләре балаларын рус мәктәбенә бирә.

Татар мәктәпләрен саклап калырга, халыкта аларның абруен күтәрергә телибез икән, эшне партия һәм совет органнарының җитәкчеләреннән, җаваплы хезмәткәрләреннән, укытучылардан һәм мәктәп директорларыннан башларга кирәк. Алар татар мәктәпләрен хөрмәт итүдә үрнәк күрсәтергә, бу уку йортларын кайгыртырга, хәлләре белән кызыксынып торырга, балаларын туган телдә укытырга тиеш. Мәгариф министрлыгы бу фәнне дәүләт имтиханнарыннан төшереп калдырып, зур ялгышлык җибәрде. Бу гамәл үзе үк туган телне укуга теләк кимүгә этәргеч булды. Хәзерге вакытта татар балаларының 35%ы аны фән буларак укымый. Ашыгыч чаралар кылмаганда, тенденция көчәя генә барачак. Туган тел – милли әдәбият һәм сәнгатьнең нигез ташы, аларның чәчәк атуына төп шарт. Туган телне үзләштерүдән мәхрүм итеп, без мондый белемсез кешеләрне халык тарафыннан гасырлар дәвамында иҗат ителгән гаҗәеп бай милли мәдәниятнең «юл читендә» калдырабыз.

Татар мәктәпләре турында махсус кайгырту – интернационализм карашларыннан читләшү, милләтчелеккә юл ачу ул, дигән ялган күзаллауларны кыю рәвештә кире кагарга кирәк. Миллилек булмыйча интернационализм да формалаша алмый. Үз телен һәм халкының гореф-гадәтләрен әйбәт белгән, шул нигездә киң эрудициягә ия булган шәхес башка милләтләр өчен тел һәм мәдәниятнең мөһимлеген яхшы аңлый, аларның рухи кыйммәтләрен җиңелрәк үзләштерә, аларның тормыш рәвешенә җайлаша. Без берничек тә татар мәктәпләрен русныкына каршы куймыйбыз, милли чикләнгәнлекне һәм йомылганлыкны нәфрәт белән кире кагабыз».

Докладның кыскача эчтәлеге шундыйрак. Ул бик зур кызыксыну уятты һәм пленумда катнашучыларда яклау тапты.

Пленумда В.Н. Дербинов чыгыш ясады: «Иптәш Фасиев милли мәктәпләрдәге эшләрнең торышын дөрес тасвирлады. Ул үзенең төпле докладында хәбәр иткәнчә, туган телдә белем алучы балалар саны 10 ел эчендә 25%ка кимегән... Мәгариф министрлыгының җаваплылыгы турында сөйләгәндә, иптәш Фасиев бик хаклы. Республикадагы эшләрнең торышы белән танышуыбыз шуны раслады: татар мәктәпләрендә эшләрнең мөшкеллеген дөрес аңлап, бәя биргән булса, Министрлык күп кенә чараларны үзе үк кыла ала иде. Эш анның мәсьәләне өлкә комитетында, Министрлар Советында һәм РСФСР министрлыгында күтәреп чыгу-чыкмавында түгел. Татар мәктәпләре өчен яхшы дәреслекләр әзерләү өчен югарыдагы органнардан нинди күрсәтмә кирәк? Бу – министрлыкның турыдан-туры бурычы. Мәктәпләр өчен махсус педагоглар әзерләү эшен оештырыр өчен тагын нинди карар таләп ителә?

Шул ук вакытта кабатлап китәм: хәлнең начарлануы өчен республиканың бөтен партия оешмасы – өлкә комитеты, шәһәр һәм район комитетлары да җавап тота. Милли мәктәпләрнең абруе ничек түбәнсетелгәнен һәркем күрде. Катгый карарлар кабул итәсе урында, җитәкчеләр балаларын рус мәктәпләренә күчереп куйган – бетте-китте вәссәлам».

Шактый югары дәрәҗәдә фикер алышулардан соң, өлкә комитеты пленумы «Татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләренең хәле һәм аларда эшне яхшырту турында» Карар кабул итте».

СТОП! КИЛЕП ҖИТТЕК

«Күпмедер вакыт узгач (ел ярымнан соң), партиянең Үзәк Комитетына КПСС Татарстан өлкә комитетының элекке беренче секретаре З.И. Моратовтан шикаять килә. Ул өлкә комитеты пленумындагы чыгышымны тәнкыйть утына тоткан. Гаепләре дә җитди – милләтчелек. Мәскәүдәгеләр өлкә комитеты карарын яңадан тикшерергә тәкъдим итте, һәм моны 1960 елның гыйнвар аенда эшләп тә куйдылар (бәхәссез-нисез генә). Моратовның хаты һәм Үзәк Комитетның аңа уңай җавабы һич тә очраклы түгел. Бу – Сталиннан мирас итеп алынган милли сәясәт чагылышы. Милли мәктәпләргә тискәре мөнәсәбәт бездә генә түгел иде. Мәсәлән, шул ук елны Кыргызстан коммунистлар партиясе ҮК беренче секретаре И. Раззаков, кыргыз балалары укыган мәктәпләрдә кыргыз телен укытуны җайга салырга кушкан өчен, эшеннән алынды. Игнатьев кебек кыю кешенең дә шүрләп куйганына гаҗәпләнәсе юк. Утны-суны кичеп, зур-зур вазыйфалардан төшерелеп, ул сак булырга өйрәнгән иде, вакытында чигенә, боргалана, хәтта игелекле ният белән кабул ителгән карарларыннан баш тарта белде. Башка җитәкче иптәшләребез, ул чакта активлашып киткән җәмәгатьчелек фикерен ишетмәмешкә салышып, тавыш-тынсыз гына Үзәк ихтыярына бирелде». T

3. С. Фасиева, К.Фасиев, Ф. Табиев, Б. Гыйззәтуллин. 1960 ел.

4. Үткәннәрне искә алып...

Әзерләде:
Нияз Әхмәдуллин

3

4

PRESSA.RU

Автор:
Руфия Фазылова

ТАТАР ТЕЛЕ: ЧИШЕЛЕШ БАРМЫ?

Уку елының беренче яртысы узып бара. Ә мәктәпләрдә татар теле буенча вазгыять һаман аңлашылмый: кайсыдыр мәктәпләрдә ул ике сәгать, икенчеләрендә факультатив, өченчеләрендә элек ничә иде, шулкадәр укытыла. Миңа калса, бу очракта мәктәп директорлары намус кушканча эшләде кебек.

Кадерле Ана телебезнең киләчәге ничек булып бетәр? Бу сорау аз гына милли үзаңы булган һәр кешене борчый. Алай гына түгел, күпләрнең җанын айкый... Нишләргә соң? Менә шушы сорауга җавап эзләп карадым.

«СУДКА МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕ УКЫТУЧЫ ЮК!»

Кул кушырып утырмыйбыз үзе: Дәүләт Советы бинасы каршына барып «Туган тел»не дә җырладык. Бауманда да җыр суздык. «Без татарлар!» дип кәттә-кәттә шигырь дә яздык. «Мин татарча сөйләшәм» акция кысаларында ТР Конституциясенең 25 еллыгына багышланган концерт та оештырдык. Тик... дөресен әйтик, хәлләр мөшкел. Җырлап, сөйләп кенә бу мәсьәләләрне хәл итеп булмый шул. Конкрет адымнар кирәк. Дәүләт җитәкчеләреннән дә, аерым гражданнардан да. Моны сәясәтчеләр, хокук белгечләре дә шулай ди.

Редакциягә танылган адвокат Руслан Нагиевны чакырдык. Татар теле белән бәйле ыгы-зыгы башлангач та, милли җанлы Руслан Нагиев, иң беренчеләрдән булып, эштән азат ителгән укытучыларны якларга әзер булуын игълан итте.

– Татар теле мәсьәләсендә бернинди бәхәсләр дә була алмый, –

Фото: Александр Ефремов

ди Руслан Нагиев. – Россия Федерациясенең 62 маддәсе бар. Аның нигезендә Россия Федерациясенә кергән республикалар үзләренең дәүләт телләрен билгели ала. Шулай ук мәгариф турында Федераль закон кабул ителгән. Анда республикаларга үзләренең дәүләт телен укыту мөмкинлеге бирелә диелгән. Ә РТ Конституциясе нигезендә, Татарстанда ике дәүләт теле: рус һәм татар телләре. «Телләр турындагы Татарстан Республикасы законы» нигезендә республикада ике дәүләт теле дә тигез күләмдә укытыла. Моңа өстәп тагын 2004 елда Россия Конституция суды Татарстанда ике дәүләт телен укытуны тикшерде. Һәм бернинди закон бозулар тапмады. Шуңа күрә бу турыда нинди дә бәхәсләр, ризасызлыклар булырга тиеш түгел.

Рус телле балаларга татар теле укыту методикасын яңадан карарга мөмкин әле. Монысы икенче мәсьәлә. Ләкин мәктәпләрдә мәҗбүри татар телен укытудан баш тарту законга каршы килә.

– Шуңа да карамастан, РФ Прокуратурасы мәктәпләрнең астын өскә китерде. Янәсе, татар телен укыту программасы ФГОСка туры килми, – дим Руслан Нагиевка.

– Әйе, Прокуратура бары тик ФГОСка таяна, ә башка барлык законнар да татар телен мәктәпләрдә укыту ягында. Ләкин белем бирү өлкәсенә караган әлеге стандартта республиканың дәүләт телләре мәҗбүри укытылырга тиеш, дип язылмаган. Гомумән, ФГОСта дәүләт телләре турында сүз юк. Шуңа күрә ул безнең төп законга каршы килә. ФГОС – бары «подзаконный акт», ул Федераль законнан өстен була алмый. Шуңа күрә Россия Югары судында ФГОС нормалары яңадан каралырга тиеш, аны үзгәртүне таләп итәргә кирәк. Әлбәттә, әлеге стандартларны РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы үзгәртә ала. Тик күргәнебезчә, әлегә кадәр андый хәл күзәтелми. Безнең бары бер генә юлыбыз бар – суд аша үзебезнең хокукларны яклау.

Закон нигезендә судка мәктәп, гимназиянең директорлары яки эштән кыскартылган татар теле укытучылары мөрәҗәгать итә ала. Руслан Нагиев берничә мәктәп директоры белән эш алып барган. РФ Югары Судына дәгъва документлары әзерләгән. Тик судка кадәр барырга риза булган директор, укытучылар әлегә юк.

– Әле беренче чирек азакларында мәктәп директорлары, укытучылар татар телен яклап судка бирү буенча киңәшләр сорап еш шалтыраталар иде. Ә хәзер тынычланып калдылар. Әллә бу хәлгә күнделәр, әллә куркалар. Югыйсә куркырга кирәкми, җинаятьчеләргә мөрәҗәгать итмиләр бит. Аларның хокукларын Югары судта якларлык юристлар бар…

Курку безнең кандадыр ул. Яшисе, эшлисе бар, дип куркабыз. Социаль челтәрләрдә аерым төркемнәр булдырып язышабыз, эштә чәй эчкәндә сөйләшеп, уфтанып, ә кайчакта елашып алабыз да тынычланабыз. «Ә нишли алабыз соң?» – дибез. Ә эшләүчеләр бар бит!

«КЕМНЕҢ КЕМЛЕГЕН КҮРСӘТТЕ!»

Казанда барлык фәннәрне татар телендә укытучы бары бер генә белем бирү йорты бар: Ш. Мәрҗани исемендәге 2нче татар гимназиясе. Урыслаша барган шәһәр ыгы-зыгысыннан соң бирегә килеп кергәч, гаҗәпләнеп тә, сокланып та каласың. Балалар бер-берсе белән татарча сөйләшә. Һәм барысы да үзебезчә, рәхәт…

Гимназиянең директоры Камәрия Хәмидуллинаны күпләр татар теле өчен көрәшүче, милли җанлы, фикерле ханым буларак белә. Ул Казан шәһәр Думасы депутаты да. Татарстанның халык укытучысы, андый исемле мөгаллимнәр республикада бишәү генә. Рәсми чыганаклардан анык җавап ала алмаганга, без абруйлы укытучы – Камәрия Зиннуровнага мөрәҗәгать итәргә булдык.

– Дөресен әйтим, ике айдан бирле татар теле турында бер генә журналистның да соравына җавап бирмәдем, күрәсең, вакыты җиткәндер, – диде Камәрия ханым. Татар гимназиясенең директоры проблемадан чыгу юлын бик гади күрә:

– Гаеп атта да, тәртәдә дә, – диде Камәрия ханым. – Мәскәүдән төшерелгән уку планнары арасында ана телендә белем бирә торганнары бар – бишенче вариант. Бездә фәлән кадәр татар мәктәбе бар, дип сөйләшәбез. Ни өчен ул мәктәпләр барлык фәннәрне дә татар телендә укыту программаларын сайламый? Татар теле дә кыскармый. Рәхәтләнеп татар телендә укытып ятасың! Тел өйрәтү өчен татар теле дәресе генә җитми. Әдәби телне саклап калам, чын милли мәктәп булсын дисәң, барлык фәннәрне дә татар телендә укытырга кирәк. Шул юл белән генә дөньяны күзаллау, кабул итү, милли үзаң тәрбияләнә. Ә татар теле дәресе үзе зәвык тәрбияли. Һәм ул әхлакның нигезе. Башка фәннәрне өйрәнер өчен инструмент буларак кулланыла.

2нче татар гимназиясенә дә Прокуратура вәкилләре килгән, тикшерү булган. Татарчага тәрҗемә ителгән уку әсбапларын рус вариантлары белән чагыштырып караганнар.

– Предметларны татар телендә укытып кына, милли мәктәп була ала. Татар телендә җырлап, биеп кенә, минем мәктәбем татар дип йөрү иллюзия, хата. Мисал өчен, Надежда Бабкина «Тары җире, киндер җире» дип җырлап китте. Аңа карап Надежда Бабкина татарга әйләндеме? Татар биюен бии торган мари, чувашлар да күп, аңа карап алар татарга әйләнми.

PRESSA.RU

Закон бозулар тапмаганнар, чөнки уку әсбапларының авторлары, барлык биремнәр дә республиканың башка мәктәпләрендәге кебек. Аерма шунда гына – алар татар телендә. Шулай булгач, бу очракта татар гимназиясе әле киресенчә, откан да. Сәгать саннары да кимемәгән, укыту планы да үзгәрмәгән.

– Бу ситуация кемнең кем икәнен күрсәтте, – ди Камәрия ханым. – Алдынгы саналган, яхшы исемнәре булган мәктәп директорлары бер сәгать татар теле калмый торган укыту планнарын сайлады. Рус мәктәбендә директор булсам, татар теле курслары ачар идем. Анда беренче булып үзем язылыр идем, шәхси үрнәк күрсәтер өчен. Рус милләтеннән булган кайсы мәктәп директоры татар телен белә бүген? Ә ул белергә тиеш. Ул бит татар балаларын да укыта, аларның ата-аналарын, әби-бабаларын кабул итә. Безнең Конституциядә язылган бит: Президент ике телне дә белергә тиеш. Ни өчен бу барлык җитәкчеләргә дә кагылмый? Ни өчен әле бер телне генә белгән мәктәп директоры яхшы булып йөри? Аның янында гына исеме бер җирдә дә мактап телгә алынмаган мәктәп директорлары бар. Алар шартлатып ике телдә дә сөйләшәләр. Бу һөнәри кодексның бер шарты булып торса, вазгыять, татар теленә караш үзгәрер иде, дип уйлыйм.

«МЕТОДИКАГА СЫЛТАП КАЛДЫРУ – ИҢ ҖИҢЕЛ ЮЛ!»

Дөресен әйтик, 25 ел мәктәптә татар теле укып, рус телле балаларның күбесе татарчаны аралашу дәрәҗәсендә дә белми. Кагыйдәләрен әйтеп торасы да юк. Минемчә, моның сәбәбе бик гади: татар теленә ихтыяҗ, кирәксенү юк... Ярар, рус телле балалар – икенче мәсьәлә. Монда бит чеп-чи татар гаиләләре ана телләреннән баш тарта, мәктәпләргә барып «кирәкми» дип гариза яза. Менә монысы берничек башка да, акылга да сыймый!

– Татар теленнән баш тартучылар методикага сылтап калдыра, – ди Камәрия ханым. – Минемчә, бу сүз татар теленә ясалма килеп бәйләнде. Җиңел бит: методикасы начар! Аны әйткән кеше һәрвакыт хаклы була, чөнки методиканы идеаль итеп булмый. Андый предмет юк. Методика ул – укыту алымнары, аны һәр кеше үзенчә чарлый, тормыш тәҗрибәсеннән ала. Укытучы, коллегалары белән аралашып, китаплардан өйрәнә. Кайчан әйтелсә дә, кем әйтсә дә, һәм кайсы предметка карата әйтелсә дә: «Методика дөрес түгел», – дигән кеше хаклы була. Һәм моны тотып алдылар. Методика төп сәбәп булып калды. Телне уйнап кына укытырга кирәк диючеләргә аптырап каласың. Рус төркемнәрендә уен уйнау, бәлки, үзен аклар. Ә татар баласына ана телен бөтен нечкәлекләре белән, башка предметларны укыткан кебек эзлеклелек, тулылык, фәннилек принципларын ватмый-җимерми укытырга кирәк. Телнең социаль тышчасын, мәдәни егәрен сакларга кирәк. Шул чакта гына тел үзенең төп – милләтне яшәтү функциясен саклый алачак. Татар телен чит тел өйрәтү методикасы белән өйрәтергә кирәк, дип сөйли башладылар. Чит тел методикасына татар теле сүзен тагу шулкадәр куркыныч әйбер. Без Татарстанда яшибез! Син подъездыңнан чыкканда күңеңне исәнләшүдән башлыйсың, хәл сорашу белән дәвам итәсең. 25 ел эчендә исәнме, сау булны өйрәнергә була иде! Ә калганы мөһим түгел. Мин күршемнең соравына татарча җавап бирәм. Шул рәвешле ике җөмлә алыштык. Бетте. Шуның белән җитте. Калганын сөйләшеп торырга бүген кешенең вакыты да юк. Ул ике сүзне белгән рус кешесе үзен минем белән бер дәрәҗәдә тота, менә аның шунысы кыйммәтле. Кеше алдында миңа үз телемдә эндәшә! Миңа үз кеше булырга тели. Бу иң зур хөрмәткә лаек фал.

Татар теленә каршы чыгучы ата-аналар төп сәбәп итеп бер дәлил китерә: балаларның БДИ бирәселәре бар. Ә БДИ фәкать рус телендә. Шулай булгач, татар телен рус теле белән бер дәрәҗәдә уку нигә кирәк? Бу очракта, без: «Анысы шулай, тик сез Татарстанда яшисез бит...» дип акланган булабыз. Югыйсә каядыр күңел түрендә аңлыйбыз: чынлыкта,

– Бу ситуация кемнең кем икәнен күрсәтте, – ди Камәрия Хәмидуллина. – Алдынгы саналган, яхшы исемнәре булган мәктәп директорлары бер сәгать татар теле калмый торган укыту планнарын сайлады. Рус мәктәбендә директор булсам, татар теле курслары ачар идем. Анда беренче булып үзем язылыр идем, шәхси үрнәк күрсәтер өчен. Рус милләтеннән булган кайсы мәктәп директоры татар телен белә? Ә ул белергә тиеш. Ул бит татар балаларын да укыта, аларның ата-аналарын, әби-бабаларын кабул итә. Безнең Конституциядә язылган бит: Президент ике телне дә белергә тиеш. Ни өчен бу барлык җитәкчеләргә дә кагылмый?

Ш. Мәрҗани исемендәге 2нче татар гимназиясе Камәрия Хәмидуллина:

– Кайчан соң безнең халыкның, милли җанлы шәхесләребезнең әйткән сүзләренә игътибар итә башларбыз?! Конституция кабул иткәнгә 25 ел узып китте. Кайда безнең милли университет? Ни өчен безнең хыяллар тормышка ашмый?

ана телебезнең дәрәҗәсе түбән, аңа ихтыяҗ юк…

– Ана теленә ихтыяҗ булсын дисәк, һичшиксез, БДИны татар телендә бирергә кирәк, – дип, сүзен дәвам итте Камәрия Хәмидуллина. – Моның өчен милли республика, төбәк – мари, чуваш, татар, башкорт, якут җитәкчеләре рус иленең җитәкчесенә барырга тиеш. Сөйләшергә, бер тапкыр, биш тапкыр. Егерме биш елга егерме биш тапкыр. Аңлатырга. БДИны ана телендә бирә торган законны кертмичә, милли мәгарифне аякка бастырып булмый. Ул законны кеше язган, аңа төзәтмә кертү юллары да бар. Шунсыз булмый. Бер телдә, әйтик, татар телендә белем алып, рус телендә имтихан тапшыру тәҗрибәсе дөньяда юк, бу фәкать Россиядә генә бар.

2нче гимназия укучылары дөнья тәҗрибәсендә булмаганча укый: татар телендә укып, рус телендә БДИ тапшыра. Нәтиҗәләр яхшы. Чыгарылыш сыйныф укучыларының 90 процентыннан артыгы ел саен югары уку йортының бюджет төркемнәренә эләгә. Тик директор бу турыда бик сөйләргә яратмый:

– Безнең тәҗрибәне татар директорлары кабул итә алмый, – ди Камәрия ханым. – «Аның һаман шул инде: фәннәрне татарча укыту турында сөйли», диләр. Шуңа күрә бу хакта сөйлисем дә килми. Соң, телне саклап калуның башка юлы булмагач, нишләргә кала?! Предметларны татар телендә укытып кына милли мәктәп була ала. Татар телендә җырлап, биеп кенә, минем мәктәбем татар дип йөрү иллюзия, хата. Мисал өчен, Надежда Бабкина «Тары җире, киндер җире» дип җырлап китте. Аңа карап Надежда Бабкина татарга әйләндеме? Татар биюен бии торган мари, чувашлар да күп, аңа карап алар татарга әйләнми.

2нче гимназиядә дә проблемалар бар икән. Мисал өчен дәреслекләр җитми. Татар телен дә, фәнне дә камил белгән укытучыларны табу да җиңел түгел.

– Соңгы ике ел эчендә без төрле районнардан татар телендәге дәреслекләр җыеп йөрибез, – ди Камәрия ханым. – Дәреслекләр кулланылыштан чыга. Нигездә хәзер каядыр яткан артык китапларны кайтаралар. Гомумән, татар телендәге дәреслекләр бастыру бер проблема дип беләм.

Шулай ук югары уку йортларында ана телебездә белем бирә торган укытучылар әзерләү системасы да бетте. Ә бит студентларга беренче курстан ук: «Менә син педагогик практиканы татар мәктәбендә уз, киләчәктә ана телебезне күтәрү сезнең кулларга кала», – дип сеңдерү кирәк. Совет заманына кайтабыз. Милли үзаң тәрбияләү юк. Менә шунысы борчый…

ТАТАР ТЕЛЕННӘН ГЕОГРАФИЯ УКЫТУЧЫСЫНА!

Язманы әзерләр алдыннан берничә тапкыр Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгына мөрәҗәгать иттем. Тик әлегә бер генә сорауга да җавап бирә алмадылар. Татарстан Дәүләт Советында узган 33нче утырышта узган чыгышында, ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, Россия мәгариф министры Ольга Васильева белән күрешүен әйткән иде. Татар теле дәүләт теле буларак 1–9 сыйныфларда атнасына ике сәгать мәҗбүри, ә югары сыйныфларда ихтыяри булачак дигән вариант яңгыраган иде. Әлегә бу мәсьәләдә ачыклыклар юк. Бер генә мәктәп директорының да өстәлендә конкрет күрсәтмә ятмый. Барысы да Ольга Васильеваның рәсми хатыннан соң ачыкланырга тиеш икән.

Әлегә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы икенче юнәлештә эш башлап җибәрде: татар теле укытучылары, теләкләре булса, яңадан әзерлек курсларында икенче белгечлек алып чыга ала. Кайсы фән булуы мөһим түгел: тарих, география, рус теле, яки башка фәнме, укырга мөмкин. Мондый курслар Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә бар. Гаризалар китергән укытучыларның күбесе башлангыч мәктәп һәм рус теле, рус әдәбияты белән кызыксына. Шулай ук тарих, риторика, физкультура, психология, технология фәннәрен сораучылар да бар икән. Кыскасы, татар теле укытучылары иписез калмаячак. ТР Мәгарифне үстерү институтына укытучылардан 2 меңгә якын гариза кергән инде.

Хәзер ничә айдан бирле нәрсәдер көтәбез. Җитәкчеләр дә, укытучылар да, ата-аналар да. Кайберәүләр инде кул да селтәде. Конкрет адымнар кайчан ясый башларбыз соң? Бөтен кеше барысын да белә, аңлый, күрә, ә Ана телебез үги булып кала бирә. Сүзләрдән конкрет эшләргә күчәр вакыт җиткәндер. Һәр кеше үз югарылыгында эшләр вакыт…

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ



«ЯШЕЛЧӘЛӘР ПАТШАСЫ»ННАН – МАНТЫЙ

Кызларыбызның берсе еш ютәлли. Салкыннар җиттеме – башлана... Соңгы тапкыр авырганда тәҗрибәле табиб безгә кабак ашарга кушты. Тын юлларына файдалы, диде. Могҗиза: бер атна дигәндә ютәл бетте. Әлбәттә, эчкән даруларның да файдасы булгандыр, әмма кабакның да ярдәме тиде, дип уйлыйм.

Автор:
Руфия Фазылова

Әлеге яшелчәдәге файдалы матдәләрне галимнәр кат-кат тикшергән. Мондагы ферментлар, җиңел үзләштерелә торган углеводлар, аксым, пектиннар, бик күп төрле витаминнарның барлыгы ачыклангач, кабакны «яшелчәләр патшасы» дигәннәр.

Без дә редакциябез кухнясында кабактан ризык пешерергә булдык. Яңа елдан соң әлеге яшелчәне саклавы да кыенлаша, ул файдалы үзлекләрен дә югалта башлый, диләр. Шулай булгач, әзерләп калырга кирәк!

ЙӨРӘККӘ ӘМЕР БИРЕП БУЛМЫЙ

Кабактан ризык пешерер өчен әллә ни ерак китмәдек – Казаннан 40 чакрым ераклыктагы Лаеш районының Габишево авылына юл тоттык. 25 яшь кенә булуына карамастан, Люзия Скорнякова бөтен төр ризыкны: беренче, икенче ашлар, камыр ризыкларын бик оста әзерли. Телефоннан сөйләшкәндә үк: «Кабактан бәлеш, ботка, аш, мантый да әзерли алам», – диде.

Соңгысы кызык кебек тоелды. Иң мөһиме – катлаулы түгел. Мантый өчен кирәк булган ингредиентлар һәр йортта да бар. Кибеткә махсус барып та торасы түгел. Тиз әзерләнә, җиңел ашала.

Люзия бик үткен, кулы кулга йокмый. Бөтен ризыкны пешерә белүенең сере – югары белемле бишенче разрядлы пешекче ул, кафеда эшли.

– Нинди ризыклар әйбәтрәк чыга: ашлармы, камыр ризыкларымы? – дим Люзиягә.

– Дөресен генә әйткәндә, беренче, икенче ашларны пешерергә яратам. Тик соңгы арада күбрәк камыр ризыклары әзерлим. Кафеда камыр бүлеге бар, еш кына шунда эшләргә туры килә.

Без килгәнче, Люзия кабакны чистартып, әзерләп куйган иде.

– Өчебез өчен әзерләгәндә бер җәем камыр да җитә, – диде яшь хуҗабикә.

– Кабакны яратасызмы? – дим.

– Яратабыз. Улым Әскәр кечкенә вакытта гел пешерә идем. Хәзер исә сирәгрәк ашала, шулай да көз көне кабактан әзерләнгән ризык өстәлдә һәрвакыт бар.

Люзия кабакны (кишер урынына) ашка да куша, ит чыгартканда да сала, салат та ясый. Бәлеш, мантый турында әйткән дә юк.

– Кабакны иткә кушсаң, кәтлитләр сусыл була, – ди Люзия. – Аннан без шарлотка да яратабыз. Алма белән кабакны турап саласың, бик тәмле була.

– Кабак каян аласыз? Күпкатлы йортта яшисез бит, – дим.

– Әнием Хәерби авылында яши, ара унбиш кенә чакрым, еш кайтабыз. Авылдан алып киләбез.

ЛЮЗИЯ СКОРНЯКОВАДАН КАБАК МАНТЫЕ РЕЦЕПТЫ:

1. Йомырка – 1 данә;
2. Он – 3 стакан;
3. Кабак – 400 г;
4. Суган – 1 баш;
5. Сыер мае яки сыек май – 100 г;
6. Майонез – 2–3 аш кашыгы;
7. Су – ярты стакан.

Фото: Лилиана Вәлитова

PRESSA.RU

БУ КЫЗЫК!

Кабакның нинди генә төрләре юк! Без ияләнгән гади төрләрдән тыш, аның яңалары да бар:

- **«Балавызлы кабак» («бенинказа») –** бик озак саклана, тышы балавыз белән капланган.
- **«Урман чикләвеге» –** ашар өчен тәмле, чикләвекне хәтерләтә.
- **«Баллы гитара» –** чыннан да, гитараны хәтерләтә. Аны чи килеш ашыйлар, төше киңәеп киткән өлешендә генә була.
- **«Лагенария» –** кабаклар гаиләсеннән булган яшелчә. Шешә, каз рәвешенә кереп үсә.
- **«Лонгиссима» –** бер башыннан кисеп алып ашыйсың, икенче башыннан үсеп утыра башлый.
- **«Люффа»** төреннән мунчала ясыйлар. Октябрьдә аны өйгә алып кереп куялар. Берникадәр саргайгач, кайнар су белән пешекләп, тышын алалар. Шуннан мунчала ясыйлар.

Люзиянең тормыш иптәше Юра рус милләтеннән. Мантыйга дигән кабакны турый-турый, катнаш никах мәсьәләсен дә кузгаттык.

– Әти-әниең рус егетенә кияүгә бирергә каршы булмадымы? – дим.

– Безнең әти юк, мин кечкенә вакытта вафат булды. Әнигә: «Юра белән таныштым», – дигәч тә, кырт кисте: «Аралашасы да булма», – диде. Тик йөрәккә әмер биреп булмый икән. Юра үзенә гашыйк итте дә куйды. Ихтирамлы, ярдәмчел ул. Мөнәсәбәтләребез турында башта якыннарыма әйтергә куркып йөрдем. Без бит авылда тәрбияләнгән балалар. Туганнар, дуслар ни әйтер дип, кот очты. Берсендә Юра мине авылга кайтарып куйды. Шунда әни, абый белән таныштылар. Егетем аларга ошады. «Бер-берегезне чынлап яратсагыз, каршы килмибез», – диделәр. Озак та үтмәде, өйләнештек.

– Гаиләгездә дин, телгә бәйле аңлашылмаучанлыклар чыкканы юкмы? – дим.

– Әйтмәгәнем булсын, юк. Улыбыз тугач, мәчеткә барып, исем куштырдык. Әскәр белән мин татарча сөйләшәм, әтисе кайткач, русчага күчәбез. Дөрес, без никах укытмадык. Ирем каршы түгел иде, тик никах укыганга карап, ул мөселман диненә күчми бит. Шулай булгач, күз буяу нигә кирәк? Ә бала тәрбиясенә килгәндә, улыбыз, үскәч, үзе сайлар. Безнең гаиләдә дингә басым ясау юк.

«ШӘҺӘРДӘН КИМ ЯШӘМИБЕЗ!»

Люзия кабакны вак итеп шакмаклап тураганнан соң, майлы табага салды. Аннан янына туралган суган өстәде. Барысын бергә биш-җиде минут сүрән утта кыздырып алганнан соң, әзерләп куелган тоз, борыч, укроп салды.

– Кабак белән суганны атланмайда кыздырырга да була, – диде Люзия. – Кем ничек ярата бит. Мин сыек май белән кулайрак күрәм, андый мантыйны салкын килеш тә ашап була.

Мантый камырына Люзия майонез да сала икән, йомшак булсын өчен, ди. Майонезга су, йомырка, тоз салып, йомшак кына камыр басты.

– Камыр каты булса, мантыйны ябыштырып булмый, – ди Люзия. – Артык йомшак та кирәкми, җәйгәндә, куна тактасына ябыша. Камырның нәзеклеге исә уртача булырга тиеш. Пилмән камырыннан чак кына калынрак.

Чынлап та мантый ясау тиз икән. Кабак, суган турау, камыр җәю белән бергә ярты сәгать чамасы вакыт кирәк булды. Иттән ясалган мантыйга караганда, кабакныкы тизрәк тә пешә.

– Егерме минутта әзер була, – диде Люзия. – Кабакны майда кыздырып алдык бит, камыры гына пешәсе калды. Мин мантый, өчпочмакларны зур ясамыйм. Кул шулай ияләнгән. Зур-зур мантыйны ашау күңелле түгел, минемчә...

Ул арада хуҗабикә мантыйларны пешерергә куйды. Бер җаймадан ике мантоварка түгәрәге чыкты.

– Дүрт кеше рәхәтләнеп тамак туйдыра инде моннан, – ди Люзия.

– Югары белем белән гади пешекче булып эшлисеңме? – дим.

– Әйе, мин зарланмыйм. Тәҗрибә алу бу. Әлбәттә, Казанда яшәсәк, бәлки, башка төрлерәк эш тә булыр иде. Безнең Габишево авылында сайлау мөмкинлеге зур түгел. Эш графигым да җайлы: дүрттә кайтып китәм. Балалар бакчасына җитешәм. Хатын-кыз өчен шунысы бик мөһим.

– Килгәндә игътибар иттек: каршыгызда гына мәктәп тә бар ахрысы?

КАБАК АШЫ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак:

- 1 литр су
- 1 кг чистартылган кабак
- 1 суган
- 1–2 тырнак сарымсак
- 50 г атланмай
- 100 г сөт
- 2 аш кашыгы үсемлек мае
- 1 аш кашыгы шикәр комы
- тәменчә тоз, борыч.

Суганны кыздырырга, тоз, борыч сибеп, изелгән сарымсак кушып болгатырга. Шуңа туралган кабак, бераз шикәр комы сибеп, суган өстенә салырга. 5–6 минут утта тотканнан соң, су агызырга. Талгын утта 20 минут пешерергә һәм куертылган сөт салырга. Аннан барысын бергә блендер белән болгатырга. Ашны яшел тәмләткечләр белән бизәргә була.

– Бар, балалар бакчасы, мәктәп, спорт үзәге, башка кирәкле социаль үзәкләр эшли. Башта Габишевоны бик яратмаган идем. Мин көллиятне Чаллыда тәмамладым. Югары белемне дә шунда алдым. Шәһәрдә яшисе килгән иде. Ә язмыш минә монда китерде. Хәзер, киресенчә, шәһәрне яратмыйм. Казанга барсак, башым авырта башлый: кеше күп, ыгы-зыгы. Габишевода кешеләр бер-берсен белә, авыл кебек. Ләкин авылдан күпкә яхшырак: юллар төзек, балалар өчен түгәрәкләр эшли, кибетләр, кыскасы, шәһәрдән ким яшәмибез. Кирәк икән, машинага утырып, Казанга барып киләбез. Ярты сәгатьлек юл, бик рәхәт!

«ИТЕ БУЛСА, ЯХШЫРАК!»

Люзия Габишевога мәдхия укыган арада мантыйлар әзер булды. Аш бүлмәсенә кабакның хуш исе таралды.

– Шулай тәмле була, – дип, хуҗабикә өстәлгә каймак та куйды.

Минем кабак мантые ашаганым юк иде. Тәме ничек булырга тиеш икәнен әйтә алмыйм. Авыз итәбез... Тәмле... Укроп салгангамы, кабак мантые димәссең. Борыч тәме дә бар. Үзгә ризык.

Люзия пешергән ризык ошады. Ит ашыйсы килмәгәндә, кичке сый буларак әйбәт кенә була, дип уйлыйм. Һичшиксез пешереп карарга кирәк!

– Йә, ничек? – дип елмая Люзия.

– Ите булса, яхшырак, – дип куйды машина йөртүчебез Александр.

Бу – ир-ат фикере. Шәхсән миңа, хатын-кыз буларак, алай тоелмады. Хәер, иткә бик исе китмәгән, бигрәк тә вегетариан ир-атлар да кабак мантыеннан баш тартмас, дип уйлыйм.

– Ирең кабак мантыен яратамы соң? – дим Люзиягә.

– Ярата дип... Пешергәндә ашый инде. Шулай да бик исе китми. Аның каравы, каенанам ярата. Узган елларда пешергән идем, аңа да бер тәлинкә илттем.

– Каенанаң да монда яшиме? – дим.

– Әйе, Габишевода торалар. Өч ул үстергән. Юра – төпчеге. Каенанам улыбызны карарга бик булышты. Әлегә Әскәр аның бердәнбер оныгы, балабызны бик ярата. Барасы җиребез булса, улыбызны аңа калдырабыз.

– Алайса килене йөрәгенә хуш килгән икән, – дим, елмаеп.

– Ул безнең мөнәсәбәтләргә беркайчан да каршы булмады. Катнаш никах мәсьәләсенә җиңелрәк карый, димме. Калган ике килене рус милләтеннән булса да, бөтен серен миңа сөйли. Без аның белән бик тату, иптәш кызлар кебек.

– Люзия, син бик үк «дөрес булмаган» килен. Гадәттә киленнәр каенаналарыннан зарлана, ә син мактыйсың, – дип шаяртам кабат.

– Миңа эштәге кызлар да шулай, ди. Соң яхшы, безнең өчен җан атып яшәгән кешегә ничек начар мөнәсәбәттә буласың?! Аның безнең тормышка сүз әйткәне юк. Кирәк икән, баланы бакчадан ала, алып бара. Төп ярдәмчебез ул.

Скорняковлар гаиләсендә күңелле мәшәкатьләр: бер бүлмәле фатирларын сатып, зурракны алырга ниятлиләр.

– Яңа фатирга килерсез. Башка ризыклар да әзерләрбез, – дип озатып калды безне сөйкемле, кунакчыл Люзия.

МОНЫ БЕЛҮ ФАЙДАЛЫ!

Кабак A, C, E һәм B витаминнарына бай. Шулай ук аңарда сирәк очрый торган Т витамины бар. Ә ул организмда матдәләр алмашын яхшырта, кан әйләнешен тизләтә. Ябыгырга теләүчеләр өчен бер дигән ризык.

Кабакның йомшак өлеше һәм төшләре бөерләрне чистарта, иммунитетны ныгыта, ашкайнатуны яхшырта. Кабак боткасы температураны төшерә.
Кабакны эч кибүдән җәфаланган, йөрәк авырулары булган кешеләргә ашарга киңәш итәлә. Ул шулай ук халык медицинасында да киң кулланыла: тән өшегәндә, тире кызару күзәтелгәндә, кабакны уып, җәрәхәтле урынга куярга мөмкин. Бүген кабактан ясалган дарулар бөер, үт һәм бәвел куыгы авырулары вакытында, матдәләр алмашы бозылганда кулланыла. Кабакның төшләре цинкка бай, аны чәч кавыклаганда, бетчәләр чыкканда ашарга кирәк. Шулай ук ул бабасырдан профилактика чарасы буларак та кулланыла. ▪

1. Турыйбыз!

2. Ваклыйбыз!

3. Кыздырабыз!

4. Камыр изәбез!

5. Өстибез!

6. Туглыйбыз!

7. Җәябез!

8. Эчлек салабыз!

9. Бөрәбез!

10. Пешерәбез!

PRESSA.RU

Фото: Александр Ефремов

БЕРТУГАННАР

Әлеге язма белән без бертуганнар – кан ягыннан гына түгел, рухи дөньялары һәм уртак эшләре белән дә кардәш булган, республикабызны алга җибәрү өчен кулга-кул тотынышып хезмәт итүче кешеләр турындагы басма матераллар сериясен ачып җибәрәбез.

МАДЬЯРОВЛАР

– Сез безне – Мадьяровларны – артык мактап җибәрмәгез, – дип кисәтә Фәрих Әхмәтович. – Эшлисе эшләр байтак әле. Күбрәк тәнкыйтьләсәгез дә була!

Дөресен әйткәндә, бу киңәшкә бик үк колак саласы килми. Алар турындагы язмаларның һәркайсы диярлек «Татарстанны бөтен дөньяга таныттылар» кебек сүзләр белән башлана. Үзегез уйлап карагыз: күренекле самбочыларның алтысы да бер үк фамилияне йөртә! Бертуган Мадьяровлар – республика гына түгел, бөтен ил горурлыгы. Хәер, келәм өстендәге искиткеч җиңүләре тормыш казанышларының бер өлеше генә әле.

Автор:
Ольга Туманская

Бөтенесе дә... комлыкта башлана! Фәрих Мадьяровны шунда ял итеп ятучы берәү шаярып кына бил алышырга чакыра. Ул самбо буенча Казанның беренче спорт остасы булып чыга. Николай Архиповны егетнең ныклыгы, бөтен көченә аягында басып калырга тырышуы сокландыра. Ул аны үзе йөргән «Динамо» спорт клубына чакыра. Соңрак Фәрихнең кече туганнары да, абыйларының уңышлары белән рухланып, профессиональ спортка тартыла.

Бүген аларның бүләкләре арасында «адашып» бетәргә мөмкин. Спорт казанышларының уртак сандыгында – ил генә түгел, Европа һәм дөнья чемпионатларында ирешкән җиңүләре. Дүрт туган – Фәрит, Нәфикъ, Рәфикъ һәм Нәкыйп – халыкара класслы спорт осталары. Фәрит, гомумән, совет самбосының легендасы! Илнең атказанган тренеры ул, илледән артык спорт остасы, 15 Советлар Союзы чемпионы, берничә дөнья чемпионы тәрбияләп чыгарган. Үзенең кече туганнары да – шул «йолдызлар» арасында.

Бүген Фәрит Әхмәдиевич туган җиреннән еракта, Төркиядә яши һәм эшли: хатынының сәламәтлеге өчен гаиләләренә климатны алыштырырга туры килгән.

ДУСЛАР ҺӘМ КӨНДӘШЛӘР

– Химиклар мәдәният сараена йөргәндә без менә шундыйларда шөгыльләнә идек! – ди Фәрих Мадьяров, сырган маталарга күрсәтеп. – Күнегүләрне тәмамлыйбыз да, җыеп, өеп куябыз – бездән соң шөгыльләнүче волейболчы егетләргә урын бушатабыз. Бөтенроссия турнирында җиңеп чыккач кына, безгә чын келәм бирделәр!

Абыйлы-энеле Мадьяровлар – Фәрих һәм Нәфикъ белән без Большие Ключи авылында очраштык. СССР чемпионатлары призеры Нәфикъ Әхмәдиевич үзенең агрофирмасын нәкъ менә биредә ачкан. Куркаләр үрчетә, Татарстанны ит белән генә түгел, ысланган ризыклар, колбасалар белән дә тәэмин итә. Уңайлы йортлар – цехлар арасында бер бина аерылыбрак тора, самбо белән шөгыльләнү өчен кечкенә генә спорт залы ул.

– Бүген бирегә авылның илле егете йөри, – дип сөйли Нәфикъ Мадьяров. – Юк-юк та, үзем дә кайчак көрәш костюмнарын киеп куям.

Зал стенасын портретлар бизи. Аларда – самбочы Мадьяровларның яшь чаклары, әнә, күпсанлы бүләкләре белән төшкәннәре дә бүгенге яшь спортчыларга үрнәк булып торалар. Без сорагач, бүген дә ялындырып тормадылар – рәхәтләнеп көрәшеп күрсәттеләр.

Сүз уңаеннан, спорт ярышларында Мадьяровларга бер-берсенә каршы басарга да туры килгәләгән. Күнегүләр вакытында гына түгел, зур ярышларда да. Мәсәлән, 1982 елда Донецкида узган СССР Кубогы финалында Нәфикъ белән Рәфикъ бер-берсенә каршы көрәшкән. Моңа кадәр ярты ел элек Рәфикъ СССР чемпионатында җиңү яулаган, ә Нәфикъ бронза призеры булган. Ә Кубок өчен көрәштә Нәфикъ көчлерәк булып чыккан.

Бүген ул 70нче еллар азагында Дзержинскида узган ярышлар вакытында Рәфикъ белән икәүләп чак кына чып-чын җәнҗалга юлыкмый калуларын елмаеп искә төшерә. Күз алдына китерергә дә куркыныч: утыз самбочы шулчаклы ук боксчыга каршы! Ызгыш, гадәттәгечә дип әйтикме, кызлар аркасында килеп чыккан – безнекеләр аларны якларга маташкан. Бәхеткә, каршылыкны тыныч юл белән хәл итә алганнар.

– Без Рәфикъ белән әллә ни озын буйлы түгел идек. Бервакыт трамвайда хулиганнар бәйләнде. «Җавап бирергә» туры килде инде. Икәү дүрт кешегә каршы! Ә җиңү барыбер безнең якта булды.

Бу ике туганның язмышлары да, исемнәре кебек үк, охшаш. Рәфикъ –

оста эшмәкәр, электр товарлары кибете хуҗасы. Абыйсы кебек үк, яраткан спорт төрен исеннән чыгармый. Аны онытырга мөмкин дә түгел – Татарстан Республикасының самбо федерациясе вице-президенты бит ул.

ҖИҢЕЛҮЛӘР ИСТӘ КАЛА...

Әмма Мадьяровларның гаилә тарихында фаҗигале битләр дә бар. Иң кече энеләре Нәкыйп дөньядан бик иртә китә. СССР чемпионы, Европа призеры... Тагын күпме медальләр һәм кубоклар яуланмый кала... Уйламаганда килеп чыккан автоһәлакәт күпме җиңүләрнең юлын кисә...

– Нәкыйп күп тапкырлар СССР Кубогы иясе, дөнья чемпионы Евгений Есинның кабатланмас, аңа гына хас «авырттыргыч алым»ына каршы тора алган бердәнбер көрәшче иде, – дип сөйли Фәрих Әхмәтович. – Есин еш кына стойкада җиңелә иде. Шулчакта үзенең әлеге алымын кулланып өлгерә алса, көндәшен җиңде, дигән сүз. Нәкыйпне генә сындыра алмады. Без, Татарстан көрәшчеләре, нигездә, авылдан чыккан кешеләр. Нәкыйп тә кәҗә сөте эчеп үсте. Сөякләре нык, сыгылмалы иде – ярышларда бу аңа нык ярдәм итте.

Келәмдә Нәкыйпнең иң атаклы көндәше, мөгаен, Владимир Путин булгандыр. Дөрес, ул чакта Путин әллә ни билгеле кеше булмаган. 1982 елда СССР Кубогына көрәштә Мадьяров аз гына өстенлек белән аны җиңүгә ирешкән. Фәрих Әхмәтович уенча, энесе ул көрәшне, бәлки, хәтерендә калдырмагандыр да, күбрәк сине җиңгән кешеләр истә

Фото: Александр Ефремов.

кала бит. Ә Путин кече Мадьяровны онытмаган, дип сөйлиләр. Казанга килүендә дә аны искә алган булган.

ЭШЛӘРГӘ КИРӘК!

– Нәкыйп белән Нәфикънең СССР Кубогыннан җиңүчеләр булып кайтуын хәтерлим, – дип сөйли Фәрих Әхмәтович. – Рәфикъ Париждан көмеш алып кайтты. Ә бездә – Сабантуй! Көрәшергә чыктылар да... җиңелделәр. Янәшәмдә Фикрәт Тәбиев утыра иде, гаҗәпләнде: ничек инде, Мадьяровлар – чемпионнар, ә бәйрәмдә җиңә алмыйлар?! Мин аңа болай аңлаттым: көрәш – көрәш инде, авыл татарларының канында ул. Сабантуй бәйрәмнәрендә мәйданга көчле көрәшчеләр чыга – кайчандыр безнең эти дә шулай чыга иде.

Бертуган Мадьяровлар Арча районының Байкал авылында туып-үскән. Ә ерак түгел урнашкан Яңа Кенәр – зур авыл. Байкал бүген таралып беткән диярлек, Яңа Кенәр яши әле. Аны саклап калырга кирәк – СССР чемпионы һәм самбо буенча тәҗрибәле тренер Фәрих Мадьяровның максаты шундый.

– Авыл кешеләре бетсә, көрәшчеләр дә бетә, – дип авыр сулый ул. – Юк бит хәзер андыйлар! Балалар йомшак, зәгыйфь булып үсә, күп утыралар, аз эшлиләр, аз хәрәкәтләнәләр.

Авылны ничек саклап калырга? Бу өлкәдә Фәрих Мадьяровның төгәл планы бар. Беренчедән, анда кәҗә һәм күркә фермасы ачарга, комбиазык цехы оештырырга кирәк. Эш булса, кешеләр дә читкә китмәячәк. Ә үсеп килүче буын өчен Мадьяровлар үзенең көрәш залы һәм мини-футбол кыры булган үсмерләр клубы ачачак. Хәер, мондый планнарны алар һәр районда, шулай ук Казанда да тормышка ашырырга тели, теләктәшләр генә табасы бар. Тренер итеп үзе белән бергә энекәше Рәшитне алып килергә исәпли – ул танылган көрәшче генә түгел, тәҗрибәле остаз да. Фәритнең уллары Артур белән Гадел дә – спорт осталары. Дәвамчылар бар, оештырырга гына кирәк.

– Балалар белән эшләмәсәк, самбоны күтәрә алмаячакбыз. Күпме боз сарайлары ачтылар, көрәш заллары да ачып булмыймыни? Адыгеяда андый заллар һәр авылда диярлек бар, шуңа күрә көрәшчеләре дә барлык ярышларны гөр китерә.

Фәрих Әхмәтович кайчандыр Татарстанның да самбо дөньясын шаулатып торуы, 90нчы елларда республиканың халыкара ярышларда аерым команда булып чыгыш ясавы һәм призлы урыннар яулавы турында сөйли.

– Әйе, җиңүләребез һәм медальләребез күп булды, әмма үзебездән соңгы буыннарга нәрсә калдырачагыбыз, мөгаен, мөһимрәктер, – диде Фәрих Мадьяров саубуллашканда.

PRESSA.RU

АУТИСТЛАР ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ: **БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР**

«Алты яшьлек улым меңгә кадәр саный, куша, ала, ләкин олы йомышын үти белми. Син аннан бер нәрсә сорыйсың, ә ул икенче нәрсә җавап бирә. Шулай булгач, аның меңгә кадәр санавыннан ни мәгънә?! Иң кирәкле әйберләрне дә эшли алмагач…»

Иллюстрация: «Человек дождя» фильмыннан кадр

Автор:
Руфия Фазылова

Бу дүрт бала анасы Анна Петрова сүзләре. Өченче уллары Димада аутизм чире. Башта ата белән ана балаларының бу сәерлеген күрмәмешкә салышкан. Янәсе, могҗиза булыр, узар әле… Көннәрдән бер көнне Анна аңлый: үзеңне күпме алдарга була? Диманың яше бара, ә малай җәмгыятьтә яраклашмаган. Болай булса, аның белән урамга чыгарга да куркыныч…

«БЕР ЯШЬКӘ КАДӘР БАР ДА ЯХШЫ ИДЕ»

Мин килгәндә Дима өйдә юк, махсус үзәккә укырга киткән иде.

– Ярты сәгатьтән кайтып җитә, – диде ана кеше.

Анна Петрова алты ел эчендә аутистлар тормышын шулкадәр нык өйрәнгән ки, үзе психолог, табиб, хокук белгеченә әйләнгән. 2016 елда «Просто другие» исемле оешма төзегән ул. Рәсми теркәлү узганнар. Оешманың беренче максаты – баласында аутизм чире булган ата-аналарны берләштерү. Икенчесе – проблемаларны уртага салып сөйләшү, авыру балалар өчен махсус программалар булдыру.

– Анна, Диманың бүтәннәрдән аерылып торганын кайчан аңладыгыз? – дим.

– Өч яшендә төгәл диагнозны белдек. Бер яшь тулганчы, Дима нәкъ башкалар кебек үсте: уйнады, төрле авазлар әйтте, хәрәкәтләргә җавап бирде. Бер яшь тулгач, барысы да кисәк кенә үзгәрде: күзгә карамый, эндәшсәң, җавап бирми. Ул яшьтә балалар күзгә күренеп үзгәрә бит, көн саен яңа шөгыльләре барлыкка килә. Ә безнең, киресенчә, артка китеш башланды. Шуннан улыбызның колакларын, күзләрен тикшерттек. «Ишетми ахры ул, тавышка җавап бирми», – дибез. Бер белгечтән икенчесенә җибәрделәр. Иң соңыннан гына психиатрда булдык. Дөресен генә әйткәндә, күңелдә шик бар иде инде…

Шулай да ата-ана иң соңгы мизгелгә кадәр бу уйдан ерак булырга тырыша. «Юк, минем бала сау-сәламәт», – дип, үз-үзен алдый. Бу кешенең психологиясе белән бәйле, проблемадан качарга теләү. Ләкин Петровларга «алсу» күзлекләрен салырга туры килә: табиблар Димага «аутизм» диагнозы куя. Әмма ата белән ана барыбер әле проблеманың ни дәрәҗәдә тирән икәнен аңлап җиткерми булса кирәк, гамьсез генә өйләренә кайтып китә. Мөстәкыйль рәвештә улларын кеше итә алырбыз, укытырбыз, дип өметләнә…

Аутистларның төп үзенчәлекләре – күзгә карамыйлар һәм күнегелгән бер үк эшне эшлиләр. Мисал өчен, бала уйнарга гел бер юлдан йөри, әгәр аны икен-

Фото: Лилиана Вәлитова

йөртү таныклыгы ала алмаячак, банкта кредит бирмәячәкләр...

– Аутизм чире белән очрашкан ата-аналарның күбесе башта шулай уйлый, – ди Анна. – Юләрлек инде бу, моны хәзер генә аңлыйм. Соң яхшылап сөйләшә алмаган, кеше белән аралаша белмәгән балага машина йөртү таныклыгы нигә кирәк? Кем аңа кредит бирсен?! Миңа бүген бу кызык та, кызганыч та тоела. Машина йөртү таныклыгындамы хикмәт? Бала үзен җәмгыятьтә тота белсен, мөстәкыйль рәвештә киенсен, ачык итеп сөйләшсен. Ә безнең Дима алты яшенә кадәр зур йомышын астына йомышлады. Сорауларга анык җавап бирми. Һәм шушы баланы без сау дип йөрибезме?

Анна Петрова республикада булган тернәкләндерү үзәкләрен барлап чыга, яхшы табибларга языла. Шунда йөргәндә аутист бала тәрбияләүче ата-аналар белән таныша. Бер-берсенә тәҗрибәләрен сөйлиләр. Әнә шул чакта махсус оешма төзү идеясе туа да.

ЧИШЕНМИЧӘ, ИСӘНЛӘШҮ ЮК!

Дима озак көттермәде, кайтып җитте. Малайга декабрьдә җиде тула икән. Беренче карашка Дима башкалардан аерылмый кебек, бик сөйкемле бала.

че сукмактан алып китсәң, ул елый, бәргәләнә башлый. Бу сәер гадәтләр Димада да була. Анна улының тагын бер үзенчәлеге турында сөйләде:

– Диманың яраткан эше – лифт төймәсенә басу иде. Әгәр төймәгә икенче кеше басса, бетте. Подъездда елый башлый. Яңадан лифт чакыртырга мәҗбүр була идек. Тагын бер мисал: чалбарының төймәсе төшкән, ди. Дима шуны күреп ала да үрсәләнә. Төймәне урынына такмыйча, тынычланмый... Бу хәлләрдән тәмам арып, балабыз өчен ут йотып йөри башладык. Хәтерлим, Димага биш яше тулган көнне шәм яндырдык. Әлбәттә, ул аны сүндерә белмәде. Шунда үзем өчен әйттем: «Җитте, иртәгәдән яңа тормыш башларга кирәк!»

Биш яшькә кадәр Дима психиатрда да теркәлмәгән була. Ата белән ана балаларының исәптә торуларын теләмиләр. Янәсе, үскәч машина

PRESSA.RU

– Бездә кунак апа бар, исәнләш, – диде Анна улына.

Әмма Дима мине күрмәмешкә салышып, башта киемен элеп куйды. Аннан соң яныма килеп исәнләште. Чынлап та, Дима күзгә карамый икән, карашын гел читкә ала. Ә сөйләшүе бик матур, бөтен авазлары да төзек.

– Ничә яшендә сөйләшә башлады ул? – дим ана кешегә.

– Улыбызның сөйләме соңгы бер елда камилләште, – диде Анна. – Өч яшенә кадәр авазлар гына әйтте. Әлбәттә, шөгыльләнмәгән булсак, болай да сөйләшмәс иде.

Диманы күзәтәм: тыныч ул. Кулына уенчыгын тоткан килеш бүлмәләрне карап чыкты. Бу аның гадәте икән: бар нәрсә дә тәртиптәме?

– Аутистлар тәртип, пөхтәлек ярата, – дип сөйләде Анна. – Мисал өчен, ике зур кызым артларыннан әйберләрен җыештырып калдырмаска мөмкиннәр, ә Дима һәрвакыт урынына куя. Аллага шөкер, улыбыз урамда үзен дөрес тотарга да өйрәнде. Хәзер лифт төймәсенә икенче кеше басса да, еламый. Әле киресенчә: «Сез басыгыз», – дип кешеләргә әйтә. Элек безне еш күргән кешеләр: «Дима ничек шулай яхшы якка үзгәрде?» – дип гаҗәпләнә. Боларның барысына да зур тырышлык бәрабәренә, яхшы белгечләр ярдәме белән ирешелде.

Аутистны нәрсәгәдер өйрәтү өчен, бик зур тырышлык кирәк икән. Сау бала өчен кул юу, киенү-чишенү гадәти булса, аутистка моңа өйрәнү өчен атналар, айлар таләп ителә. Һәр адымны кат-кат аңлатырга, аны бергә кабат-кабат эшләп карарга кирәк. Шунсыз булмый.

– Элек кая барсак та, Дима таныш булмаган кешеләрне кочаклый иде, – дип сүзен дәвам итте Анна. – Безнең белән гел кочаклашып торгач, чит кешеләрне дә шулай итәргә кирәк, дип уйлый. «Алай ярамый, якын кешеләр белән генә кочаклашалар», – дип, күп тапкыр аңлаткач, бу гадәтен ташлады. Бик нечкә күңелле бала ул, хайван, бөҗәкләрне ярата.

Алты яшендә Дима китаплар укый, меңгә кадәр саный. Ләкин укыган әйберен сөйләп бирә алмый. Сау балага бик җиңел тоелган әйберләр аутистлар өчен гаять катлаулы булырга мөмкин. Әйтерсең, аларда инстинкт юк.

Диманың иң яраткан кешесе сеңлесе Лена икән. Кызчыкка ике яшь. Алар бергә уйныйлар. Дима үзен абый итеп тоямы, сеңлесен яклый, уенчыклар алып килеп бирә.

– Көмәнле икәнемне белгәч, каушап калдым, – ди ана кеше. – Дима шундый булгач, тагын бала тәрбияләргә вакыт калырмы, сау булырмы, дип борчылдым. Тик ирем Владислав начар уйларга урын калдырмады: «Димәк Аллаһы Тәгалә шулай куша! Син үзең генә түгел, ә без ни өчен?» – диде. Ул яктан мин чиксез бәхетле, күз генә тимәсен. Ирем бик ярдәм итә. Ә Димага мөнәсәбәте... гаҗәп. Миңа калса, ул башкаларга караганда да аны күбрәк ярата.

– Диманың тулы, ярату булган гаиләдә үскәне күренеп тора. Усаллыгы юк, – дим.

– Әйе, улыбызда агрессия юк, чөнки туктаусыз эш алып барабыз. Әтисенең дә тәрбиясе зур. Безнең оешмага төрле хатын-кызлар мөрәҗәгать итә. Ирләре ташлап киткәннәре дә байтак. Сер түгел, авыру бала туса, ир-ат проблемадан качу ягын карый – гаиләдән китә. Бу иң җиңел юл бит. Ә әтиебез балалар дип яши. Димага күпме акча киткәнен үзебез генә беләбез. Дәресләр, төрле үзәкләрдә уку – барысы да түләүле. Кызганыч, аутист балалар дәүләт тарафыннан якланмаган. Ата-ана үзе кайгыртмаса, бала мәктәпкә кадәр өйдә утырырга мәҗбүр. Балалар бакчасына йөрүдән файда күрмим, аларга анда игътибар юк. Ала каргалар янында кара карга булып ялгызы читтә утыра инде. Без гади бакчага тугыз ай йөрдек, аннан баш тарттык. Әлегә республикада аутистлар өчен балалар бакчасы юк. Тик без бу юнәлештә эшлибез, киләчәктә андый проблема булмас, дип өметләнәм.

ПАРТА АРТЫНДА – САУ БАЛАЛАР БЕЛӘН

Казанда мәктәпкәчә яшьтәге аутист балалар өчен берничә үзәк бар. Алар нигездә балаларның акыл үсешен арттыруга юнәлтелгән, укырга-язарга, рәсем ясарга өйрәтәләр. Шулай ук үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен дә сеңдерәләр.

Мондый үзәкләрнең күбесе түләүле. Әле ун-унбиш ел элек аутист балалар мәктәп яшенә кадәр өйдә утырган булса, бүген алар шундый үзәкләрдә шөгыльләнә.

– Аутист баласы булган ата-анага бик авыр, – дип сөйләде «РАСкраска» үсеш үзәге мөгаллиме Полина Слесаренко. – Сау балалар өлкәннәрдән карап барысын да кабатласа, аутистларны һәр нәрсәгә кулларыннан тотып өйрәтергә кирәк. Монда бер сәгать шөгыльләнү генә җитми.

Аутистлар тормышы белән күбрәк танышкан саен шуны аңлыйсың: барысы да ата-ана тырышлыгыннан тора. Могҗиза көтеп, бернәрсә дә эшләмичә, авыру балаң белән өйдә генә утырсаң, булмый! «РАСкраска» үзәгенә дә үсеш дәрәҗәсе төрле булган балалар килә икән. Берәүләр биш яшенә бер сүз әйтә алмаса, икенчеләр тулы җөмләләр белән сөйләшә.

– Безнең иң төп бурыч – аутист балаларны сөйләшергә өйрәтү, – ди Полина Слесаренко. – Рәсемнәргә генә карап аңлатучы, ишарәләр белән генә сөйләшүче малай-кызлар да бар. Мисал өчен, ата-ана иртән баласына рәсем күрсәтә: анда малай тешен чистарта. Бала да шуны кабатлый. Аннан икенче рәсем: бала ашый, өченче рәсемдә ул уйный... Әйе, аутистлар өчен бу дөрес методика, чөнки алар бөтен әйберне күреп, карап кабул итә. Тора-бара ул рәсемдәге әйберләрне автоматик рәвештә эшли башлый. Бала үсә, өеннән кеше арасына чыгарга тиеш була. Анда аңа кем рәсем күрсәтеп утырсын? Менә шуңа да бала башкалар кебек аралашырга, үзен яшьтәшләре кебек тотарга тиеш. Әлбәттә, бу бер дә җиңел түгел. Үзәккә беренче тапкыр килгән ата-аналарга: «Бергә эшләсәк кенә, нинди дер нәтиҗәләргә ирешеп була», – дим. Юкса кайбер ата-аналар, мәктәп яшенә җиткән баласын китереп куя да: «Минем балам сәламәт яшьтәшләреннән аерылмасын», – ди. Ә үзенең бернәрсә эшлисе дә килми. Андыйларны хәтта кире борабыз. Алты-җиде яшенә кадәр сөйләшә дә белмәгән баланы ничек итеп санаулы көн эчендә «сәламәт яшьтәшләреннән аерылмый торган» итәсең? Бу мөмкин түгел! Моның өчен еллар, ә бәлки, бер гомер кирәк булыр. Һәм үзәктә шөгыльләнү генә җитми, өйгә кайткач, монда уздырылган күнегүләрне яңадан кат-кат эшләмәсәң, нәтиҗәсе юк диярлек...

Яңа уку елы башыннан Казанда беренче тапкыр аутист балалар өчен ресурс класслар ачылды. Башкаланың 1, 65, 97, 156, 168нче номерлы мәктәпләрендә бар ул. Андый классларда барлыгы 17 аутист бала белем ала. Балалар тәнәфесләрдә башкалар белән бергә уйный, аралаша. Һәр укучыга аерым тьютор билгеләнгән. Алар балаларны көн дәвамында күзәтә, дәресләрне аңлата. Дөрес, барысын да түгел.

– Безнең балалар кайбер дәресләрне сау яшьтәшләре белән бергә укый, – диде ресурс сыйныфларның кураторы Светлана Шимшек. – Мәсәлән, рәсем, физкультура гел бергә. Ә аерым фәннәрне баланың үсешенә, сәламәтлегенә карыйбыз. Кайбер балалар математиканы яхшы белә, андыйлар яшьтәшләре белән укый. Татар теле, инглиз теле авыррак бирелә, чөнки аутистларга гуманитар фәннәр, сөйләп аңлату кыенрак. Мондый очракта укучы белән тьютор шөгыльләнә.

– Сау балаларның ата-аналары ресурс классларга каршы булмадымы? Яшерен-батырын түгел, аутистларда тик торганнан агрессия барлыкка килергә мөмкин, – дим.

– Юк, каршы килүче булмады. Беренчедән, ресурс классларда укучы малайлар һәм кызлар махсус комиссия аша уза, аларның эмоциональ халәтен тикшерәләр, җәмгыятькә яраклашканмы, сөйләшә аламы һ.б. Безнең балаларның акыл үсеше әйбәт, янәшәдәге балаларга куркыныч тудырмыйлар. Араларында гаҗәеп акыллы балалар бар. Мәсәлән, 1нче мәктәптә укучы кыз бала инглиз телен камил белә, ә 97нче мәктәптә укучы малай минут эчендә фотоаппаратны сүтеп җыя. Өченчесе бик оста рәсем ясый. Бу балалар сау-сәламәт яшьтәшләреннән бик күп нәрсәгә өйрәнә: башкалар белән ничек аралашырга, уйнарга һ.б.

...Россиядә, шул исәптән безнең республикада да, әлегә кадәр аутист балалар сигезенче төркемгә караган коррекцион мәктәптә белем алган, холыкларында агрессия булганнар исә өйдә укыган. Бу 17 бала – беренче карлыгачлар. Яңа алым нәтиҗәле булыр, дип ышанасы килә. Мөмкинлеге чикле балаларны сау яшьтәшләре белән бергә укыту, минемчә, начар түгел. Беренчедән, бу очракта сәламәт балаларда башкаларга карата ихтирамлы булу, ярдәм итү кебек төшенчәләр мәктәп эскәмиясендә үк тәрбияләнә. Икенчедән, бездә авыру балаларга аерым бер ярлык тагып куялар: «син авыру». Нәтиҗәдә, ул гомер буе ата-анасына йөк булып яши, җәмгыятьтә үз урынын таба алмый. Ә болай, кечкенәдән бергә үсеп, укып, бәлки мөмкинлеге чикле бала үзен башкача тота башлар. «Әйе, мин үзгә, тик бу әле киртә түгел!» – дияр. Чит илләрдә андый ярлык тагулар юк. Гаиләдә сау булмаган бала туса, ата-ана аңа сабый чактан ук сеңдерә: «Без гомерлек түгел. Син бездән соң мөстәкыйль яшәргә тиешсең. Моның өчен хәзердән үк бөтенесен үзең эшлә...» Ә бездә өлкәннәр, картайганчы, авыру баласын кайгырта, нәтиҗәдә үзләренең тормышлары да, баланыкы да сыкранып уза. Ә бит сыкранып кына хәлне яхшы якка үзгәртеп булмый. Өйрәнергә, яшәү өчен көрәшергә кирәк.

БУ КЫЗЫК!

Бүгенге галимнәр дөньякүләм танылган кешеләр арасыннан Альберт Эйнштейн, Амадей Моцарт, Исаак Ньютон, Чарльз Дарвинда аутизм чире булган, дип саный.

Елена Мирскова, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының балалар баш психиатры:

– Баласының үсешендә алга китеш булмаган ата-ана кайсы гына белгечкә бармый, тик психиатрга күренми. Моңа бәлки артык гаҗәпләнергә дә кирәкмидер: аутистлар турында мәгълүмат аз. Ата-ана бу турыда уйлап та карамый.

Бүгенге көндә республикада унсигез яшькәчә 300дән артык аутист бала исәпләнә. Ләкин аларның саны төгәл түгел. Кайбер ата-аналар, балаларына диагноз куелгач та, психиатрга исәпкә куелмый. Шулай ук төгәл диагнозны белмичә яшәүчеләр дә бар. Әйе, ата-ана баланың сәерлеген (мисал өчен, ялгызлык ярата, уенчыклар белән түгел, кәгазь савытлар белән уйный һ.б.) белсә дә, күрмәмешкә салыша. Аутист балаларның иң төп билгесе – сөйләм телендә тоткарлыклар.

Бүгенге көнгә кадәр әлеге чирнең кайдан килеп чыкканын төгәл генә әйтеп булмый. Әйе, генетик фактор зур роль уйный, йөклелек чоры ничек узган, бала туганда кыенлыклар кичермәгәнме – барысы да мөһим. Тик аларга гына бәйле түгел.

Бер яшендә бала күзгә карамый, авазлар әйтми, гомумән, башка балалардан аерыла икән, психиатрга күренергә кирәк. Чирне иртәрәк белеп, балага дәвалау курсы, дөрес юнәлеш биргән саен, яшьтәшләреннән калышмаска мөмкинлеге күбрәк аның. Т

PRESSA.RU

Артур Әдиятуллин, «Әдиятуллин һәм партнерлар»ның идарә итүче партнеры

ЮРИСТЛАР ПРЕДПРИЯТИЕ АКТИВЛАРЫН ЭКОНОМИЯЛӘДЕ

Квалификацияле юридик ярдәм – предприятие активларын экономияләү һәм шулай ук хокук бозулардан саклануның нәтиҗәле ысулы.

Бизнесның куркыныч астында калу очраклары күп, эшмәкәрләр намуссыз контрагентларга, күзәтчелек итүче органнарның башбаштаклыгына юлыга, бик еш кына үзләре дә экономик югалтуларга китерә торган юридик хаталар ясый.

Мисал китерәм: йөк ташу белән шөгыльләнүче транспорт оешмасы йөк артык төялгән өчен ике тапкыр административ җаваплылыкка һәм гомуми суммасы 750 мең сум тәшкил иткән штрафка тартылган була. Юристларның вакытында ярдәм күрсәтүе аркасында компания гаепсез дип табыла һәм штрафтан азат ителә.

Икенче бер очракта эшмәкәр килешенмәгән килеш кибетен яңартып кора һәм аны арендага бирә. Башкарма комитет законсыз объектны сүтү турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать итә. Ә юристлар законлы юл белән вакытны оталар (заказчы, кибетен арендага биреп, керем алуын дәвам итә), яңартып кору өчен кирәкле документларны рәсмиләштерә. Кибетне сүткән очракта эшмәкәрнең югалтулары бик зур булыр иде.

Контрагент килешүләрен тикшергәндә, клиентларыбыз өчен зыянлы, авыр аңлашыла торган, яшерен өстәмәләр кертелгән шартларга юлыгасың. Мондый килешүләргә кул куеп, компания үз өстенә өстәмә йөкләмәләр ала, эшен куркыныч астына куя, бәхәс килеп чыккан очракта судта отылырга мөмкин.

Нәтиҗә: бизнес югары сыйфатлы юридик ярдәмгә мохтаҗ. Кызганыч ки, эшмәкәрләр моны бик соң, мәсьәләне хәл итү авырлашкач яисә бөтенләй мөмкин булмагач кына аңлый.

Бизнеста юридик һәм хисап эше индивидуаль якын килүне һәм профессионалларны җәлеп итүне сорый.

ӘГӘР СЕЗ ТҮБӘНДӘГЕ ПРОБЛЕМАЛАРГА ЮЛЫКСАГЫЗ:
- ЮХИДИ, САЛЫМ ИНСПЕКЦИЯСЕ һ. Б. ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫ ШТРАФ САЛСА
- КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕКНЕ РӘСМИЛӘШТЕРӘ АЛМАСАГЫЗ
- ПРЕДПРИЯТИЕНЕ АЧАРГА, ЯБАРГА, ҮЗГӘРТЕРГӘ, ЮККА ЧЫГАРЫРГА ЯКИ БАНКРОТЛЫК ИГЪЛАН ИТӘРГӘ ТЕЛӘСӘГЕЗ
- ПРЕДПРИЯТИЕГЕЗДӘ ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ЯХШЫ ХИСАПЧЫ ЯИСӘ ЮРИСТ ТАБА АЛМАСАГЫЗ
- СУДКА ЯКИ ДӘҮЛӘТ ОРГАНЫНА ЧАКЫРУ КИЛСӘ
- КОНТРАГЕНТЛАР ТҮЛӘМӘСӘ

«ӘДИЯТУЛЛИН ҺӘМ ПАРТНЕРЛАР» БАРЛЫК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕГЕЗНЕ ХӘЛ ИТӘРГӘ БУЛЫШЫР!

«ӘДИЯТУЛЛИН ҺӘМ ПАРТНЕРЛАР»
Казан, Гладилов ур., 27, керү – ишегалдыннан, 2 кат, 426 офис.
Телефоннар: 8 (843) 253-53-44, 8-903-305-53 44

Реклама

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама 16+

Реклама бүлеге:

тел: (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге:

тел: (843) 222-06-05

КРЕДИТ РЕФИНАНСЛАУ:
ЭКОНОМИЯЛӘҮНЕҢ РЕАЛЬ МӨМКИНЛЕГЕ

Берләшкән кредит бюросы мәгълүматларына караганда, 2017 елның беренче яртысында Россиядә яңа кредитларның яртысыннан күбрәге элеккеге кредитларны каплауга юнәлтелгән. Күпчелек экспертлар фикеренчә, хәзер рефинанслау өчен уңайлы шартлар тудырылган: кредит ставкасын 2–7 пунктка киметергә мөмкин. Рефинанслау кем өчен файдалы һәм моның үзенчәлеге нәрсәдә? «Казанский» операция офисы башлыгы Марат Хасиятуллин белән «Татарстан» шул хакта әңгәмә корды.

– Бүгенге көндә кредитларны рефинанслауга сорау ни дәрәҗәдә?

– Кредитны рефинанслау – 2017 елда клиентларга хезмәт күрсәтүнең алдынгы төре. Бу аңлашыла да: 2014-2015 елларда зур процентлар белән кредит алучылар бүген хәлләрен җиңеләйтергә тели. Мәсәлән, Татарстанда элеккеге бурычларны өлешчә яисә тулысынча каплау өчен алынган яңа акчалата кредитлар 2017 елның беренче яртысында 55%ны тәшкил итте. Банк буенча тулаем алганда, сентябрь аенда гына да рефинанслау кысаларында 50 млн сум акча бирелгән, бу безнең планлаштырган күрсәткечләрдән берничә тапкыр артык. Ә Татарстанда рефинанслауның икенче аенда ук моңа таләпнең ике тапкырга артуы күзәтелде.

– Кредит рефинанслау кем өчен файдалы?

– Рефинанслау кредит ставкасын уртача ике-өч пунктка төшерергә мөмкинлек бирә, ә аерым очракларда экономия биш-җиде пунктка кадәр җитәргә мөмкин. Билгеле, һәр очракны аерым карарга кирәк. Мәсәлән, клиент бер ел элек 36 айга елына 25% ставка белән 200 мең сум кредит алган, ди. 12 айдан соң аның 153 мең сум түлисе калган. Ул 24 айга 17% ставка белән кредитын рефинансларга уйлый. Бу очракта экономия 58 мең сум тәшкил итә.

– Кредитны рефинанслау өчен бирелә торган акчаның уртача суммасы күпме?

– Исәпләп чыгарганнан соң, клиентларның кредит рефинанславының уртача суммасы якынча 350-400 мең сум тәшкил итүе аңлашылды.

– Кагыйдә буларак, банклар башка банклардан алынган кредитларны җиңелрәк рефинанслый. Шундый ук югары ставка белән кредит алган бүгенге займ хуҗаларына ни эшләргә? Икенче банк эзләргәме?

– Андыйларга банк гадәттә яңадан кредитлау тәкъдим итә. Мәсәлән, без клиентка яхшырак шартлардагы индивидуаль тәкъдим рәсмиләштерәбез. Бу очракта ул зур суммада кредит ала, элеккеге бурычын каплый, калган акчасын үз карамагында файдалана ала.

«УБРиР» КБ ГАЖ, лицензия № 429, 06.02.2015 ел.
Фото «УБРиР» КБ ГАЖнән алынды. Реклама.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Казан ханлыгына нигез **КАЙЧАН** салынган

Россия тарихында татар тарихы **НИНДИ** урын тота

Хуҗа Хәсән авылы **КАЙЧАН** оешкан

Китап киштәсендә **НИЛӘР** бар

Татарстанча «хюгге» **КАЙСЫ** районда «яши»

КАЗАН ХАНЛЫГЫ

Казан Кремле территориясе. Ханнар төрбәсе.

Алтын Урда таркалганнан соң чагыштырмача кыска – 100 елдан бераз гына артыграк вакыт эчендә яшәп калган бу дәүләтебез Идел-Урал төбәкләрендә таралып утырган мари, чуваш, удмурт, мордва һәм башкортлар тормышында да тирән эз калдырган. Ханлык чорында Идел буе татарларының халык буларак формалашуы тәмамлана. Язмышның төрле борылышларына, фаҗигаләренә карамастан, милләтебез татар исемен бүгенгегә кадәр саклый.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Казан ханлыгы тарихы яхшы өйрәнелгән дип әйтмәс идем. Мирасханәләрдә сакланып калган язма чыганакларыбызның күбесе рус елъязмаларыннан гыйбарәт, бу документлар исә ул замандагы рус-татар мөнәсәбәтләрен объектив яктырта дип әйтеп булмый. Борынгы архивларыбызны 1552 елгы фаҗигадән соң максатчан рәвештә юкка чыгарганнар – гасырлар буена татарны тарихсыз һәм динсез калдырып, рус милләте составында «эретеп» бетерү сәясәте алып барылган.

ХАНЛЫККА КАЙЧАН НИГЕЗ САЛЫНГАН?

Менә шул чыганакларыбызның ярлы булуы аркасында, хәтта Казан дәүләтенең кайчан барлыкка килүен дә төгәл генә әйтә алмыйбыз. Ханлыкка 1437 яки 1438 елда Кырымнан куылган Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәд тарафыннан нигез салынган, дип әйтә кайбер тарихчылар. Рус елъязмаларында һәм фәндә билгеле башка тарихи чыганакларда Олуг Мөхәммәднең Казанга килүе турында берниндимәгълүмат булмаса да, бу фикер фәндә киң таралган («Татар энциклопедиясе»нең 3 нче томы – авт.). Ә бит Воскресение һәм Никон елъязмаларында, Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүт 1445 елда Казанны алды, аның идарәчесе Алимбәкне (Либейны) үтереп, үзе патшалык итә башлады, дип ачыктан-ачык язылган. Димәк, Казан билегендә (кенәзлегендә) тәхеткә Алтын Урдадан, Җүчиләр нәселеннән чыккан идарәче килә. Шулай икән, Казан ханлыгының тарихын 1445 елдан башлап җибәрү дөреслеккә күбрәк туры килә, минемчә.

Әмма ханлыкны нигезләүдә Олуг Мөхәммәднең ролен дә киметеп күрсәтергә ярамый – «яңа» дәүләт, ихтимал, аның «проекты» буенча төзелгәндер. Татарларның кайбер риваятьләрендә Олуг Мөхәммәд Казанның беренче ханнары арасында санала, «Яңа Казанны салганда, аның беренче ханы Алтынбәк, икенчесе – Алимбәк, өченчесе – Мөхәммәд, дүртенчесе Мәхмүтәк булган», – диелә. Игътибар иткәнсездер: хәтта риваятьләрдә дә Олуг Мөхәммәд дәүләткә нигез салучы дип аталмаган.

Тик монда бер сорау килеп туа. Ханлыкка кадәр яшәгән Казан билеге дә дәүләт бит инде ул – Болгарның дәвамчысы. Олуг Мөхәммәд улы Мәхмүт ул дәүләтне 1445 елда нигезенә кадәр җимер-

«Казан ханлыгы». А. Иванов эше.

Иллюстрацияләр Александр Ивановтан һәм автордан алынды

«Нурлы Казан».
Ф.Халиков рәсеме.

мәгәндер, үзенә кадәр идарә иткән Алимбәкне генә куып җибәргәндер, дип фаразларга мөмкин иң. Шулай икән, Казан билегендә бары тик тәхет хуҗасы гына алмашына булып чыга, һәм без, тарихчылар, ул билекне 1445 елдан башлап ханлык дип атап йөртәбез.

ХАНЛЫК ТЕРРИТОРИЯСЕНЕҢ ЧИКЛӘРЕ

Нindирәк дәүләт була соң ул Казан ханлыгы? Ул зур гына территория биләп торган, аның чикләре көнчыгышта Агыйделдән алып көнбатышта Сура елгаларына хәтле, төньякта удмуртлар һәм комилар яши торган Вятка-Кама төбәкләреннән башлап, көньякта Иделнең Самара борылышына кадәр сузылган. Шулай итеп, элгәреге Идел Болгарына караган бөтен җирләр һәм анда яшәгән халыклар Казан ханлыгы составына кергән. Ул көньяк-көнчыгышта Нугай Урдасы, көньякта – Әстерхан (Хаҗитархан) һәм Кырым ханлыклары, көнбатышта Мәскәү дәүләте белән чиктәш булган. Ханлыкның үзәк өлешен хәзерге Татарстан җирләре (көньяк-көнчыгышта Кама елгасына кадәр генә) тәшкил иткән. Элеккеге Идел Болгарының халык иң күп яшәгән Кама аръягы җирләре ханлык заманында бушап калган диярлек. Бирегә, көтү куып, күчмә нугайлар еш килеп йөргән. Норлат, Шәрбән, Алпар, Әлки кебек авыллар нугайлар һөҗүменнән саклану өчен урманнар эченә сыенып утырган.

Аның каравы, Казан арты төбәкләрендә халык күп яшәгән. Ул төбәкләрдә, бигрәк тә Эчке (Иске) Казан тирәсендә, болгар-татарларның XV–XVI йөзләргә караган дистәләрчә авыллары булган. Күренекле тарихчы Е.И. Чернышев исә 1960 нчы елларда ук, архив материалларына таянып, Казан ханлыгы чорына караган һәм Казансу, Ашыт, Мишә, Зөя һәм башка елга бассейннарында урнашкан 700 ләп авылны картага төшергән иде.

«КАЗАН ИЛЕНДӘ БАСУЛАР ЗУР...»

Авыл халкы башлыча игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән. 1552 елда Казанны яулап алуда катнашкан рус кенәзе Андрей Курбский: «Казан илендә басулар зур, туфрагы уңдырышлы, һәртөрле яшелчә-җимешкә бик бай, ә игенчеләр исә күптәнкүп», – дип язып калдырган. Игенчеләр җир эшкәртү өчен тимер төрәнле сабаннардан һәм болгар заманнарыннан ук билгеле булган ике тешле сукадан файдаланганнар. Бодай, арпа, арыш, борай, солы, карабодай, тары, борчак, ясмык, җитен иккәннәр (аларның янгында күмерләнгән бөртекләре археологик казулар вакытында табыла). Елъязмаларда: «Казан җире яшелчәгә, җиләк-җимешкә бик бай», – дигән сүзләр дә очрый. Шунысы кызык: инде күптән утрак тормышка күчкән борынгы болгар бабаларыбыз да яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерүгә хирыс булган. Биләр казылмаларында алма, чия, кура җиләге, балан, кыяр орлыклары табылып тора. Күрәсең, яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерү ханлык чорында да дәвам иткән, әмма соңгырак чорларда әлеге традиция югалган һәм авыл җирләрендә бары тик сугыштан соңгы елларда гына яңадан торгызылган.

ХАНЛЫКНЫҢ ШӘҺӘРЛӘРЕ

Казан ханлыгының шәһәр тибындагы эре торак пунктлары елга буйларында урнашкан була. Аларның күбесе элеккеге болгар торулыклары нигезендә үсеп чыккан. Әмма Казан ханлыгын инде «шәһәрләр иле» дип атый алмыйбыз. Исегезгә төшерәбез: Болгар илендә нигытылган шәһәрлекләр саны 100 дән артык булса (алар арасыннан Болгар, Биләр, Сувар, Җүкәтау, Кашан, Ашлы кебек бөтен дөньяда мәгълүм эре калалар язма документларда телгә алыналар), Алтын Урда чорында бу сан ике дистәдән артмый, ә ханлык чорында исә Казаннан һәм Чаллыдан кала (хәзерге Балык Бистәсе районының Тәберле Чаллысы авылы янында урнаш-

Сәхиб-Гәрәй хан ярлыгы. 1523 ел.

Казан бүреге. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында саклана.

кан кала күз алдында тотыла), Арча, Лаеш, Тәтеш, Алабуга, Камай («Эчке Казан»), Сембер һәм Сарытау ише эрерәк торак пунктларын шәһәрләр исемлегенә шартлы рәвештә генә кертергә мөмкин. Хәер, болай дип әйтү дөреслеккә туры килмәскә дә мөмкин, чөнки без санап киткән калаларның берсе дә (Казан һәм Чаллыдан башкалары) археологлар тарафыннан юнълэп өйрәнелмәгән ич. Ничек кенә булмасын, югарыда китерелгән фактлар урта гасыр татарлары цивилизациясенең әле Алтын Урда чорында ук, 1360 нчы еллардан башлап, әкренләп сүнә баруын күрсәтәләр. Бу процесс, күргәнегезчә, ханлык чорында да дәвам итә.

Күн ук савыты. Казан Кремле территориясендә казу эшләре вакытында табылган. Реконструкция.

ШӘРЫКНЫҢ БАШКАЛАСЫ

Халыкара сәүдә үзәге буларак Шәрык һәм Көнбатыш Европа илләрендә дә билгеле булган ханлык башкаласы Казан, бүгенге күзлектән чыгып караганда, артык зур шәһәр булмаган. Аның тау башында урнашкан һәм көчле ныгытмалар белән уратып алынган өлеше (кала – кремль) якынча 10 гектар мәйданны биләп торган. Каланың төньяк өлешендә Хан сарае, аннан ерак түгел Хан мәчете (хәзерге Сөембикә манарасы урынында), шул мәчет янында, бераз көнбатыш тарафка китеп, ханнар төрбәсе урнашкан булган. Әлбәттә, дәүләт идарәсенең тотрыксыз эшләвен тәэмин итү өчен салынган башка биналар да булгандыр. Хан резиденциясе тирәсендә, көньяктарак, ерактан ук сигез манаралы матур Кол Шәриф мәчете күренеп торган (таш хәрабәләре Благовещение соборы каршындагы сквер территориясендә ачылды). Көнбатыш тарафта хан гвардиясе казармалары, ат абзарлары, корал ясау остаханәләре, сугыш кирәк-яраклары арсеналы, тагын да көньяктарак сарай хезмәткәрләре яши торган гади генә йортлар, ашлык саклау амбарлары тезелеп киткән. Шәһәр каласында, Кремльдә, Нурали (Нургали) исемен йөртүче тагын бер мәчет эшләп торган. Аның кайда урнашкан булуы әлегә билгеле түгел, Нурали (хәзерге Тайницкая) башнясы янындарак түгел микән дигән фараз гына бар.

Шәһәрнең төп өлеше, әлбәттә, сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр бистәсеннән гыйбәрәт булган. Ул көнбатыштан Болак елгасы, көнчыгыштан Кара, Ак, Мунча, Шакшы (Поганое) күлләре, көньякта исә хәзерге Лобачевский һәм Астрономия урамнары белән чикләнгән 60 гектар чамасы мәйданны биләп торган. Ханлык чорында шәһәрнең бу өлеше дә кереп-чыгып йөрү өчен 9–10 манарасы булган имән диварлар белән әйләндереп алына. Бистәнең Казансуга якын өлешендә кара һәм төсле металл кою мичләре, тимерчеләрнең, чүлмәкчеләрнең, тире-күн эшкәртүчеләрнең күпсанлы остаханәләре, ә Болак тирәсендә, Нурали башнясыннан ерак түгел җирдә, Таһир мунчасы («Даирова баня») урнашкан була. Хәзерге Үзәк стадионга каршы якта, элеккеге Ташаяк урамы тирәсендә, даими эшләп торучы зур гына базар булган.

Башка урыннарны гади агач йортларда яшәүче шәһәр кешеләре, сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең утарлары алып торган. Алар арасында мөлкәтле кешеләрнең, бай сәүдәгәрләрнең агач бүрәнәләрдән, сирәк булса да кирпечтән салынган, шул заман кешеләре язганча, икешәр катлы «гаҗәпләндерерлек матур» йортлары аерылып торган. Кызганыч, язма чыганакларда Казан бистәләрендәге мәчетләр һәм башка җәмәгать биналары турында хәбәрләр сакланмаган. Алар да булган, әлбәттә. Мөселман шәһәрен диварлары төсле чынаяк плитәләр белән капланган мәчетләр һәм аларның югарыга омтылган манараларыннан башка күз алдына да китереп булмый. Шул мәчетләре бит инде шәһәргә үзенә бер төрле матурлык биреп торган һәм чит ил кешеләре аны «искиткеч шәһәр», «Шәрыкнең башкаласы» дип атаганнар.

Тормыш шәһәр яны бистәләрендә дә кайнап торган. Болак аръягында, хәзерге Мәскәү урамы буйлап, XV йөз урталарында ук Көрәеш бистәсе үсеп чыга. Бистәнең сокланырлык матур Өтәч мәчете (Отучева мечеть) хәтта рус елъязмаларында теркәлеп калган. Көрәешнең археологик эзләре, шул исәптән борынгы зират урыны, хәзерге Колхоз базары тирәсендә ачылды. Көрәеш бистәсеннән арырак, Иделгә таба, Хан болыны башланып киткән, анда җәен зур бәйрәмнәр оештырылган, ат чабышлары уздырылган.

Казансуның Иделгә кушылган урынында балта осталары һәм кораб төзүчеләр бистәсе – Бишбалта барлыкка килә. Шунда ук, Идел култыгында, сәүдә һәм хәрби суднолар тукталышы өчен уңайлы урын да табыла.

Шәһәрнең икенче ягында, Арча кыры белән Кабан күле арасында, Әрмән бистәсе урнашкан була. Өлкән яштәге кешеләр әйтүенчә, әле узган гасыр урталарында да Калинин урамы башланган җирдә борынгы зират урынын күрсәтеп торучы әрмән язмалары белән чуарланган кабер ташлары калкып торган.

Шәһәрдә һәм аның тирә-юнендәге бистәләрдә, безнең якынча исәпләүләр буенча, 7–8 мең чамасы кеше – башлыча һөнәрчеләр һәм вак сәүдәгәрләр яшәгән. Кызганыч, археологик казулар вакытында һөнәрче остаханәләре бик сирәк очрый, әмма алар кулланган инструментлар һәм шул остаханәләрдә җитештерелгән әзер продукция – тимерчеләр ясаган хезмәт һәм сугыш кораллары, күптөрле көнкүреш кирәк-яраклары, бакырчылар ясаган комганнар һәм кувшиннар, ювелир осталары җитештергән алтын-көмеш бизәнү әйберләре, күнчеләр теккән аяк киемнәре, ук савытлары – археологик табылдыклар арасында сирәк түгел. Чүлмәкчеләр аеруча

«Кунак утравында Казан ярминкәсе». Ф.Халиков рәсеме.

оста һөнәр ияләре саналган. Алар эшләгән югары сыйфатлы балчык савыт-саба һәм дә кош-хайван сурәтендәге уенчыклар матур формалары, үзенчәлекле бизәкләре белән аерылып торган. Хатын-кызлар өчен бизәнү әйберләре ясаганда зәркәнчеләр бакырга, алтын-көмешкә чокып рәсем төшерү, кыйммәтле ташлар кую, металл үрү кебек катлаулы ысуллар кулланганнар. Алтын-көмеш әйберләр хан сараена аеруча күп кирәк булган. Замандашлары язганча, һәр яңа хан үзенә «кыйммәтле таҗ, алтын-көмештән савыт-саба эшләткән, кыйммәтле кием-салым тектергән». Бүген Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында сакланган уникаль «Казан бүреге» кешеләрдә бүген дә зур соклану уята. Аны XVI гасырның беренче яртысындагы татар зәркән сәнгатенең гүзәл үрнәге дип атарга мөмкин.

Һөнәрчеләр арасында төзелеш белән мәшгуль кешеләр аерым бер төркем тәшкил иткән. Алар «патша пулатлары һәм биек манаралы мәчетләр салучы осталар» гына түгел, ә төрле төстәге кирпечләр, матур бизәкле гипс плитәләр эшләүче осталар да булганнар. Таш кисүче осталарның байлар заказы буенча искиткеч матур итеп эшләнгән, матур каллиграфия белән гарәпчә текстлар язылган кабер ташлары безне әле дә хәйран калдыра.

КАЗАН – СӘҮДӘ ШӘҺӘРЕ

Казан ханлыгы икътисадында сәүдә, бигрәк тә тышкы сәүдә зур роль уйнаган. Татар сәүдәгәрләре Мәскәү Русе, Кавказ һәм Урта Азия, хәтта Көнбатыш Европа илләре белән тыгыз элемтәдә торганнар. Иделнең Казанга якын Кунак (Гостиный) утравында ел саен даны еракларга таралган Казан ярминкәсе уздырылган. Шул заманның бер кешесе: «Казанга бөтен Рус иленнән бай сәүдәгәрләр һәм еракта бик күп чит ил кешеләре җыелып килә һәм кыйммәтле товарлар белән күпләп сату итә», – дип язып калдырган. Сәүдәгәрләр «Бохарадан, Шемахадан, һәм дә төрекләр, әрмәннәр иленнән, һәм дә башка илләрдән» килеп йөргән. Чит ил сәяхәтчеләре дә рус елъязмачыларының сүзен раслый. «Казан – сәүдә шәһәре, – дип язып калдырган XV гасырда яшәгән Венеция сәүдәгәре Иосафато Барбаро. – Аннан ифрат күп санда мех чыгарыла, алар Мәскәүгә, Польшага, Пруссиягә һәм Фландриягә китә». XVI гасыр башында яшәгән Австрия дипломаты Сигизмунд Герберштейн Казанга «Әстерхан, шулай ук Персия/Фарсы һәм Әрмәнстан базарларыннан сәүдәгәрләр» килүе турында хәбәр итә. Югарыда китерелгән тарихи чыганаклар яктылыгында Казан ханлыгы Европа белән Азия халыклары арасындагы сәүдәдә әһәмиятле урын тоткан, дип әйтә алабыз.

* * *

Казан шәһәренә киңрәк тукталуыбызның сәбәбе аңлашыладыр, дип уйлыйм. Ул – ханлыкның башкаласы, татарларның чит илләрдә дә танылу алган бердәнбер зур шәһәре. Башкала тарихында ил тарихы чагыла. Чамалагансыздыр, ханлык чоры Казаны элгәреге Алтын Урда һәм Болгар шәһәрләреннән зурлыгы ягыннан да, байлыгы ягыннан да күпкә калыша. Биредә Биләр, Болгардагы кебек монументаль архитектура корылмалары юк дияргә була. Икътисад үсешен югары бәяләгән очракта да, әлеге күренеш Казан өчен генә хас, дип уйларга нигез бар, чөнки Арча, Лаеш, Тәтеш һәм башка шәһәрләр бик кечкенә, шунлыктан алар һөнәрчелектә сизелерлек роль уйнамаганнар. Әлеге чынбарлыкны тану ханлыкның һәм гомумән урта гасырлар чоры татар цивилизациясенең киләчәк язмышын объектив рәвештә күз алдына китерергә ярдәм итә. ■

PRESSA.RU

«ТЕРЕ МУЗЕЙ»ГА РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Шулай дип каршы алалар бирегә килгән кунакларны. Россия тарихының иң борынгы чорларыннан алып бүгенге көнгә кадәрге этапларын колачлаган, «тере музей» дип исемләнгән әлеге мультимедиа күргәзмә быел Россиянең күп кенә эре шәһәрләрендә тәкъдим ителде. Уфа, Казан, Төмән, Самара… Әйтүләренә караганда, соңгы мәйданнарның берсе булган Самарада гына да аны беренче көннәрендә үк 17 меңнән артык кеше караган. Бездә, Казанда исә, бу сан, килгән кунакларны да исәпкә алсак, 50 меңнәргә җыела, диләр.

Автор:
Луиза Янсуар

ЗАМАНЧАЛЫК – БЕРЕНЧЕ УРЫНДА

«Россия – минем тарихым» проектына биш ел. Аның идеясенең авторы – Егорьевск епископы, Патриархлар советының җаваплы секретаре Тихон (Георгий Шевкунов). Ул Гуманитар проектлар фондының экспертлар советы җитәкчесе дә булып тора. Ә бу советка Россия тарихы институтыннан (РАН) башлап, Россиянең башка бик күп мәртәбәле уку йортларының күренекле академиклары, профессорлары керә. Алар фикеренчә, яшьләр өчен дә, өлкән һәм урта буыннар өчен дә кызыклы, мавыктыргыч булырдай проектның төп максаты – үткәнебез һәм бүгенгебезнең тарихына анык нәтиҗә һәм бәя бирү, безнең тарихны өр-яңадан ваемлау. Проект РФ Президенты администрациясе тарафыннан югары бәяләнде һәм Россиянең эре шәһәрләрендә күрсәтелергә тиеш, дип табылды. Әлбәттә, җирле тарихи-мәдәни пластны да исәптә тотып. Милли республикаларга килгәндә, соңгы момент аеруча зур әһәмияткә ия, билгеле. Мисал өчен, җәй көне Уфада узган күргәзмәдә башкортлар үзләрендәге күренекле шәхесләргә, тарихларындагы сәхифәләргә урын бирде. Казандагы күргәзмәдә дә бу шулай. Бар яктан уйланылган һәм тулы бербөтенне тәшкил иткән тере экраннар арасында йөрисең-йөрисең дә, кинәт кенә, көтмәгәндә, «Татарстан тарихы битләреннән» дигән панельләргә килеп төртеләсең. Күңел сөенеп, очынып китә. Алар аз-азлап кына булса да, әзер проектка өстәмәләр кертү кебек четерекле бурычны үз өстенә алган ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани институты командасына шактый кыенга килгәндер, дип фаразларга җирлек бар. Әлбәттә, проект милли күзлектән карап оештырылган очракта без бөтенләй башка тарихны күрер идек, әмма – кунак ашы кара-каршы, дигәндәй… Милли тарихыбызга реконструкция ясауны үзмаксат итеп куйган белгечләрнең берсе – ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани институты фәнни секретаре Бәхтияр Искәндәр улы Измайловка мөрәҗәгать иттек. Ул безгә Татарстан тарихы белән бәйле сәхифәләрнең ничек туплануына ачыклык кертергә булышты.

Фотолар: Луиза Янсуар

Күргәзмәнең чишмә башында берничә тарихи-мәдәни экспозиция тора: «Романовлар», «Рюриковичлар», «Бөек зилзиләләрдән – Бөек җиңүгә», «Россия – минем тарихым. 1945–2017» һ.б. Тора-бара ул шушындый зур проект булып әверелә. 2016 елда аны Мәскәү манежында 200 000 кеше карый.

«ТАРИХНЫҢ ШОМА ГЫНА БУЛМАВЫН АҢЛАДЫЛАР...»

Бәхтияр Измайлов:

– Без Мәскәүдәге оештыручыларның заказы буенча эшләдек. Федераль үзәкнең һәм үзебезнең Мәдәният министрлыгының заказы, дисәк дөресрәк булыр. Региональ компоненты өстәү буенча махсус комиссия төзелде: Фәннәр академиясе, Милли музей һәм үзебезнең Тарих институты керде ул комиссия составына. Федераль үзәккә үзебезнең концепцияне тәкъдим иттек, һәм, әйтергә кирәк, сөйләшү барышында безгә карата Россия Тарих институты белгечләреннән сораулар минимум булды. Коллегалар безнең рецензентлар иде, һәм контентны эшләгәндә, безгә бурычларны да алар куйды. Региональ компонентны, аңлашыла ки, күргәзмәнең инде әзер схемасына яраштырып эшләргә кирәк иде. Бу яктан проблемалар тумады дияргә дә була, әмма тарихка карашның ике яклы булуы, әлбәттә, үзен сиздерде. Мәскәүдән караганда тарих бит ул бердәй, андагылар уйлаганча гына күренә. Әмма регионнар белән җыелып сөйләшүләр, комиссияләрнең эшчәнлеге барышында Федераль үзәк үзе дә ул тарихның шома гына булмаганлыгына янә бер мәртәбә инанды.

Һәр регионның – үз карашы, үз нокталары. Мисал өчен, бездәге проектны эшләгәнче үк Уфада килеп туган прецендент: Салават Юлаев башкортлар өчен милли каһарман дәрәҗәсендә йөри торган шәхес, региональ компонентта аның, әлбәттә, үз мәртәбәле урыны бар. Ә Россия тарихында аның роле шактый шикле ракурстан бәяләнә. Гомумән, Пугачев восстаниесенә мөнәсәбәтне Россия тарихы дәреслекләреннән барыбыз да яхшы хәтерлибез. Четерекле сораулар милли республикалар тарихына килгәндә, шактый күп. Бездә, мисал өчен, Казанның алыну вакыйгасы милли фаҗига, дәүләтчелекне югалту, күп елларга сузылган әрнү буларак кабул ителсә, Россиянең империячел сәясәтендә ул – чираттагы җиңүләрнең берсе. Чукындыру сәясәтенә килгәндә дә, хәлләр шулайрак. Без моннан, регионнан торып, моны күрәбез, аларга да аңлатырга омтылыш ясап карыйбыз. Аңламадылар, рецензентлар бәйләнеп, фикерен тагып утырды, дип әйтә алмыйм. Эш конфликтлы булмады. Без үзебезгә бирелгән кадәр өлешләрдә үзебезнең тарихка региональ карашыбызны тиешенчә күрсәтә алдык, дип уйлыйм. Бездә 42 залның 40ында ул җирле компонент бар. Кайбер республика-регионнарда, төрле сәбәпләргә бәйле рәвештә, юк та аның кадәрле сәхифә.

Әлбәттә, күргәзмәнең, ул гаять заманча, югары кимәлдә эшләнгән булуына карамастан, сораулар уята торган яклары җитәрлек. Әйтик, борынгы тарих. Әгәр төрки-татар тарихына борылып күз салсак, без, аны, сүз дә юк, Киев Русе чорыннан башлый алмыйбыз. Без борынгы тарихка кагылышлы залларны

PRESSA.RU

Статистика буенча, Россиядә «Россия – минем тарихым» мультимедиа-күргәзмәсен 2 500 000 нән артык кеше караган.

ике тапкырга арттырыр идек. Монда төрки каганатлар да керергә тиеш, һуннар тарихына кагылышлы этаплар да... Кавказ халыкларына килсәк, аларда да сораулар күп. Чөнки, Киев Русе оешканчы ук, Кавказ территориясендә шәһәрләре белән данлыклы цивилизацияләр булган.

Ә инде рухани компонентка килсәк, бу аңлашыла: Патриархлар советы нәкъ менә дини-мәдәни бердәмлекне күздә тотып, Россия тарихының яңа этабында үзенә күрә бер идеология булдырырга омтыла. Тарихта «центрический» дип йөртелүче карашка һәм алымга нигезләнгән булуына карамастан, бу – бик зур, саллы хезмәт, һәм ул яңа заман яшьләренә юнәлтелгән, алар файдасына эшләр дә дип өметләник.

ЧИПТАГЫ ТАРИХ

Чынлап та, файдага булсын иде, дигән теләк туа. Чөнки күргәзмәнең буеннан-буена без, нигездә, христиан дөньясы кыйммәтләре белән очрашабыз, Россиядәге башка диннәр, конфессияләр һәм күзаллаулар, төп стенд белән күз уңыннан читтәрәк калып, «төбәкнеке» булып кала бирә. Үзәктә формалашкан проект өчен моның табигый булуын аңлыйбыз, билгеле, әмма яшь буында бу сораулар уятмаска, һәм шулай тиеш дип кабул ителергә дә мөмкин бит, дигән шик уяна. Экспозицияләрне карап йөргән яшьләрне туктатып, аларга сораулар биреп карадым. Арада төрлесе бар. Мәктәп укучылары да, студентлар да. Кайсылары әти-әниләре, укытучылары белән килгән. Менә Артур, ул студент. Бер төркем дусларын ияртеп, күргәзмәгә инде өченче тапкыр килүе икән.

– Миңа күргәзмә бик ошады. Идеясе дә, заманчалыгы да – озак итеп алкышларлык. Аеруча ошаганы – интерактив уеннар, квестлар, биремнәр, белемнәреңне рәхәтләнеп сынап карарга мөмкин. Мин тарих белән мәктәптә укыганда ук кызыксына идем, шуңа монда әллә ничә килдем инде, дусларымны да алып килдем. Кызларны, гадәттә, тарихи ретроспективага корылган гөмбәз җәлеп итә. Ул, чыннан да, искиткеч. Тере вакыйгалар куемтысына кереп киткәндәй буласың...

– Ә сине татар тарихына, Татарстан тарихына кагылышлы сәхифәләр җәлеп итмәдеме, сораулар тудырмадымы? – дип сорыйм Артурдан. Аның әнисе – татар, ә әтисе рус милләте вәкиле икән. Ул мәктәптә рус телендә укыган, БДИны бик яхшы балларга тапшырган. Юрист һөнәрен үзләштерә. Киләчәктә Казанда калырга җыенмый. Амбицияләре – зурдан.

– Мин тарихка фактлар җыелмасы буларак карыйм, авырту ноктасыннан түгел. Бу – заманча караш, – дип җавап кайтара Артур, елмаеп. – Килешәсездер, бүген кешеләрнең мөмкинлекләре – санап бетергесез, телләр беләсең икән, яхшы профессияң бар икән, дөньяның теләсә кайсы почмагына чыгып кит тә, сынап кара үзеңне! Югары технологияләр заманында, күз иярмәс тизлекләр чорында яшибез бит...

– Ә үзең тарихны ничек язар идең? Дөнья бит сезнең кулга калачак... – дип, төрттерүемне дәвам итәм.

– Мин ул тарихны инде язып, сүздә теркәп торырга кирәк булмаячак, дип уйлыйм, ул, бәлки, безнең баш миебезгә урнаштырылган чип рәвешендә булыр. Иң мөһиме – конфликтларны сугышсыз хәл итүгә ирешү бүгенге заманда. Фашизмнан арынсак иде инде. XXI гасыр – урамда...

Яшьлек максимализмы ялкынын бөркеп, дусларын куып тотып, Артур стендлар арасында югала. Ә мин игътибарымны күптән җәлеп иткән бер абзыйга юнәлтәм. Ул Казанның бер мәктәбендә күп еллар буена физика укыткан, хәзер лаеклы ялда икән. Илдар әфәнде күргәзмәне зур игътибар белән карый, үзе белән килгән иптәше белән фәлсәфә куертып, бәхәсләшеп алалар. Интеллигентларча кыяфәте, фикерләре белән җәлеп итте ул мине.

– Нәрсәсе белән ошый сезгә күргәзмә? – дип сорыйм.

– Ошаган ягы – заманчалык. Бар да бер структурага җыелган, бар да тиешенчә, порцияләп бирелә. Әмма структура үзе урыны-урыны белән шактый күп сораулар уята, – ди ул. – Күргәзмәнең азагына табарак героик пафосның өстенлек алуы да күңелне кырды бераз. Безнең илебез бит әллә ни мактана алмый үзенең яшәү минимумы белән. Ә монда – барысы да искиткеч...

Экспозиция турында Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин болай дигән иде: «Экспозиция барлык җиңүләре һәм проблемалары белән безнең илебез тарихының объектив картинасын күрсәтә». Илебез тарихы канвасына милли төбәкләр тарихын да кертеп, ил буенча бердәм экспозиция күрсәтсәк, барлык халыкларның үткәнен белү күбрәк нәтиҗә бирер иде.

ТӨБӘК
ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Кулга очраклы гына «Хуҗа Хәсән – минем гомер бишегем» исемле китап килеп керде. Авыл тарихлары турындагы китапларны шактый укыганым бар. Кемнедер үпкәләтәсем килми, ләкин аларның күбесе авылда яшәүче кешеләр, хәзерге чорда булган йортларны санап чыгу кебек өстә яткан фактлар белән чикләнә. Ә Хуҗа Хәсән турындагы китап үзгә… Ул фәнни хезмәт кебек, хәтта шул төбәк турында бер энциклопедия, дияр идем.

Ә иң кыйммәтлесе – китап авторы үзе дә Хуҗа Хәсәннеке. Әллә шуның өчен дә ул бай эчтәлекле, тирән мәгънәле булган.

Автор:
Руфия Фазылова

ЛАЕКЛЫ ЯЛДА – ЯҢА ШӨГЫЛЬ

Кайбыч районының Хуҗа Хәсән авылы турында ике китап бар икән. Минем кулга килеп кергәне – икенчесе. Ә беренчесе – «Хуҗа Хәсән – әби-бабайлар нигезе» дип атала. Беренчесе – 2014 елда, икенчесе 2017 елда дөнья күргән. Китапларның авторы – Вячеслав Власович Данилов. Аны күпләр республика авыл хуҗалыгы үсешенә зур өлеш керткән шәхес, Татарстанның атказанган икътисадчысы буларак белә.

«Хуҗа Хәсән – минем гомер бишегем» китабын укып чыкканнан соң, гади икътисадчының тарихны шулкадәр яхшы белүенә гаҗәпләнеп тә куясың.

– Сез тарихчы да түгелме? – дим Вячеслав әфәндегә, китап белән танышканнан соң.

– Юк, – дип елмая ул. – Шулай да тарих белән гомер буе кызыксындым. Әти-бабалардан калган аерым истәлекләрне теркәп тә бардым. Туган авылым турында китап язу теләге, хыялы күңелдә һәрвакыт булды…

Вячеслав Власович белән өч сәгать сөйләшеп утырдык. Миңа калса, мәктәпләрдә тарихны аның кебек кызык итеп сөйләсәләр, бөтен бала туган төбәгенең үткәнен өйрәнү белән яна башлар иде.

Вячеслав әфәнде лаеклы ялга чыккач, ике ел гына эшли. Аннан саннар дөньясыннан тарих дигән олы бер дәрьяга кереп чума. Һәр нәрсәнең үз вакыты бар икәнен яхшы аңлый. Татарстан, Чувашстан республикалары, Буа, Апас, Кайбыч районнары архивларын өйрәнеп чыга, Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсендә борынгы язмалар бүлегендә эзләнә. Шулай итеп ике ел дәвамында өйрәнә торгач, «Хуҗа Хәсән –

Фото: Александр Ефремов

PRESSA.RU



Вячеслав Власовичның нәсел шәҗәрәсе Алиш бабайдан башлана. 1640–1650нче елларда туган булырга тиеш икән. Һәрхәлдә, Россия дәүләт борынгы актлар архивында шундый документлар бар. Алишның хатыны Дускәй булган. 1748 елда нәселдә Анна, Алеша исемнәре барлыкка килә. Мисал өчен, 1747 елда туган Гали – Григорийга, 1712 елда туган Сәет Семенга әйләнә. Шулай итеп, санаулы еллар эчендә тулы бер ыру рус исем-фамилияләрен ала. Ә аларның милләтләре чуваш дип языла. Халык телендә исә «керәшен» булып йөри башлыйлар.

– Керәшен татары, диләр. Миңа бу атама бик сәер тоела. Керәшеннең татары буламыни?! Ә менә татарның керәшене, ягъни чукындырылганы чынлап та бар, ягъни без ул. Диннәре үзгәрсә дә, безнең халык гореф-гадәтләрен саф килеш саклап калган булырга тиеш, дип уйлыйм. Ни өчен дигәндә, чукындырылган татарларны бер яктан мөселманнар үз итмәгән, чөнки дин башка. Икенче яктан, телләр төрле булу сәбәпле, чувашлар да әллә ни якын китермәгән. Нәтиҗәдә алар үзләре генә укмашып яшәргә мәҗбүр була.

әби-бабай нигезе» исемле китабы барлыкка килә. Тик Вячеслав Власовичка болар гына аз тоела. Мәскәүгә – Россия дәүләт борынгы актлар архивына юл тота. Анда XVI гасырга караган иске славян язуларын өйрәнә.

– Тарихны, безнең ата-бабаларның үткәнен күзаллау өчен тагын К. Фукс, А. Фукс, Н. Ильминский һәм православие миссионерлары хезмәтләрен дә өйрәндем, – ди Вячеслав әфәнде. – Шактый документларны республиканың Үзәк тарихи-сәяси архивында таптым. Дөресен әйтим, шулкадәр матавыклы, энергия, сабырлык сорый торган эшләр бу. Иске славян теленнән рус теленә күчерү өчен бик күп вакытымны сарыф иттем. Тик мин болар турында зарланып сөйләмим, аларны өйрәнү гаҗәп күңелле эш булды. Үзем өчен икенче бер дөнья ачтым! Балаларга, оныкларга бай мирас калдырам, дип сөенәм.

Яшерен-батырын түгел, бүген модага кереп китте: хәллерәк кеше, туган авылы турында китап эшләтә. Вячеслав Власович бу эшкә иганәчеләр эзләп азапланмый, ике китапны да үз акчасына чыгара, хәтта кредит ала. Бастыру бер хәл, Мәскәү архивларында язмаларның күчерелмәсен алуның бер бите генә дә 200 сум тора. Чыгымнарның бер өлешен Кайбыч районы администрациясе дә күтәрергә вәгъдә биргән булган икән. Тик эш нигәдер барып чыкмаган.

– Икенче китапны ике күз, ике кыш эшләдем, – ди Вячеслав Власович. – Әле өченче китабымны да әзерләп ятам. Соңгысы авылның яңа тарихы турында булачак.

КЕРӘШЕННЕҢ ТАТАРЫ БУЛМЫЙ

Вячеслав Власович икенче («Хуҗа Хәсән – минем гомер бишегем») китабында, нигездә, архивлардан алынган мәгълүматларны китерә. Автор, бабаларының кайчан чукындырылуын, авылларындагы кешеләрнең күбесен ни өчен чуваш милләтенә кертүләрен ныклап өйрәнгән. Һәм соңыннан нәтиҗәләр дә ясаган.

– Тарихтан беләбез: Иван Грозный Казанны яулап алганнан соң, чукындыруның беренче дулкыны була, – ди Вячеслав әфәнде. – Икенче дулкын 1740 елның 11 сентябрендә кабул ителгән указ нигезендә башлана: мәҗүсиләрне һәм мөселманнарны күпләп христианлаштыралар. Әмма документлар нигезендә 1741-1742 елларда безнең төбәктә бер генә татар да чукындырылмаган булып күренә. Моның сәбәбе бик гади: чукындырылган татарларны чуваш дип яздырганнар. Безнең нәсел мисалында да ачык күренә ул: татарлар да, чувашлар да бар.

МӘКТӘП ЭСКӘМИЯСЕННӘН БЕЛГӘН...

Хуҗа Хәсән керәшен авылы. Кайбыч районында андый авыллар – 11. Вячеслав Власович беренче китабында («Хуҗа Хәсән – әби-бабайлар нигезе») аларның тарихын да телгә ала. Алай гына түгел, бу авылларның бер-берсенә ничек бәйләнгәнен исбатлый.

– Хуҗа Хәсән авылы хәзерге Кайбыч районының көнбатыш чигендә, Гөбенә елгасының урта җиренә һәм аның сул ягында, Инеш елгасы буйлап урнашкан, – дип сүзен дәвам итте әңгәмәдәшем. – Ул шушы төбәктәге борынгы авылларның берсе булган. Заманында Бөек Болгар дәүләтенең Тау ягы дип аталган. Монда мукшылар белән бергә чирмешләр, татарлар яшәгән. Соңрак, Бөек Болгарны җимергәннән соң, чувашлар да килә башлаган. Татарлар белән чувашлар кушылып яши башлаган. Шуңа күрәдер, хәтта күршедәге Чувашстан Республикасының күп авыллары татар исеме белән йөртелә. Әйтик, Бикмурзино, Тормыши, Байти-

ряково, Байгулово һ.б. һәм авыл эчендәге елга, чишмә исемнәре дә татар сүзләрен хәтерләтә. Мәсәлән, Чуваш Чүтие авылында «Тот Кош» чишмәсе бар. Андый мисаллар тагын байтак.

Вячеслав Власович туган авылы тарихы турындагы фактларны мәктәп эскәмиясендә үк белгән. Укытучылар, авылдагы өлкәннәр сөйләвеннән дә, укыган китаплары аша да. Җитәкче булып эшләгән елларында да әледәнәле туган төбәге тарихы белән кызыксынган. Китап язарга җыенып, Россия дәүләт борынгы актлар архивына баргач исә, кечкенәдән колагына кергән мәгълүматларны раслаучы документларга юлыккан.

– Хәзер тәгаен беләм: XVI гасыр азагыннан 1781 елларга кадәр Хуҗа Хәсән волость булып йөргән, – ди Вячеслав әфәнде. – Ул Свияжск өязенә кергән. Анда 21 авыл саналган. Чикләре бик зур булган. Чувашстан Республикасы Комсомольск, Янтик, Канаш районнарының берничә авылларын да берләштергән.

Хуҗа Хәсәннең оешуын фаразлап, якынча чамаларга гына була, чөнки архивларда XVI гасырдан иртәрәк булган мәгълүматлар юк. Авылның барлыкка килүен икегә бүлеп карарга кирәк. Беренчесе – Изге Болгар җиренә монгол гаскәрләре кереп җимерә башлаган чорда (1236–1240). Икенчесе – шул җирләргә Аксак Тимер (Тамерлан) һөҗүм иткән елларда, ягъни 1390–1400нче елларда булырга мөмкин.

«КЕШЕЛӘРНЕ УРТАК ВАТАН БЕРЛӘШТЕРӘ»

– Күп кенә язучылар, журналистлар һәм тарихчы галимнәр архивларда казынып, моңарчы язарга түгел, әйтергә дә ярамаган әйберләрне дөньяга чыгарды, – ди Вячеслав Власович. – Мин моңа сөенәм. Теге яки бу төбәкнең язмышын билгеләгән зур вакыйгаларны, халыкның олуг шәхесләрен барлап, киләчәк буыннар өчен язып калдыруны бик мөһим, кирәкле эш, дип саныйм. Моның бик әһәмиятле булуын тарих тагын бер кат раслар әле...

Даниловлар гаиләсендә өч ул үскән. Вячеслав әфәнде белән Зинаида ханымның бүген җиде оныгы бар. Сигез дистәне тутыруга карамастан, Татарстанның атказанган икътисадчысы әле һаман сафта. Дөнья яңалыклары белән танышып бара, яңа китабына материаллар туплый. Сәламәтлеге дә зарланырлык түгел. Күзлексез укуына исә гаҗәпкә калдым.

– Күзләрем архивларда утырып кына яшьләнә башлады, болай зарланмыйм, – диде ул үзе дә.

Вячеслав Власович кебекләр турында, «физик та (бу очракта – математик – авт.), лирик та», диләр. Гомере буе саннар дөньясында яшәгән ир шигырьләр дә язгалый икән. Берсен хәтта кычкырып укып та күрсәтте:

– Үзәк өзелә, хисләр ургып ташый
Язган чакта ошбу китапны.
Авыл урамында атлап йөрим,
Күрәм кебек һәрбер якташны...

Гөбенә елгасына куәт бирә
Кыр кизләүе, Инеш сулары.
Белсәң иде, нинди серләр саклый
Шушы ике елга ярлары...

– Вячеслав әфәнде, икенче китабыгызга: «Авылымны һәм авылдашларымны өзелеп яратам, барыбызга да изгелекләр теләп калам», – дип язгансыз. Туган ягыгызга карата чынлап та бик тирән хисләр белән янасыз, ахры? – дим.

– Кайда гына яшәсәк тә, нинди генә югары постлар биләсәк тә, кешеләрне уртак Ватан берләштерә. Хуҗа Хәсән – яшьлек хыялларын, шатлык-кайгыларны, авыр тормыш сынауларын үз эченә алган язмышыбыз ул. Туган авылыбыз һәрчак безнең белән. Без анда туганбыз, укырга өйрәнгәнбез, яшьлегебез шунда үткән. Анда әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез җирләнгән. Туган авылны ничек онытасың, ди?! Кеше картая-картая тагын да хискә бирелә икән. Балачак, яшьлек сагындыра.

Кызганыч, хәзер сирәк кайтыла. Унбер туган арасыннан бүген бер мин генә исән. Шулай да Хуҗа Хәсән бер генә сәгатькә дә күңелдән китми...

...Әлбәттә, мондый кеше хөрмәт уята. Итагатьле, зыялы ул. Минемчә, туган авылы турында китап язмаса да, һичшиксез, ул җәмгыятькә берәр файдалы эшкә алыныр иде. Сүз уңаеннан, Вячеслав Власовичка 2017 елның 30 октябрендә 80 яшь тулды. «ТР алдындагы казанышлары өчен» орден медале белән бүләкләнде ул. Әлеге уңайдан ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлау телеграммасы юллаган, Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары, шулай ук ТР Апас районы башлыкларының рәхмәт хатлары тапшырылган үзенә. Тынгы белмәс Вячеслав Власовичны без дә олы бәйрәме белән котлыйбыз. Сәламәтлек, күңел көрлеге телибез.

МУЛЬТИКУЛЬТУР ӘДӘБИЯТ, ЯКИ КОРОЛЬ АРТУР САРАЕНЫҢ САМУРАЕ

Быелгы әдәбият сөючеләрнең күпчелеге Нобель комитеты карары яңгыраганнан соң сөенгәндер дип фаразларга җөрьәт итәм. Мин үзем чын күңелдән сөендем. Кадзуо Исигуро рус телендәге тәрҗемәләре аша безнең мәдәни контекстка чагыштырмача соң килеп керсә дә, бүгенге әдәби барышны инде аңардан башка күз алдына китереп булмый. Кибетләрдәге һәм өйдәге китап киштәләре турында әйтәсе дә юк.

Автор:
Луиза Янсуар

Комитетның бу карарын соңгы еллардагы «иң сәяси булмаган карар» дип тамгаладылар. Язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе Дмитрий Быков моңа карата реакциясен болай белдерде: «Гаҗәпләнергә урын юк, ул беренче эшелондагы язучылардан, һәм, әйтергә кирәк, чыгышы буенча япон булуына карамастан, инглиз телендә күп кенә инглиз язучыларының үзләреннән дә яхшырак иҗат итүчеләрдән дә. Аның эмоциональ тирәнлеге, асылда, Көнчыгыш белән Көнбатышның көчле конфликты нәтиҗәсендә барлыкка килгән тирәнлек ул». Әдәбият тәнкыйтьчесе Анна Наринская фикеренчә: «Премияне ни өчен биргәннәре турында сүз куертып тормыйча, Нобель комитетының политкорректность векторы буйлап нинди курс алуы хакында баш ватмыйча, конкрет предмет турында сөйләшергә мөмкин, ниһаять». Ягъни чын мәгънәсендә әдәбият турында. Сөйләшик…

«ХАЛЫКАРА РОМАННАР ЯЗАРГА ТЕЛӘР ИДЕМ...»

Британ телен камил дәрәҗәдә үзләштереп, инглиз прозасын баеткан язучылар буларак, гадәттә, Джозеф Конрад белән Владимир Набоковны атыйлар иде. Алар сафына менә Кадзуо Исигуро да килеп өстәлде. «ХХ гасырның иң шәп инглиз романчысы» титулын йөрткән, китаплары Британиянең ел китабы булып танылган, Уитбред, Букер белән бүләкләнгән Исигуро инде Нобельгә дә лаек дип табылгач, мондый канатлы гыйбарә пәйда булды: «Кадзуо Исигуро – король Артур сараена килеп эләккән самурай ул». Ә бит уйлый калсаң, чыннан да парадокс: Британиянең иң мәртәбәле романистларының алдынгы сафында торучы Исигуроның теле асылда японча ачыла, ул япон гаиләсендә тәрбияләнә, андагы традицияләр аңа үз йогынтысын ясамый калмый. Әмма инглиз колледжында, мәртәбәле Британия университетларында укып, язуын инглиз телендә яза һәм бүгенге көндә «нәкъ менә инглиз теле, мәдәнияте традицияләрен иң яхшы саклаучы инглиз язучысы» булып исәпләнә. Букерны да Британия тормышының традицион асылын, нигезләрен, кыйммәтләрен тасвирлауны үзәккә алган «Остаток дня» әсәре өчен ала. Интервьюларында еш кына: «Мин халыкара романнар язарга теләр идем…» – дип кабатлый Исигуро. Шулай ук Британия белән Япония мәдәниятләренең уртак яклары шактый булуын да бик еш ассызыклый. Самурайлар кодексы белән Король Артур рыцарьларының намус һәм йөрәк кодексы шул рәвешле берьбөтенгә кушыла да, мультикультур бердәмлек хасил була. Мультикультурага мөнәсәбәт кискен поляр фикерләргә корылган булуын беләбез, әмма яхшымы бу, начармы – бүгенге күзлектән чыгып бәя бирү ашыгу булыр иде. Исиугро очрагында – бигрәк тә. «Халыкара роман» төшенчәсе турында сүз алып барганда да нәкъ менә синтезны күздә тота, дип уйлыйм. Мәдәниятләрнең һәммәсенең ахыр чиктә бер уртак платформага килеп кушылачагын күздә тота дип. Чөнки без акрынлап уртак бер аралашу теленә таба йөз тотабыз. Әмма шул ук вакытта милли катламга карата үтә сак, нәзберек булып кала Исигуро: британ традицияләренә дә, үз туган культурасы кыйммәтләренә дә. Туган җәмгыятен, мәдәниятен ваемлаудан башлаган иҗат юлында ул, барлык катламнарны барлый-барлый, һәрберсенең ахыр чиктә гомумцивилизациягә үстерүгә, аның барышын билгеләүгә керткән өлешләре турында уйлануга барып чыга. Алай гына да түгел, безнең ул цивилизацияне теләсә кайсы мизгелдә җимерергә дә, торгызырга да сәләтле булуыбыз хакында…

> *«Мине пейзаж үзе гомумән кызыксындырмый. Мине кеше башында яшәгән пейзаж гына мавыктыра». Кадзуо Исигуро.*

КАТАСТРОФАГА КАДӘРГЕ БЕР СЕКУНДТА...

Кеше башында яшәгән пейзаж турында сүз алып барганда, нигездә, хәтер темасына ишарә ясый Исигуро. Бу аның иҗаты буйлап кызыл җеп булып сузылган тема, дисәк тә ялгышмабыз. Исигуро фикеренчә, хәтер Кешелекне саклаучы төп нигез һәм бер үк вакытта коточкыч субъектив, тотрыксыз категория дә. Әнә шул субъективлык белән тотрыксызлык цивилизациянең иң хәтәр, җимергеч моментларына, вакыйгаларына китерә. Һәм бары шул гына Кеше-

Фото: blogdacompanhia.com.br

леккә кылган гамәлләрен онытып, алга таба ыргылырга да көч бирә. Кеше баш миендәге пейзажны, йөрәгендәге хәтер тасмасын җентекләп өйрәнү аша цивилизация язмышы турында уйлана Исигуро романнарында. Микроскопик кисемтәдә күренгәннәрнең ахыр чиктә нинди глобаль катастрофаларга китерүенә басым ясый.

«Новая газета»да аның хакында язган мәкаләсендә Ян Шенкман болай дигән иде: «Исигуроның Нагасакида туганлыгы – мөһим факт. Гәрчә бу атом-төш коралы фаҗигасеннән соң 9 ел узгач булса да, аңарда моңарчы чәчәк аткан тормышның мәңгегә җимерелүеннән калган коточкыч халәт, эз саклана. Язганнарының барысында да бар ул фаҗиганең кайтавазы. Ничек кенә инглиз элпәсе белән ыспайлап каплап куйма, тарихи хәтер барыбер үзгәрмәячәк. Шуңа да Исигуро һәр әсәрендә үткәнгә борылып карый, анда кайта. Кайта, чөнки дөньяның фаҗигагә кадәрге мизгелен янә бер кат күрергә, тоярга тели. Менә бит: әле генә бар да яхшы иде, һәм... инде беркайчан да бер нәрсә дә элеккечә булмаячак. Нобель премиясенең Исигурога нәкъ менә хәзер бирелүе – үзенә күрә бер билге, дияр идем. Без бүген нәкъ шундый халәттә яшибез, чөнки: катастрофага бер секунд вакыт калгандай».

ТОМАН ЭЧЕННӘН КҮРЕНГӘН ДӨНЬЯ
«Там, где в дымке холмы», «Художник зыбкого мира» китаплары

Бу тема Исигуроның беренче романнарында ук калкып чыга. Үткәнне торгызу, аны анализлау, хәрабәләр арасында йөреп, эзләрен барлау. Исигуро эмоцияләргә бик саран язучы. Бик тотнаклы. Урыны-урыны белән кырыс та дияр идем хәтта. Хисләрне сурәтләгәндә дә ул ярымым, ярымкараш, ярымхәрәкәт белән эш итә. Японлыгына традицион, патриархаль британ кырыслыгы һәм хәтта эчпошыргычлык белән чиктәш сабырлыгы да өстәлә. Исигуро беркайчан да гаепләү, кемгәдер тамга тагу кебек примитив юнәлешкә таба борылмый. Ул проблеманы кешеләрдән, эчке менталь корылыштан эзли.

Беренче әсәрләрендә япон әдәбиятындагы экзистенциаль традицияләрнең йогынтысы үзен аермачык сиздерә. Теле инглизчә булса да, аһәңе, өслүбе буенча алар гаҗәеп рәвештә «японча» дип ассызыклый тәрҗемәчеләр үзләре үк. Русчага тәрҗемәдә дә бу тәм әле сакланып кала. Шуны да әйтергә кирәк: Исигуро беренче романнарында субъектив хәтернең тагын бер яссылыгына мөрәҗәгать итә. Ул үзе күреп үсмәгән Японияне, сөйләгәннәр буенча гына кыйпылчыклап җыеп алынган ватанны, Атлантида турындагы мифтай, модель буларак тудыра да, аның язмышын, тарихи эволюциясен читтәге караш белән ваемларга омтыла. Мәсәлән, «Там, где в дымке холмы» романы каһарманы Эцуко урта яшьләрдәге япон хатыны. Ул Англиядә яши. Һәм менә көннәрдән бер көнне Япониядәге иреннән туган олы кызы Кейко үз-үзенә кул сала. Англия кешесенә кияүгә чыгып, бирегә күченеп килгән әнисе, үги әтисе, һәм инде Англиядә дөньяга килгән сеңлесе белән аны тоташтыручы җепләрнең ни дәрәҗәдә иллюзор булуы бер мизгелдә аермачык күзгә күренә.

Роман, исемендә үк әйтелгәнчә, томан эчендәге вакыйгаларның ул таралып алган арада күренеп китүен хәтерләтә. Исигуро әсәрендә ике чик арасында калган, бер дөньядан икенчесенә атлап чыккан замана кешесе белән бергә аның артыннан котылгысыз рәвештә сузылып барган тарихи-мәдәни шлейф турында уйлана. Романның башында ук каһарманы авызыннан шундый сүзләр әйттерә ул: «Инглизләргә безнең милләттә үз-үзеңә кул салу инстинкты бар дигән уй кадерле һәм кыйммәт, шуңа да нидер аңлатып тору нәтиҗә бирмәячәк. Газеталарда бары тик аның япон булуын һәм бүлмәсендә асылынып үлүен генә яздылар».

Исигуро бу әсәрендә тагын бер гаять әһәмиятле, алга таба иҗатында еш кабатланачак лейтмотивны кертеп җибәрә: бер мәдәният белән икенче мәдәният арасындагы якынаю, бер-беренә таба адымнар ясау мәңге дәвам итсә дә, ахыргача бер милләт вәкиле икенчесен барыбер аңлап җиткерә алмаячак. Алай гына да түгел, иңгә-иң куеп яшәгән туганнар, ир белән хатын да бер-берсеннән коточкыч ерак булып калалар хәтта. Әмма, ничек кенә булмасын, бер-береңә таба адымнар ясауны дәвам итәргә кирәк, дигән фикердә тора ул. Моның зыянга караганда файдасы күбрәк булуына ышануын дәвам итә. Юкка гына бит хыялы «халыкара романнар» түгел.

PRESSA.RU

«На исходе дня» фильмыннан кадр.

«МИН БУ ЮЛНЫ ВӨҖДАНЫМА ТАП ТӨШЕРМИЧӘ УЗДЫМ...»

«Остаток дня» китабы, «На исходе дня» фильмы

Кайсыдыр чалымнары белән татар әдәбиятындагы корбанчылык идеясенә тартым булган «кемгәдер хезмәт итү» идеясе нигез бу романга. «Остаток дня» әсәрен күпләр төп рольләрне Энтони Хопкинс белән Эмма Томпсон башкарган «На исходе дня» исемле Голливуд фильмы аша беләдер дип уйлыйм. Ә аңарчы 1989 елда басылып чыккан бу өченче романы өчен Исигуро Букер премиясен ала, һәм нәкъ менә шушы әсәрен «XX гасырның иң инглизчә романы» дип тамгалыйлар. Шунысы да билгеле: Букер комитеты тарихында беренче тапкыр тәкъдим ителгән язучы кандидатурасына каршы тавыш бирүче бер генә кеше дә табылмый. Сүз уңаеннан, бездә Борис Акунин соңрак бу әсәргә ремейк рәвешендә язылган «Коронация» романын бастырып чыгарды.

Әсәр искиткеч гади сюжетка корылган һәм, күпләр әйтүе буенча, шактый озын һәм сүлпән. Әмма бу – Кадзуо Исигуроның стиле. Әле бу романнан соң язылган «Когда мы были сиротами» белән «Безутешные» әсәрләре гомумән олы-олы кирпечләрне хәтерләтә. Исигурога катламлап-катламлап керергә кирәк, ул экшн һәм бормалы конструкцияләр тарафдары булмады беркайчан да. Әмма интриганы тиешле рәвештә, нәкъ менә инглиз һәм япон сарайлары этикеты кануннары буенчадыр, бәлки, тота белә ул. Кычкырып торган интрига булудан бигрәк, шкафтагы скелет шикелле яшеренеп яткан сер, әйтелеп бетмәгән яшерен әрну, дисәң, дөресрәк тә булыр аны. Лорд Дарлингтонга чын мәгънәсендә яратып, олы хөрмәт һәм тугрылык белән хезмәт иткән нәселле дворецкий Стивенс тарихында без самурайлар кодексы нигезләрен дә,



рыцарьлар кануны элементларын да күрәбез. Гади генә итеп әйткәндә, Стивенсның язмышы – ул хуҗасына багышланган хезмәтче язмышы. Әмма дворецкий булуны без, Япония мәдәниятендәге гейшаларның ролен аңламагандай, бар тирәнлегендә ваемлап бетермибез икән. Дворецкий булу – ул үзе бер осталык, һөнәр икән. Алай гына да түгел, иҗат, миссия!

> *Всякий мало-мальски серьезный дворецкий обязан на людях жить в своей роли, жить целиком и полностью, он не может на глазах у других выйти из роли, а через час войти, словно это не роль, а маскарадный костюм. Существует всего одна, и только одна ситуация, в рамках которой дворецкий, пекущийся о своем достоинстве, может позволить себе выйти из роли, а именно – когда он остается в полном одиночестве.*

Һәм менә чын хуҗасын югалтып, Америкадан килгән яңа берәүгә йорт белән бергә күчеп, хезмәт итәргә мәҗбүр булган Стивенсның фаҗигасен сурәтли Исигуро. Бу, әйткәнемчә, «кычкырып торган» яра түгел, бу тыенкы гына эчке газап. Фашизм алдында торган Европа буйлап поездда чыгып киткән Стивенсның (гәрчә ул үз гомерен нигездә хуҗасының сараенда үткәреп, бу хәлгә гайре табигый итеп караса да) уйланулары – романның фабуласы шуннан гыйбарәт. Үткәнгә экскурс – Исигуроның «фирменный» алымы. Үз тормышыннан баш тартып диярлек яшәгән Стивенс – камил дворецкий үрнәген тудыручы. «Без камил булырга тиешбез» – аның кредосы. Ә үз тормышы бөтенләй юк Стивенсның. Һәм менә, ул ышанган, ул инанган иске тормыш та күз алдында пыран-заран килеп, таркалып бара. Көн шәфәкъкә авыша, аңарга көннең азагыннан бер йотым калып килә. Әмма Стивенсның төп үкенече – бу тормышның юкка чыгуы түгел, ул моны акылы белән кабул итә, аңлый. Аны иң әрнеткәне – ул сайлаган юлның, кыйбланың очсызлануы, дәрәҗәсен югалтуы. Шулай да ул бер нәрсәдән юаныч таба: «Мин бу юлны вөҗданыма тап төшермичә уза алуым белән бәхетле», – ди.

Фото: photo.ivid.it

ҮЗЛӘРЕ САЙЛАМАГАН ЯЗМЫШ

«Не отпускай меня» китабы һәм фильмы

«Не отпускай меня» фильмыннан кадр.

Шул ук вөҗдан, язмышка буйсыну темасы һәм фатальлек мотивы Исигуроның иң популяр «Не отпускай меня» романында да – үзәктә. «Тайм» журналы аны 2005 елның иң яхшы романы дип игълан итте. 1923 елдан башлап 2005 елга кадәр иҗат ителгән инглиз телле иң шәп әсәрләр арасында беренче рәтләрдә исәпләнә ул. 2010 елда Марк Романек «Не отпускай меня» романы буенча фильм чыгарды, анда төп рольләрне Кэри Маллиган, Эндрю Гарфилд һәм Кира Найтли башкарды. Бу очрак – фильмның әсәрне очсызландырмаган очрагы.

Роман, Исигуроча, хәтер тасмасын үткәнгә таба әйләндерүдән башлана. Кэти Х. исемле 30 яшьләрдәге хатын уйларында сәер дә, серле дә мәктәп-интернатка – Хэйлшемда узган балачагына кайта. Хронотоп: XX гасыр азагы, шартлы (утопик дияргә дә буладыр, бәлки) Британия. Ә тарихның, ягъни җеп очының башы фашизмнан соңгы Европа чынбарлыгына, 1950 нче елларга барып тоташа. Мәктәптәге укытучылар («опекуннар») мондагы балаларны («тәрбияләнүчеләр»не) бик җентекләп карый. Аларның сәламәтлегенә зур игътибар бирелә, балаларны мәктәп чикләреннән беркайчан да читкә чыгармыйлар. Берәүнең дә килеп хәлен белмиләр, әти-әни, туганнар темасы бөтенләй күтәрелми. Тоташ сер һәм шом атмосферасында балаларга даими «сез киләчәктә миссиягезне үтәр өчен үсәсез» дип тукып торалар. Алардан рәсемнәр ясаталар, иң яхшы рәсемнәрне Мадам исемле серле ханым, мәктәпкә килеп, сайлап, каядыр алып китә. Рәсемне әйбәт ясаучылар югары бәяләнә мәктәптә... Балалар үзләре бу сәерлекне күрми, билгеле, алар өчен мондый яшәү шартлары – норма. Укучы исә һәр яңа битне ачканда «ни соң бу?!» дип изалана.

Һәм менә аларны Коттеджларга җибәрәләр. Монда Кэти дус кызы Рут һәм романтик натуралы иптәше Томми белән бергә килә. Томми белән Кэти арасындагы дуслык мәхәббәткә әверелеп китәргә тиеш булса да, Рут өлгеррәк булып чыга. Монда яшьләргә бер-берсен яратырга рөхсәт бирәләр, әмма бала табарга ярамый. Гаилә корырга да... Романның өченче өлешендә әсәрнең буеннан-буена барысы да коты очып көткән тәүге «выемка» көне килеп җитә. Томми белән Рут – донорлар, Кэти – булышчы. Донорларның органнарын алалар, булышчы исә аларга чираттагы «выемка»га кадәр хәлгә килергә ярдәм итә, карый-кайгырта. Бу өчәү үлем машинасын туктатырга теләсә дә, сүздән ерак китә алмыйлар. Ә Мадамны эзләп тапкач, тагын да куркынычрак хакыйкать ачыла: алар кеше дә түгел, ә клоннар гына икән. Аларга рәсемнәрне... кеше дип аталырга хокуклымы-юкмы икәнлекләрен анализлар өчен ясатканнар икән... Ахыр чиктә, без Хейлшемның җәмгыятьтә клоннарга карата булган кансыз мөнәсәбәтне яхшырту өчен Мадам тарафыннан төзелгән гуманлы проект икәнлегенә төшенәбез. Ул клоннарның җансыз медицина материалы гына түгел, ә тулы канлы иҗади шәхесләр булуын күрсәтергә тели.

Әмма катастрофа, бу ракурстан караганда, тагын да тирәнәя: укытып, тәрбияләп, иҗади яктан үстереп, хисләрен кузгатканнан соң, «кеше» дә була алмаган, «ит кисәге» генә рәвешендә дә кала алмаган бу өчәү (ә андыйлар – тулы бер интернат һәм берничә чыгарылыш!) аяк астындагы туфракны бөтенләй җуя. Томми белән Кэти кешеләр арасына китеп, кешечә яшәү турында хыяллана. Гаилә корып, бер-берсен кадерләп... Әмма алар, кешеләр озаграк яшәсен өчен үстерелгән медицина материаллары, мондый хокукны берәүдән дә ала алмыйлар. Кешеләр шикелле, үз язмышларын үзләре сайлау мөмкинлегенә ия түгел алар, чөнки.

> *Я видела стремительно возникающий новый мир. Да, более технологичный, да, более эффективный. Новые способы лечения старых болезней. Очень хорошо. Но мир при этом жесткий, безжалостный. И я видела девочку с зажмуренными глазами, прижимавшую к груди старый мир, более добрый, о котором она знала в глубине сердца, что он может остаться, и она держала и просила не отпускать ее.*

Исигуроны фантастикага китүдә, попсага гына яраклы темаларга мөрәҗәгать итүдә гаепләүчеләр булды, бу роман басылып чыкканнан соң. Гәрчә клоннар дип ул хокуксыз, кыйбласыз, тормыш шартлары яхшыра баруга карамастан, көннән-көн яшәргә сәләтсезрәк була барып, кешелек сыйфатларын коточкыч тизлектә югалтып шушы җәмгыятьтә яшәгән үзебезне атаса да. Үзеңне таныр өчен күбрәк тә көч һәм сәләт кирәк шул.

БЕЛЕШМӘ

1954 елның 8 ноябрендә океанограф Сидзуо Исигуро гаиләсендә туа. 1960 елда Сидзуо Исигуроны Британиядәге Океанография милли институтына фәнни хезмәткәр буларак чакыралар да, Исигуролар Гилфорд шәһәренә күченә. Кадзуо Стартфондагы мәктәпкә укырга керә, аннан укуын Суррейдагы Грамматик гимназиядә дәвам итә. Укуын тәмамлагач, бер елга академик отпуск алып, АКШ һәм Канада буйлап сәяхәткә чыгып китә. Музыкант булырга хыяллана, төрле клубларда уйный, җыр текстлары иҗат итә. Ул Америка джаз җырчысы Стейси Кентның берничә җырының авторы.

1974 елда Кент университетына укырга керә, 1978 елда аны инглиз теле һәм философия буенча бакалавр дәрәҗәсе алып тәмамлый. Лондонда социаль хезмәткәр булып эшли. 1980 елда Көнчыгыш Англия университетында сәнгать магистры дәрәҗәсенә лаек була. 1983 елда Кадзуо Исигурога Баритания подданные дигән таныклык бирәләр.

Кадзуо Исигуро хатыны Лорна Макдугалл һәм кызы Наоми белән Лондонда яши. Хатыны белән алар Ноттинг-Хиллда йортсыз җәнлекләрне караган приютта социаль хезмәткәр булып эшләгәндә танышалар.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ



«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы әдәби премиягә бәйге игълан итә

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибарны арттыру максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы – бәйгенең төп шарты!**

Кульязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2017 ел дәвамында «Татарстан» журналы Экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2017 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – белешмә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульязмалар tatarstan@tatmedia.com электрон тартмасына «КОНКУРСКА» тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны үткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан 2017 елның 15 декабренә кадәр.

Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ: **БАР ДА – АЛАР КУЛЫНДА**

«Бу бәйге аша без үзебез өчен яңа исемнәр дә ачтык, шулай ук моңарчы иҗатын белгән язучыларга да башка күзлектән карый алдык», – дигән фикердә тора жюри әгъзалары. Әйтергә кирәк, текстларга чынлап та зур җаваплылык һәм дулкынлану белән карады алар. Шулай итеп, гадел, кырыс хөкемдарларыбыз җиңүчене сайлаган арада, без аларның үзләре белән таныштыра торырга булдык.

Разил Вәлиев, Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүлеге лауреаты, Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе.

– «Татарстан» журналында берсен-нән-берсе саллы һәм эчтәлекле язмалар күп булса да, нишләптер, аның һәр санын алуга мин әдәби әсәрләр басылган битләрне эзли башлыйм. Һәм бу – гаҗәп тә түгел. Чөнки дөнья мәшәкатьләре белән тулган күңел үзен-нән-үзе матурлык, гүзәллек, зур мәгънәле фикер эзли. Журнал битләрендә тирән эчтәлекле хикәя яисә шигырь тапсам, мин шәһәр урамы читендә балкып үсеп утырган чәчәк түтәлен очраткандай булам.

Бүгенге көндә хикәя – әдәбиятның иң үтемле жанры, дисәм, ялгышмам кебек. Чөнки вакытлар кысылган, яшәү тизлеге арткан чорда кеше зур күләмле әсәрләр укырга вакыт таба алмый. Ә роман-повестька җитәрлек фикер-тәэсирләрне хикәя калыбына сыйдыру гаять зур әдәби осталык һәм талант таләп итә. Шунысы куанычлы, «Татарстан» журналында дөнья күргән хикәяләрнең күбесе бу таләпләргә – хикәя жанры таләпләренә җавап бирә. Конкурска йомгак ясагач, аларны аерым китап итеп чыгара алсак, бу безнең укучыларыбызга бик тә кадерле бүләк булыр иде.

СОҢГЫ АЙЛАРДА ДӨНЬЯ КҮРГӘН ХИКӘЯЛӘР ЖУРНАЛГА МАТУР БИЗӘК ӨСТӘП КЕНӘ КАЛМАДЫЛАР, РӘСМИ БАСМАГА РУХИ АҺӘҢ ДӘ ИҢДЕРДЕЛӘР, АНЫ УКУЧЫ КҮҢЕЛЕНӘ ТАГЫН ДА НЫГРАК ЯКЫНАЙТТЫЛАР.

Илдар Сәгъдәтшин, ТР «Татарстан китап нәшрияты» ДУП генераль директоры.

ӘДӘБИ БӘЙГЕ ИГЪЛАН ИТҮ ҺӘМ УЗДЫРУ ҺӘРВАКЫТ АКТУАЛЬ, ДИП УЙЛЫЙМ. ШАГЫЙРЬЛӘР, ЯЗУЧЫЛАР ӨЧЕН ДӘ, НӘШИРЛӘР ӨЧЕН ДӘ. ЧӨНКИ, ЯЗУЧЫ СҮЗЕ УЛ – БАСМАДА БАСЫЛА ТОРГАН СҮЗ

–Бүгенге заманда заманча, үзенчәлекле, ягъни популяр сүз белән әйтсәк, креатив каләм иясен табу – бик мөһим. Аның әсәрләре мавыктыра да, укучыда ихтыяҗ уята да торган булса, бу инде нәширләр өчен дә табыш. Чөнки автор укылса, ул сатыла да. Журнал игълан иткән бәйгедә җиңү – язучылар өчен менә дигән мөмкинлек. Әдәбият дөньясында исеме бик танылып җитмәгәннәргә – үзен таныту өчен, ә инде исеме күренгәннәргә – яңадан сынау узу өчен. Әдәбият дөньясында беренче чирканчык та, яңа сулыш та – бердәй кирәкле нәрсәләр.

Бу проектның нәкъ менә «Татарстан» журналы платформасында узуына мин үзем бик тә символик мәгънә салам, чөнки ул – саллы, зәвыклы укучысы булган басма. Аның бер гасырлык тарихы бар. Мине жюри әгъзасы буларак чакыруларын да зур дәрәҗә буларак кабул итәм, рәхмәт. Бәйгедә катнашкан һәркемгә уңышлар юлдаш булсын, җиңәсезме, юкмы, илһам сезне ташламасын, киләчәктә иҗади планнарыгыз тормышка ашсын!

Фотолар жюри әгъзаларыннан алынды.

Луиза Янсуар, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия, Халыкара Bella премиясе, ТР М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, «Татарстан» журналының әдәби редакторы.

ӘДӘБИЯТ ГОМЕР-ГОМЕРГӘ ҖӘМГЫЯТЬ ҮСЕШЕНӘ ТӘЭСИР ИТКӘН. БУ БӘЙГЕ АША СҮЗ КАДЕРЕ КИМЕГӘН, ЮГАЛЫП БАРГАН ЗАМАНДА ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕНЕҢ ЮГАРЫ ЭШЕЛОННАРГА ДА БАРЫП ҖИТҮ, УКЫЛУ МӨМКИНЛЕГЕ БАР.

– Язучы өчен шактый рәхимсез бүгенге вазгыятьтә каләм әһеленә карата кечкенә генә илтифат, якты йөз дә – могҗизага тиң. Күпмедер күләмдә матди әҗере дә булса – бөтенләй бәйрәм. Язучы, әгәр ул чынлап та җитди каләм иясе булса һәм үз-үзен хөрмәт итсә, очсызга сатыла торган затлардан түгел. Бу сүзләр бик пафослы яңгыраса да, Татарстандагы җәмгыятьтә дә язучы сүзенә һәм шәхесенә карата (спортка булган кадәренә үк өметләнү түгел, юк!) мөнәсәбәт беркөн үзгәрер, дигән теләк сүнеп бетми күңелдә.

Бәйгенең шарты: әсәрләрдә Татарстан кешеләренең язмышлары, кече ватан мотивы чагылу. Текстларны журналга әзерләгәндә, матур йолалар, милли традицияләр, язмыш борылышлары тасвирламасына юлыгабыз да, редакциябез белән чын күңелдән сөенәбез. Әдәби сүз тәме, яме белән хушланабыз. Бүгенге көндә хикәя жанры дөнья әдәбиятында да кризис кичерә, ди, әдәбият белгечләре. Әнә шул жанрга яңа сулыш өрү дә иде максатыбыз. Ул үзен аклады, минемчә.

Татьяна Вафина, «Татарстан» журналының баш мөхәррире.

ПРЕМИЯНЕҢ МАКСАТЫ – ТАЛАНТЛАРНЫ БАРЛАУ, БУЛГАННАРЫН БӘЯЛӘҮ ҺӘМ АЛАРГА МӘЙДАН БИРҮ

– «Татарстан» журналының миссиясе – игелекле эшләр, акыллы гамәлләр, мәңгелек кыйммәтләр турында язу гына түгел, ә аларны кешеләргә җиткерү, тормышка ашыру да. Шуңа без «Татмедиа» Республика агентлыгы белән бергә әдәби премия булдырырга карар кылдык. Башлап язучы каләм иясенең беренче китап чыгару мөмкинлеге шактый четерекле бит ул, инде исеме танылып килгән иҗатчылар өчен дә – җиңел генә түгел кайвакыт. Ә сәләтле кеше, гадәттә, үзе өчен сорап йөри белми. Монысы да – билгеле факт.

Безнең премиянең бурычы – гадел жюри сайлап алган әсәрләрдән китап төзү һәм нәшер итү. Жюри составына без китапка һәм әдәби сүзгә сак һәм җаваплы карый торган шәхесләрне генә сайлап алдык. Аларның карары кемгәдер канатлар куя алса, кемнеңдер иҗатына алга таба үсәргә ярдәм итә, димәк, без бурычыбызга ирешкәнбез. Бу бәйге һәр елны уздырыла торган булыр һәм «Татарстан» журналы тирәсенә тагын да күбрәк талантлы, кызыклы, үзенчәлекле кешеләрне туплар, дип ышанам.

Галимҗан Гыйльманов, А.Алиш, Ф.Хөсни, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Татарстан китап нәшрияты» редакторы.

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ КЕБЕК МӘРТӘБӘЛЕ БАСМА БИТЛӘРЕНДӘ ӘСӘРЕҢ ЧЫГУ – ҮЗЕ БЕР ГОРУЛЫК УЛ.

– Авторлар үзләренә нинди уңыш елмайганын сизгәндер, дип уйлыйм. Мин жюри әгъзасы булуыма шулай ук шатмын. «Татарстан», иҗтимагый-сәяси басма булуына карамастан, әдәби сүзгә һәрчак игътибарлы. Соңгы арада бу үзен аеруча сиздерә. Әдәбиятнең көче мәкаләләр көченә караганда да үтемлерәк. Чөнки, кайбер хакыйкатьләрне кешенең йөзенә бәреп, лозунг рәвешендә түгел, ә нәкъ менә хисләргә төреп, уйландыру, сискәндерү, елату халәтенә кертү аша җиткерергә кирәк. Идеологик көчен югалтса да, сүз тәэсир итү көчен югалтмады әле,



аның әнә шул хасиятен саклап калып, яңа буыннарга җиткерә алсак иде.

Безнең әдәбиятның да, сәхнә, эстрададан аермалы буларак, кыйбласы үзгәрмәде. Ул һаман да традицияләргә таяна, чишмә башының кая икәнен онытмый, экспериментлар, эзләнүләр дә хас аңа, әмма ул тоталь рәвештә үз кыйммәтләреннән баш тартмый. Бу бәйгегә килгән әсәрләрдә дә сизелә.

Ленар Шәех, ТР М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, «Татарстан китап нәшрияты»ның баш мөхәррире.

ӘДӘБИ БӘЙГЕЛӘР АША КАЛӘМ ИЯЛӘРЕНӘ ЯҢА ӘСӘРЛӘР ЯЗАРГА ЭТӘРГЕЧ БИРҮ ХУПЛАУГА ЛАЕК КҮРЕНЕШ.

– Бу үзенә күрә ярыш та, көрәш тә. Кем яхшырак яза, шул җиңә. Бүләге дә нинди бит – китабыңның басылып чыгуы. Язучы өчен моннан да зур сөенеч була аламы? Сабантуй батырына яулап алынган тәкә ничек кадерле булса, иҗат кешесенә дә китабы чыгу – зур бәхет, олы мәртәбә. Конкурсның җанры да бик үтемле – проза. Бүгенге укучы язучыдан яхшы әсәрләр көтә. Иншалла, «Татарстан» журналы оештырган бәйге безгә яхшылыкка дәшә, изге гамәлләргә этәрә, уйландыра торган яңа әсәрләр бирер һәм яңа исемнәр ачар!

PRESSA.RU

Роза Мулланурова (Камалетдинова) Әгерҗе районы Яңавыл авылында туып-үсә. Урта мәктәпне тәмамлагач, КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Казан электр техникумында китапханәче, Казандагы дары заводында чыга торган «Ленинчы» газетасында хәбәрче, редактор булып эшли. 1990 елдан «Азат хатын» – «Сөембикә» журналында – 25 ел буе әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөхәррире вазыйфаларын башкара. Татарстан Язучылар һәм Журналистлар берлекләре әгъзасы. «Чишмә күзе». «Ялгыз каеннан да ялгыз...» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.



Роза Мулланурова

Яшел алма

Гомер буе көткән... Ә Нурсинә бер-ике көнгә генә кайтып килмәкче иде. Авылда уттай эш өсте. Печәнгә төшкәннәр. Йорт исәбеннән бүлеп биргән чөгендерне чүп баскан, апасы кылны кырыкка ярырдай булып чабулап йөргән була. Йөрүе дә – йөрәк дарулары эчә-эчә генә инде. Ни йөзең белән: «Баланы калдырырга гына кайттым. Мине көтәләр, китәм», – дисең? Бәрәңге төпләре өеп, чөгендер утап көн арты көн узганы сизелмәде дә...

Ул уйнап әйтмәгән! Көтмәгән. Ничек болай булды соң әле бу? Йөрәк серен, кадерле сүзләрен әйтергә дә өлгермәде. Ярату идеме бу? Мавыгумы? Буш хыялга алданумы... Ачылырга, чәчәк атарга өлгермичә сулдымыни мәхәббәт гөле? Ачылмаган бөре! Хыялый күңелне алгысыткан ул кичләр хатирә генә булып калыр инде. Меңнәр арасында Ул – бердәнбер! Иде...

Акъегетнең сөйгәне! Ни хикмәттер, моның шагыйранә ялган, фәкать купшы, матур сүз икәнен белсәң дә, шуңа ышанасы килә. Чыркылдык кыз-кыркын сыман башны артка ташлап, дөнья яңгыратып бер көләсе иде дә... Бәлки чындыр? Хатын-кыз колагы белән ярата диюләре хак, күрәсең. Кибәккә алданырга чыпчык түгел, югыйсә. Мин күптән акыл утырткан, дип үзен ничек кенә ышандырырга тырышмасын, назлы сүз, вәгъдәләргә – хәтта ялганына да ереп китә шул кыз-хатын күңеле. Чөнки нәзберек, нечкә җан һәрчак җылы сүзгә мохтаҗ. Ә матур сүзләрне ишетеп өйрәнгәнмени ул?!

Ә ир-ат өчен яшәү мәгънәсе – яула һәм хакимлек ит! Үз дигәненә – теләгәненә ирешеп, өстенлеген раслау өчен сандугач булып сайрыймы әллә ир заты? Ата сандугач кына сайрый, дип бүтәннәрне дә ышандырырга тели... Янәсе, кыз-хатын – ана сандугачның сайрарга вакыты юк. Бала чыгарасы, үстерәсе бар. Нурсинә дә белә моны. Тик... ышанасың барыбер! Әгәр ышанмаса, өенә кайткач та, яшь кызлар кебек көзге алдында бөтерелер, әллә уйнап, әллә чынлап Акъегет әйткән шул сүзләрне кат-кат кабатлар идемени?

Сер түгел, яшьлек искән җилдәй сиздермичә үтеп бара. Гыйшык уены уйнарга соңдыр инде аңа! Бер тилереп алумы бу? Үзен шулай битәрләр, ә кеше күрмәгәндә, көзгегә күз салыр да: «Җитте сиңа, болай ашкынуың юньлегә булмас, кызый!», – дип, үзенә-үзе бармак янар. Әмма ниндидер бер җен, горурлыкмы шунда, күңелен кытыклап куяр: кырыкның аръягында да тормыш бар икән янәсе. Туй узган, тун тузган, дип исәпләү – хата булмагае!

«Алма бит син! Кызарып-янып пешкән, тулышкан, өлгергән татлы алма! Бәхәсләшмә, минем «глаз – алмаз»! Назга сусаган мондый чак та үтә ул, үтә! Яшәп калырга кирәк! Иртәгәгә калдырмыйча, бүген, хәзер яшәргә!» – дигән иде. Нурсинә көлгән булды. Дөрес, ул әле ирләр күзе төшмәслек түгел! Алмалар өлгерер чак көзгә тартым була бит. Ә шулай да... Керфек-кашын буяп, болай да ак йөзенә кершән дә тидерсә, иннекнең дә затлырагын сатып алса... Их, мәшһүр чәчтарашка язылып, чәчен Руфиянеке сыман кистереп-күпертеп, кул-тырнакларын каратып-ясатып чыгарга иде дә – чәчтарашка шулкадәр

Фото Goodfon.ru сайтыннан

акча чыгарып салырга башына тай типкәнмени аның? Тормышның очын-очка көчкә ялгап, тырышып-тырмашып яшәп яткан көне ич. Кулга акча керсә, мул итеп күчтәнәчләр алыр. Апасы үпкәли, сирәк кайтасыз, ди, белми, һәр тиеннең санаулы икәнен. «Илсурны бер-ике атнага авылга кайтар. Сөт-катык сатып алмаган. Сулап туймаслык саф һава. Чишмә суының сихәте тиеп терелеп, ныгып китмәсме?» – дигәч, кайтарган иде улын.

* * *

Ә Акъегет белән танышу-очрашулары бәхетле очраклылык идеме?! Әллә тәкъдир, язмыш дигәннәренең кулы уйнадымы? Нурсинәгә язмыш иркәсе булу язмаган икән: бик иртә үз көнен үзе күрергә туры килде аңа. Әллә ниләр майтарырдай булып, укырга керәм, кеше булам дип авылдан чыгып киткән иде. Кесәсендә җил уйнаган авыл әпәйләренә институт ишекләрен киереп ачарга атлыгып торучы юк икән. Акча, бөтен җирдә акча хакимлек итә. Һөнәрле үлмәс, дип фикер йөртте, тегү фабрикасына барып керде. Бер эштән дә тайчынмый торган тырыш иде ул. Баш күтәрми эшләде, уч тутырып акча алган чаклары булды. Тик... фатирга түлисе, кием-салым юнәтәсе... Тамакны да алдап булмый – ничек керсә, шулай тиз чыга акча. Өстәмә эшләр дә алып карады. Арттан этүчең булмагач, мантып китүләре харап кыен. Белә ул бу кадәресен! Эштән курыкмый. Нәселләре шундый. Юанычы эш булгач, нишләсен, чытырдап ябышты ул тегүгә дә.

Мәскәүдәге җиңел сәнәгать институтына читтән торып укырга керде. Бергә фатир тәшкән иптәше – Руфия үгетләде. Контроль эшләрне бергә-бергә эшләве күңеллерәк тә, җиңелрәк тә булыр, куктән манный боткасы яуганны көтеп утырасы түгел, тәвәккәлләргә, укырга кирәк, калышма, тырыш, диде.

Әти-әниле, тату гаиләдә, тигез канат белән үскән чая-үткен Руфия аңа күп яктан өлге, үрнәк булды. Әти-әнисе укытучы булгач, тиенгә аптырап йөрми. Өс-башы да гөлт иткән. Үзе дә төшеп калганнардан түгел, мал табу җаен белә. Бер үк юлларны таптап, җәйге-кышкы сессияләргә бергә йөри торгач, нык якынаеп, аерылмас дуска әйләнделәр. Тегү-чигүгә Нурсинәнең кулы ябышып тора: универмагта арзан, затлырак тукыма эләктерсәң, бәхет шул була! Шунда ук кистереп тә аласың. Прокатка алган тегү машинасында төн чыкканчы итәк, күлмәкне җөйләп алу аңа уен кебек иде. Кием-салымга аптырамый. Руфиягә дә тәккәне булды. Шундый заман иде: кесә тулы акчасы булганнар да килешле, әзер кием таба алмый йөди. Кул эше белүенә, осталыгына куанып туялмый ул. Дөрес, Руфия күз чекерәйтеп, энә белән кое казыгандай типчеп-җөйләп утыруны сөйми. Җитәкче булырга яратылган ул, кеше өйрәтүне кулайрак күрә. Хәер, эшне оештыра да, эшен күрсәтә дә белә.

Озакламый Руфияне мастер итеп куйдылар. Кешегә чыккан кояшны күпсенми Нурсинә – дустының бәхетенә сөенә генә. Руфия смена начальнигы вазыйфасын җилкәсенә алгач та: «Син булдырасың!» – дип канатландыручы ул булды. Берничә елдан профсоюз җитәкчесе итеп сайлануына да ихластан куанды. Аның дусты бит ул! Күз алдында үсте, моңа ничек шатланмыйсың!

Әмма җай гына үз эзеннән тәгәрәгән дөнья көтмәгәндә, күз ачып йомган арада, үзгәрде дә куйды. Фабрика-заводлар ябылды, меңнәр эшсез калды. Дөнья исәпләре болай да күптән Нурсинәнең үз башында иде инде. Соң гына, аспирантурада укып йөргән ыспай гына егеткә кияүгә чыккан иде дә, уңмады. Уңмадымы, язмыш сынауларын уза алмадымы гомерлек яр булыр дип сайлаганы... Югыйсә, матур гына яшәп киттеләр: уллары туды. Биш яшьлек чагында бала, авырып, урын хастасы булгач, кояшлы якты көннәр үткәндә – сагынып сөйләргә генә калды. Яшәвенең бар мәгънәсе – сабыен аякка бастыру, тернәкләндерү бит хәзер. Үзәккә үткән фәкыйрьлек, кысыбрак тотсаң, биш кешегә җитәрлек хәсрәт башына ишелсә дә кайгысын читкә чәчеп йөрмәде ул. Үзенекен үзе генә белде, кайгысын эчкә йотты. Хатын-кыз түзә ул, тик ир-ат мондый сынауларга чыдамый икән шул. Кемнең кемлеге кайгы килгәч беленә, яхшының – изгелеге, яманның әшәке холкы барыбер тышка бәреп чыга. Ире яшел еланны дус итте, шешәдәшләр тапты. Эшлим дип тотынган диссертациясе дә урыныннан кузгалмады, янды. Әкренләп йорттан да читләште. Хәер, өйгә кайткан чакларда да юкка-барга бәйләнеп тәңкәгә тиюләре үзәккә үтте. Ник бу күлмәк юылмаган да, ашау ягы такы-токы? Акланасы килми Нурсинәнең. Акча алып кайтканың бармы, дияргә гарьләнә. Йомшак холыклы, дуслар йогынтысына тиз бирешә, дип аклый ирен. Барысына да үзен гаепле саный: өлгермәве хак. Ир-ат халкы хәйләкәр песи бит ул: карап-тәрбияләп, сыйлап-сыйпап торганны ярата. Улы янынннан бушый алмавы хак. Ята торгач йә аркасы чиләнгән була, кайсы төше авыртканын әйтә-аңлата алмый көйсезләнә балакай. Табибына, массажистына, тагын әллә кемнәргә төртә торгач, акча янчыгы бик тиз шиңә. «Кысыр ашың кәҗәгә тансык», – ди дә кашыгын атып бәрә ир дигәнең. Дару исе дә укшыта аны, хатынның бимазалануы да күңеленә ятмый. Ә бер көнне: «Чыдарлыгым калмады», – дип әйбер-карасын җыештырды да юкка чыкты. Базарга хуҗа булып алган тау халкы эшмәкәрләренә ялланып, әллә сәүдә итүче, әллә шуларның күңелләрен күрүче бер җилбәзәк хатынга ияләшүен ишеткән иде, ышанасы килмәде. Утсыз төтен булмый, диюләре хак икән. Тапты үз тиңен...

Хыянәт ачысына тешен кысып түзгән булыр иде, болгавыр заманның рәхимсез, ачы җилләре икенче яктан китереп сукты: күз нурларыңны түккән хезмәтең өчен яртышар ел акча алмый яшәп кара әле! Алыпсатарлар заманы килде. Фабрика банкротлыкка чыкты. Әле дә ярый Руфия Рәшатовна:

– Төшенкелеккә бирелеп, борын салындырып утыра торган чак түгел. Үз эшебезне ачабыз, – дип, Нурсинә белән сер бүлеште.

– Ничек итеп?

– Җан биргәнгә җүн бирермен, дигән ди Ходай да. Хәлле генә дуслары – якташлары бар иремнең, булышырлар дип уйлыйм. Ишеткәнең бармы ООО дигәнне? Татарчалатсаң, җаваплылыгы чикләнгән оешма була. Барасыңмы?

– Алсагыз...

– Әйттем ич! Бергә ут-су кичкән дусны ярты юлда ташлап калдырыйм мени? Ни күрсәк тә бергә күрербез. Исемен – «Мәрхәмәт» дип уйлап торам. Мода йорты, шәфкать фонды... Директоры үзем. Син... Тумаган тайның билен сындырып куймыйк. Байларга аркаланмый булмас. Аннан... күз күрер.

Йомыш-юлга йөгерүче дә Нурсинә, вакытлыча өйдәш булып кергән, тузган бинаны җиң сызганып ремонтлау, бизәү дә аңа йөкләнде. «Нурсинә, бар! Нурсинә, тап! Тегесен җайла, монысын китер...» Юк, зарланмый ул. Ялгыш та канәгатьсезлек төсмерен йөзенә чыгармый. Чыдарга кирәк. Түзәргә һәм җиңәргә! Башка юл юк. Урам тулы эшсез. Руфия Рәшатовнага мең рәхмәт әйтеп, кушканын һәм кушмаганын үзең

PRESSA.RU

белеп эшлисе дә эшлисе генә. Хәер, Руфия үзе дә мин хуҗа дип кул кушырып утыра торган кеше түгел, телефоннан төшми, кирәк икән анда чаба, монда йөгерә, тегесен юнәтә, монысын... Эшләтә дә, эшли дә белә. Дөнья мәшәкатьләренә исе китми, йодрыгына йомарлап тотар өчен туган эшлекле, булдыклы ханым бит ул. Нурсинәнең дусты, таянычы, ярты бәхете ул Руфия Рәшатовна.

Эшмәкәрләр җыенына да ул алып килде аны. Киңәш-табыш итү нияте белән оештырылган җыелыштан соң санаулы гына җитәкчеләр өчен корылган мәҗлес – банкетка да Руфия Рәшатовна ияртеп алып керде. Нурсинәнең тизрәк өенә – Илсуры янына кайтып китәсе килә. Әзрәк утыргач, җайлап кына чыгып таю иде исәбе. Әмма хуҗа сүзенә колак салмый кара! Әнә: «Мондый җиргә халык ашап-эчеп утырыр өчен җыела дип белдеңме әллә!? Юк! Читләр алдында әйтелмәгән иң кыйммәтле фикер шундый тын табында телдән ычкына. Мыегыңа чорный барырга гына иренмә!» – дип, ярдәмчесен искәртеп куюы тикмәгә түгел бит! Мондый бәйрәм табыннарын өнәми Нурсинә. Хәер, сирәк эләгә андый җирдә кунак булу, әмма барса да үзен уңайсыз хис итә. Затлы ирләр, купшы ханымнар янында кием-салымның кимлеге-тыйнаклыгы күзгә ташлана. Белә, ялтыравыклы ул кичәләр аның өчен түгел. Чит ул монда, ят дөнья кешесе. Шуны белгәнгә уңайсызлана да.

Әнә, Руфия өстәл башында – түрдә ничек балкып утыра. Чибәр генәме, әллә нинди сөйкемле сөяге бар аның. Өс-башы дисеңме, үз кадерен белеп, вәкарь белән сөйләшүеме, елмайганда аны тагын да сөйкемлерәк итеп бит уртасы чокыраюмы... Серле итеп кенә көлемсерәве, җаен, вакытын, урынын белеп тапкыр сүз әйтеп куюы... Һәммәсен авызына карата. Бирсә дә бирә бит Ходай шундый сәләт, төс-бит бирәүгә! Такташ Алсуы! Ә бәлки артыграктыр да әле: үзе чибәр, үзе сөйкемле, үзе усал, үзе болай бердә усал түгел кебек шикелле. Кунак түрә – калын бәдәнле, елтыр башлы, күзлекле зур абзыең да күзен аера алмый аннан. Бер-берсен күптән белгәндәй якын итеп сөйләшәләр.

Ишеккә якынрак утырган Нурсинә сиздермичә чыгып китәргә кайчан җайлырак булыр дип карангалый да башлаган иде инде. Аның хәлендәге хатынга күзгә-башка чалынмый, вакытын белеп, тизрәк китү хәерлерәк.

Яңгыравыклы, купшы тостлар бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты, үз уйларына чумган иде ул. Ботка пешергән иде, суынып беткәндер. Ашый алдымы икән газизе? Тәрәзәдән күзен алмый, әни кайчан кайта дип көтәдер, бахыр. Ә әнисе утыра, өстәл сыгылырлык бай табындагы затлы ризыкларның кайсына үрелергә белми кыенсынып. Сабыена да авыз иттерәсе килеп... Ярамый! Хәер, яшәргә дә ярамыйдыр, бәлки! Ә яшәргә азапланабыз.

Музыкантлар бию көе уйный башлагач, халык кузгалгач, ул да шыпырт кына чыгу юлына борылыр. Руфия белән саубуллашыргамы, әллә инглизчә, берни әйтми кайтып китәргәме? Килешерме икән, дип аптырабрак утыра...

Шулчак иңендә кемнеңдер саллы кулын тоеп сискәнеп китте. Күтәрелеп карарга базмады. Шулай тын гына утырса, чакырылмаган кунак: «Бер мокыт икән бу!» – дип борылып китәр кебек тоелды. Фәкыйрьлеген сиздермәс, эшкә кия торган, табаны тузган туфлиен күрсәтмәс өчен ул мокыт дип аталырга да риза иде. Кулын җилкәсенә куйган ир затының дәрәҗәле кунакларның берсе булу ихтималын затлы ислемай исеннән чамалап өлгергән иде. Каушады, торырга да, утырып калырга да белми, үзен ут арасында калгандай хис итте.

– Нурзидә, биергә чакыруымны кабул итегез!

Сүзе китапчарак булса да бәрхет тавышы ягымлы, ә куллары... Ул аны-моны әйтеп өлгергәнче корычтай беләкләр тәкәллефсез генә биленнән эләктереп, хәтта күтәреп үк алды да, зырылдатып түгәрәк уртасына алып чыкты. «Гафу итәрсез, бии белмим», – дип мыгырдануын ишетмәдеме, юри саңгыраугә салыштымы, җилтерәтеп, үз артыннан ияртеп, әйләндерергә тотынды. Чынлыкта, уртада зал тутырып алар икәү генә бии-әйләнә икән. Калганнар түгәрәк хасил итеп, күрелмәгән кызыклы вакыйгага шаһиты булгандай бәхетле елмаеп, бу икәүгә сокланып, кул чабып торалар. Көчле куллардан ычкынырга теләсә дә, ир затының Нурсинәне җибәрергә исәбе юк иде, ахрысы. Башы әйләнеп, менә авам, менә авам, дигәндә музыка туктады. Партнеры аны читкәрәк әйдәде. Кулъяулыгын җилпәзә кебек җилләтеп, әллә сокланып, әллә кызганып озак кына аңа карап торды.

– Чакырудан баш тарткан кыз-хатын юк иде әле, дисәм... Моңарчы үзләре чакырып теңкәгә тия иде, – дип көлде, үткен карашын Нурсинәдән аермыйча гына. – Син – беренче. Абзаңның теләгенә каршы килергә җөрьәт иткән ханым... Сәер хәл бу... – Битәрли идеме ул аны, әллә сөйләшү рәвеше шундыймы, ә Нурсинәдә тик бер теләк, моннан тизрәк чыгып качу уе гына иде. Нурзидә дип эндәшүен дә колак яныннан үткәреп җибәрде. Нурсинә мин, дип төзәтүне кирәк санамады. Нурзидә икән, Нурзидә! Баш әйләндергеч тизлектә бөтерелүләре дә, ир затының көчен һәм өстенлеген раслап сөйләшүе дә, базык гәүдәле тәбәнәк – карсак булуы да, хәтта беләкләреннән көче ташып тору – берсе дә охшамады аңа. Кәтәнә ирләрне өнәми, нигәдер ким күрә... Ә чыны... Хикмәт буйдамыни?! Бәхетсезлеккә тарыган улын ташлап киткән ир: «Буй – наратның ярты-сы» дип мактанырга ярата иде, сыналыр чак җиткәч, ярыкка кысылган таракан кебек күзгә-башка күренмәс булды. Кызганыч... Сиздерми генә чыгып сызу нияте барып чыкмады. Чәчен рәтләү сылтавы белән хатын-кызлар бүлмәсенә төшүгә, Руфия Рәшатовна сак кына терсәгенә орынды:

– Акъегет кызыксына: мин белмәгән чибәр ханым кем, дип сораштыра! Күзе төшкән, ахры. Сер бирмә. Югалып калма! – Кем ул Акъегет, дип кызыксыну, әлбәттә, урынсыз монда. Кем белми аны, надан, дип көләчәкләр. Күп тапкыр ишеткәне булса да, күреп-белми аны Нурсинә. Хәер, кайсыбер кешеләрне күреп белгәнче, ишетеп кенә белүең отышлырак, диләр түгелме?!

Руфия аны кабат залга алып керде. Янәшәсендәге буш урынга утыртты.

– Авыз ачып утырма. Уйна, көл, озатам, дисә каршы килмә. Бел, гомердә бер була мондый очраклылык. Кешесенә туры килү, диюем. Күк капусы ачылды, дип уйла. Кешелекле ул. Тормышың авыр, ярдәме тияр...

(Кыскартылып бирелә. Тулы вариантын сайтыбызда табарсыз)


Большое Нуркеево
Сакла-Баш
Ляки
Азалаково
Петровский Завод
Мелля-Тамак
Кавзияково
Ташлияр
Тойгильдино
Сарман
Альметьево
Илексаз
Михайловка
Мурзыш-Тамак
Рангазар
Старый Каширо
Бикарай
Александровка
Татарский Шуган
Ләшәү Тамак
Кужак
Чубар-Абдуллово
Старый Мензелябаш
Новоникольск
Җәлил
Сулеево
Масягутово
Новое Каширово
Кзыл-Елга
Альксеево
Кама-Исмагилово
Новое Надырово
Мальбагуш
Мальнгуз
Әлмәт
Азнакай
Нижняя Мактама
Бишмунча
Верхняя Мактама
Актюбинский
Тайсуганово
Абдрахманово
Васильевка
Чемодурово
Кудашево
Микулино
Зай-Каратай
Старое Сумароково

PRESSA.RU

САРМАН – ТИГЕЗЛЕК ХӨКЕМ СӨРГӘН ТӨБӘК

Фәрит Хөснуллин, Сарман районы башлыгы.

Сарман – халкы тыныч авыл тормышы, сокландыргыч булдыклылык һәм гаҗәеп хезмәт сөючәнлек арасында тигезлек саклап яши торган уникаль урын.

Автор:
Алсу Троицкая

ЯХШЫ ТӘЭСИР ГАРАНТИЯЛӘНӘ

Мөгаен, шуңа да бу авыл халкы иң гади нәрсәләр турында да искиткеч зәвык белән һәм тәэсирләнеп, дәртләнеп сөйли. Ә ничек җырлый алар! Илһам Шакиров, Зөһрә Сәхәбиева, Зөһрә Шәрифуллина, Гөлдания Хәйруллина – исемнәре легендага әйләнгән җырчылар. Яшь башкаручылар да бик талантлы – Алинә Прокофьева, Динә һәм Дилә Кыямовалар…

– Мин алар белән горурланып кына калмыйм, аларны бик яратам да, – дип сөйли Сарман районы башлыгы Фәрит Хөснуллин, безнең журналистлар өчен авыл һәм район буйлап шәхси экскурсиясен башлаганда. – Нәкъ менә аларның иҗаты татар теленә һәм халкыбызның гореф-гадәтләренә иң шәп реклама булып тора.

Урамда ноябрьгә хас холыксыз һава булса да, читтән торып, «кабинеттан» гына түгел, бәлки чын экскурсия үткәрергә карар кылынды. Фәрит Мөнәвирович әйтүенчә, Сарман җиренә килгән һәркемгә бирердәге табигать һәм гүзәл урыннар белән хозурланудан матур тәэсирләр алу гарантияләнә.

Күптән түгел ачылган Татар Илеге паркына барганда, башлык күп нәрсә белән таныштырырга өлгерә:

– Быел районыбызда федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге программаларны гамәлгә кертүне дәвам иттек. Хәзерге вакытка аларның барысы да диярлек төгәлләнде. Бу – социаль әһәмияткә ия объектларны – медицина, мәдәният һәм мәгариф учреждениеләрен, универсаль спорт мәйданчыкларын, сәламәтләндерү комплексларын, авыл советлары биналарын, күпфатирлы йортларны, ишегалларын, автомобиль юлларын, газ һәм сүүткәргечләрне, авыл хуҗалыгы секторы объектларын төзү һәм аларны капиталь ремонтлау, җәмәгать урыннарын, су хуҗалыгы комплексын үстерү… Без барлыгы 29 программа буенча эшләдек, аларның күпчелеген гамәлгә керттек.

Каршыга очраган машина йөртүчеләр, Хөснуллинны танып, сигнал биреп сәламли. Бирердә башлыкны белмәгән бер генә кеше дә юктыр кебек тоела.

– Мин бирердә тудым, бирердә, авылда, мәктәпне тәмамладым. Авыл хуҗалыгы институтыннан соң туган ягыма әйләнеп кайттым, – дип аңлата Фәрит Мөнәвирович.

…Хөснуллинның кылларын тарткалап, төрле дәрәҗә, урыннар белән кызыктырып караганнарын соңыннан гына белдек. Казанда төпләнергә дә мөмкинлеге булган икән, әмма үзенең яраткан Сарманына хыянәт итмәгән. Эшкә ул җәяү йөри. Моның шулай икәнен яхшы белгән җирле халыкның аеруча әрсезләре, Фәрит Мөнәвирович иртәнге сукмагында тотып, аңа үзләренең гозерләрен, тәкъдимнәрен тапшырудан да тайчынмый. «Шәхси мәсьәләләр буенча кабул итүнең» сарманча варианты булып чыга инде бу.

БӨТЕН ЫСУЛЛАР ДА КИЛЕШӘ, ЯКИ НЕФТЬЧЕЛӘР БЕЛӘН АВЫЛ ХАЛКЫ ТАНДЕМЫ

– Менә карагыз: бөтен җирдә төзелеш бара, хәзергә кадәр эш кайный. Хакимият бинасы каршындагы яңа паркта яктылык сибә торган фонтанны ноябрь башында җибәреп карадык, майда ул инде даими режимда эшли башлаячак. Киләсе елга нефть-газ табу идарәсе урнашкан Җәлил бистәсендә дә яктылык та сибә, музыка да уйный торган фонтан ясарга ниятлибез. Җәлилләр мондый бүләккә лаек, дип уйлыйм. Без нефтьчеләребезнең уңышлары белән ихластан горурланабыз, алар, тәүлегенә 12шәр

Фотолар: Александр Ефремов, Сарман муниципаль районы администрациясе архивыннан.



ТАНЫШТЫРУ КАРТОЧКАСЫ

Сарман – республиканың көнчыгышында урнашкан район, аңа 1930 елда нигез салынган. Мәйданы – 1385 квадрат километр. 1 шәһәр, 22 авыл җирлегендә, 68 торак пунктта 36 меңнән артыграк кеше яши, шулардан 8 меңгә якыны – район үзәгендә, 14 меңгә якыны – шәһәр тибындагы Җәлил бистәсендә.

тонна нефть чыгарып, «Татнефть» ГАҖндә алдынгы урыннарда бара. Былтыр без нефтьчеләр ярдәмендә Җәлилдә балалар өчен ун уен мәйданчыгы, быел Сарманда тагын җидене ясап куйдык. Җәлил нефтьчеләре идарәне югары социаль нәтиҗәле итүнең тулы бер системасын булдырган. «Җәлилнефть» НГТИ түбәндә санап кителгән менә дигән социаль объектларны төзеде һәм аларны бик яхшы карап тота: «Җәлил» шифаханә-профилакторие, заманча «Дуслык» балалар сәламәтләндерү лагере, чаңгы спорты комплексы, бассейнлы һәм заманча җиһазландырылган тренажер заллы спорт-сәламәтләндерү комплексы, боз мәйданчыгы ел әйләнәсе эшли торган Спорт сарае. Гомумән алганда, нефть тармагы, авыл хуҗалыгы тармагы белән берлектә, Сарман районы икътисадының һәм социаль сферасының ныклы нигезе булып тора. Һәм анда яшәүчеләрнең барысы да туган җиребезнең үсешендә һәм гөрләп алга баруында, сәламәт яшь буын тәрбияләүдә үзләренең роле никадәр әһәмиятле булуын яхшы аңлый. Мәктәпкәчә яшьтәгеләр үзләренең камил формалашуы һәм мәктәпкә әзерлеге өчен бөтен шартлар тудырылган балалар бакчаларына һәм ясләләргә йөри. Балалар бик яхшы мәктәпләрдә укый, алар анда белем алып кына калмый, хореография, вокал, театр сәнгате, гамәли иҗат белән дә шөгыльләнә ала. Хоккей, волейбол, баскетбол, футбол мәйданчыкларында, бассейннарда һәм спорт комплексларында яшүсмерләргә спорт белән шөгыльләнер өчен менә дигән мөмкинлекләр тудырылган. 1–3

1

2

3

PRESSA.RU

1

ТАТАР ИЛЕГЕ –ТЫНЫЧ УРЫН

– Без хәзер Ленин урамыннан барабыз, – дип, экскурсияне дәвам итә Фәрит Хөснуллин. – Быел монда да күп нәрсә эшләнде: үзәкләштерелгән суүткәргеч һәм канализация капиталь ремонтланды, яңа асфальт салынды. Киләсе атнага агачлар утыртырга җыенабыз.

Ә менә тагын бассейн һәм спорт комплексы, 1 нче мәктәп, авылдагы ике светофорның берсе. Без соңгы елларда күзгә күренеп үскән бистәгә якынлашабыз. Биредә 200ләп яшь һәм күп балалы гаилә яши. Нәкъ менә шул урында әниләр – бәбиләре белән, әбиләр оныклары белән рәхәтләнеп һава сулап йөрерлек яңа парк төзүнең никадәр мөһимлеген сез үзегез дә яхшы аңлыйсыз бит. Һәм без аны төзедек тә. Анысын да республика һәм муниципаль район катнашындагы җәмәгать урыннарын үстерү программасы буенча тормышка ашырдык. Сулыгы да булган бик гүзәл, тыныч парк килеп чыкты. Аның тирәнлеген, су астында конкурслар оештырып, 2 августта җирле десантчылар чамалап карады инде. Яр буенда 1,5 метр булса, эчтәрәк 3-4 метрга да җитә!

Бер ел элек бу ташландык урын, чүплек иде. Бәләкәй генә Татар Илеге инеше ага, паркны да шуның исеме белән атадык. Әнвәр Залаков җитәкчелегендәге мелиораторларга рәхмәт – шундый сулык ясау идеясе аныкы иде, ә «Сарман «Мелиорация» КМК» ҖЧҖ подрядчы булды.

Быел биредә тренажер һәм 600 метрлы роллер-велосипед юлы, спорт мәйданчыгы пәйда булды. Янәшәгә кечкенә вагон куярга җыенабыз – теләгән кеше киемен шунда алыштыра алачак. Ял көннәрендә, бигрәк тә җәен, монда халык бик күп. Һәм шунысы сөендерә: кешеләр мондый объектларга саграк карый башлады. Берәр вандал пәйда булган очракта да, ул җимергәннәрне төзәтеп куярлык дистәләгән кеше табылачак.

Сүз уңаеннан, ярдәмчеләрем белән мин дә паркта киңәшмәләрне шактый еш үткәрәм – төзелештә килеп туган сорауларны урында тикшерү уңайлырак. 1

ТУРИСТЛЫК РУХЫ ЯШӘГӘН УРЫНДА

Без Сарманның легендалары яшәгән җиргә якынлашабыз. Фәрит Мөнәвирович бизәлешенең төп элементы «Бакыр тау» язуы булган тауга таба күрсәтә. Бу – Сарман бренды. 2–3

– «Бакыр базы» – бакыр рудниклары комплексы, – дип аңлата ул. – Аның төрле биеклектәге буталчык галереяларында адашып та, тар тишекләренә кысылып та ка-

2

4

лып була. Әмма бу урын туристлар, спелеологлар, географлар, археолог һәм тарихчылар арасында бик популяр. Билгеле, без бик кызыклы тур ясап, анда рудникны да кертү турында уйланабыз. Әлегә барысы да истәлекле урын статусын бирү стадиясендә, әмма без инде бүген үк турбизнес уенчылары белән сөйләшүләргә әзер. Безнең Сарманны туристларны җәлеп итәрлек үзәккә әйләндерү өчен бөтен мөмкинлекләребез бар. Күрсәтерлек һәм гаҗәпләндерерлек урыннарыбыз күп ләбаса! Чишмәләр, аэродром, – әнә, карагыз, җиңел моторлы самолет оча. Яхшыбай, Яхшы Каран һәм Иске Минзәләбаш авылларындагы борынгы мәчетләр, Язикәү авылындагы Михаил-Архангел чиркәве, Бөек Ватан сугышы һәм төбәкне өйрәнү музее, дүрт Георгий хачының тулы кавалеры, Беренче бөтендөнья сугышы каһарманы Шәйдулла Асылгәрәев кабере... 1916 елның 4 июнендә Император галиҗәнапләре үзен прапорщиклыкка күтәргәндә, Шәйдулла Асылгәрәевкә нибары 28 яшь булган! Әкренләп без үзебездәге истәлекле урыннарны торгызабыз. Бәхеткә, Александр Андров һәм Валентин Сапожников кебек җирле меценатларыбыз да бар. Кирәк булганда, бөтен кеше ярдәмгә килергә әзер: менә хәзер Сарманда өченче мәчетне төзибез, хәтта әбиләр дә акча бирә.

Бакыр тау янындагы менә бу кечкенә генә урында да – бакыр рудниклары, «Кара-каршы» чишмәсе, 4 кондызлы буа урнашкан. Ә инде тауга менсәң, ачылган манзарадан шундый рәхәт була! Менә ул бәхет! Әгәр буш вакытыгыз булса, сез дә мондый релакс мизгеленнән файдаланып калыгыз. Булыша! Әнә, күрәсезме, кемнәрдер бездән уздырган инде. Автобус белән килгәннәр, күбәү, мөгаен. Әйтәм бит, бирредә туристлар бер дә бетми.

– Фирма хезмәткәрләренә бүләк буларак Татарстанның уникаль урыннарына сәяхәтме? Бик шәп! Рудникка озатучы белән киткәннәрдер бит? Алексей беләнме? Бусы яхшы, ул бик тәҗрибәле спелеолог, – дип, кайбер кунаклар белән сөйләшеп алырга да өлгерә экскурсия үткәрүчебез.

Туристларның җавапларыннан соң тынычланып һәм аларның кыр кухнясына – боткалы казан һәм гаять зур термоска күз төшереп, район башлыгы елмая һәм мантыйкка ялгап дәвам итә:

– Сүз уңаеннан, киләчәктә без гурманнар өчен хәтта гастрономик тур да оештыра алабыз. Бездә бит бөтен нәрсә үзебезнеке, экологик яктан чиста. Зәңгәр тауларның бакыр рудникларында фильтрация үткән «Сарман» суы да, «Сарман ите» цехларында иң тәмле

3

PRESSA.RU

1

2

– Их, кызганыч, җаен килмәдегез. Тик җай көне килгән булсагыз, безнең никадәр чөгендер җыюыбызны күрмәс идегез. Аның тулай уңышы буенча без республикада беренче урынны алдык, – дип тыныч кына сөйләвен дәвам итә Фәрит Мөнәвирович.

иттән ясалган пилмән дә, «Сарман икмәге» пешергән хуш исле икмәк тә – үзебезнеке. Хәзер менә сөт комбинаты да чимал кабул итә башлады. Киләчәктә «Сарман атланмае» брендын торгызырга ниятлибез.

КАРА ТУФРАК БУЙЛАП САФАРИ

– Их, кызганыч, җаен килмәдегез. Тик җай көне килгән булсагыз, безнең никадәр чөгендер җыюыбызны күрмәс идегез. Аның тулай уңышы буенча без республикада беренче урынны алдык, – дип, тыныч кына сөйләвен дәвам итә Фәрит Мөнәвирович, без исә, машинабыз Янурыс авылы янындагы тайгак юлдан очып чыкмасын дип куркып, утыргычларыбызга сеңеп барабыз.

– Быел бөртеклеләрнең уңдырышлылыгы гектарыннан – 44,4, шикәр чөгендеренеке 458 центнерны тәшкил итте. 1 Бөртеклеләрнең тулаем уңышы – 190,2 мең тонна. Бу – Татарстандагы иң яхшы нәтиҗәләрнең берсе. Бездә бодай, арыш, арпа, солы, кукуруз, борчак, люпин, көнбагыш, рапс үстерелә. Аграрийларыбыз, бер шартлы башка исәпләгәндә, 48,8 центнер (саламнан башка) азык берәмлеге әзерләде. Районда терлекчелек тә динамик үсештә. Барлыгы 20,8 мең тонна сөт, 1645 тонна ит җитештерелде, бу 2016 елга карата 108 һәм 114 процентны тәшкил итә. Без сарманлыларның шәхси ярдәмче хуҗалыкларына да актив ярдәм күрсәтәбез. 2017 елда 9 ШЯХ сөт юнәлешендәге мини-фермалар төзү чыгымнарының бер өлешен каплауга бер миллион ярым сум күләмендә субсидияләр алды. Кош-корт сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга 299 мең сум, ана терлекләрнең баш санын арттыруга 8,8 миллион сум бүленде. Иң күп савым сыеры асраучы хуҗалыкларга ярдәм йөзеннән Сарман муниципаль районы бюджеты хисабына 16 саву аппараты сатып алынды. «2015-2017 елларда эш башлаучы фермерларга ярдәм» программасы буенча барлыгы 6 миллион сумлык 3 грант бирелде. 3 миллион 639 мең сум күләмендәге грантны «2017 елда ТРнда КФХ базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» программасы буенча бер фермер алды.

Без кырлардагы эш нәтиҗәсе буенча атна саен йомгак ясыйбыз. Һәм иң яхшы комбайнчы, агроном, машина йөртүчеләрне бүләклибез. Ә терлекчелек буенча ай саен сыер савучыларны, бозау караучыларны, терлекчеләрне, ферма мөдирләрен, квартал саен комплекс җитәкчеләрен бүләклибез. Без районның икътисадый үсеше, аның хуҗалыкчылык нигезенең авыл хуҗалыгына нигезләнүен аңлыйбыз. Бу безнең районның гербында да чагыла: алтын башакта һәм табигать, сәламәтлек, уңдырышлылык символы булган яшел төстә. Авыл хезмәтчәннәренә финанс ярдәме күрсәтү генә җитми. Без аларны үзебезнең газетабызда да мактыйбыз, данлыйбыз, концерт куярга популяр артистларны да чакырабыз. Менә үткән атнада Сарман Мәдәният йортында уңыш бәйрәме үткәрдек. Салават Фәтхетдинов үзе концерт куярга килгән иде! Шунысын да әйтү урынлы булыр: киләчәктә артистларыбыз яңартылган Мәдәният йортында чыгыш ясаячак – киләсе елда аны капиталь ремонтларга җыенабыз. Менә хәзер без яныннан узып барган Үзәк район хастаханәсе бинасын да ремонт кәтә.

МОННАН ДА ШӘБРӘК ЭШ ЮК!

– Карагыз әле, безнең Сарманда коелар нинди! Без аларны ел саен үзара салым акчасына төзекләндерәбез, тәртипкә китерәбез. Быел шул рәвешле биш коены реставрацияләдек. 2 Гомумән, үзара салым турында фикерләр күп төрле. Кемдер ике куллап түләргә әзер, кемдер кискен каршы. Әмма, тәҗрибә күрсәткәнчә, бу акча хисабына ишегалларын, юлларны, зиратларны тәртиптә тотып, яңгынга каршы чаралар үткәреп була. Бюджеттан бүленгән акчалар һәрвакытта да район һәм авыл хаҗәтләрен үтәргә җитәрлек түгел бит. Моның

референдум юлы белән хәл ителүе дә мөһим. Без һәрвакыт халык фикере белән исәпләшергә тырышабыз. Һәм әлеге фикер теге яки бу конкрет проблеманы хәл иткәндә һичшиксез исәпкә алына.

Күрүегезчә, биредә Минзәлә елгасы үзәнен турайту һәм ярларын ныгыту эшләре бара. Бетон плитәләр куябыз. Моңа «2014–2020 елларда Татарстан Республикасындагы әйләнә-тирә мохитне саклау, табигый байлыкларыннан файдалану һәм торгызу» программасы буенча 20 миллион сумга якын акча бүленгән. Астарак та яр буйлары төзекләндерелде, анысы да республика программасы буенча. Әгәр сез, инде әйткәнемчә, җәй көне килгән булсагыз, бик матур, динамик кадрлар төшергән булыр идегез – сарманлылар, аеруча бала-чага, анда рәхәтләнеп су коена һәм буш вакытларын үткәрә.

Нинди хыялым бармы? Якташларым барысы да яхшы яшәсен иде. Биредә, Сарман җирендә, һәркемгә дә уңайлы булсын иде. Яшьләр туган җирләрендә калсын иде – асылда барысы да шуның өчен эшләнә бит. Һәм Татарстан Республикасы Президенты карарлары, бүгенге республикакүләм һәм федераль программалар, төрле президент проектлары (без аларда да катнашабыз) нәтиҗәләрен күреп, әкренләп яшьләр дә авылда калуны сайлый башлады. Минем фикеремчә, әгәр яңа җитештерүләр пәйда булса, тагын да зуррак перспективалар ачылачак. Менә бүген сөт заводын торгызу өмете бар. сөт, кефир, май җитештерергә, шул ук вакытта авыл халкын яңа эш урыннары белән дә тәэмин итәргә планлаштырабыз. Икмәк белән барып чыкты бит! 600 килограммнан башлаган идек, хәзер инде бөтен күрше районнарны да тәмле күмәч белән тәэмин итәбез. Сөт белән дә барып чыгар, иншаллаһ! Минемчә, авылда нәкъ менә шулай яшәргә кирәк тә – сыерлар котәргә, фермалар салырга, иген игәргә, тәмле атланмай ясарга һәм икмәк пешерергә!

Җәлил гимназиясендәге бу искиткеч матур кышкы бакча кабатланмас җәй атмосферасын тудыра, укучыларга, укытучылар һәм ата-аналарга биредә никадәр яхшы, җылы һәм уңайлы икәнне сиздерә. Урамда нинди һава торышы булуга карамастан, биредә рәхәт. Заманча залда спорт дәресләре, хореография һәм вокал дәресләре бара. Гимназия ашханәсендә көненә ике тапкыр тәмле ризык әзерләнә. Биредә балалар турында кайгыртулары сизелеп тора.

Җәлил бистәсендәге «Әкият» балалар бакчасында педагоглар сабыйларны иртәнге сәгать алтыдан ук каршы ала, чөнки аларның әти-әниләренең, нигездә, нефтьчеләрнең, эш көне бик иртә башлана. Әмма алар үз сабыйлары өчен тыныч була ала: «Әкият»тә идеаль шартлар тудырылган. Биредә физиотерапия процедуралары да, массаж да, логопед белән дәресләр дә бар, ә иң мөһиме – кайгыртучан педагоглар.

Бу искиткеч авыл күренешләрен Ләшәү Тамак авылында сынлы сәнгать һәм технология укытучы Илдус Хәлимов һәм аның укучылары ясаган. Аларны күреп алган сарманлылар район үзәге урамнарына да шундый сыннар куярга кирәк, дигән фикергә килгән. Хәзер зур агач аюлар кинотеатр һәм почта арасындагы мәйданны бизи.

PRESSA.RU

Атаклы таш ФТЛ-мич. Чылбырлы механизм ярдәмендә кирпеч ипиләр мич эчендә әле аска, әле өскә күчерелеп, төрле температурада «сәяхәт итә» һәм тигез пешә. Рус һәм татар миченең үзенчәлекле кушылмасы ул.

Алар иң тәмле һәм хуш исле ипи пешерәләр.

Фото: Александр Ефремов

ИПЕКӘЙ һәм ипекәй янына – май

Менә инде берничә ел көн саен иртәнге сәгать өчтән алтыга кадәр «Сарман икмәге» ҖЧҖнең ипи-күмәчләре Татарстанның җиде районындагы кибетләргә, балалар бакчаларына һәм мәктәпләргә тарала.

Рөстәм Нуруллин, «Сарман икмәге» ҖЧҖ генераль директоры

– Ипи пешерү җайлы эш түгел. Аны йә күңел салып эшләргә, йә бөтенләй тотынмаска кирәк, бу эштә билгеле бер күнекмә-тәҗрибә белән генә чикләнергә ярамый, – дип аңлата «Сарман икмәге» ҖЧҖ генераль директоры Рөстәм Нуруллин. – Монда хәтта бүген кайсы аяктан торуың да, эшкә нинди кәефтә баруың да әһәмиятле. Безгә килгән ун кешенең, кагыйдә буларак, берсе генә чын-чынлап урнашып кала. Ә инде шул калганнары намус белән хезмәт куя. Безнең алтын хәзинәбез әнә шул кадрлар ул.

«Сарман икмәге» тарихы 2011 елдан башлана. Алты ел элек Рөстәм Рифкатович, районның икмәк пешерү традицияләрен кире кайтарып, җитештерүне җайга салырга катгый карар кыла.

– Сарманда ипине һәрчак тәмле пешерәләр иде. Һәм кинәт кенә икмәк заводы ябылды да куйды, кирпеч ипиләрне, батоннарны Әлмәттән һәм Тукай районыннан китерә башладылар. «Без кай җиребез белән ким әле? Сарман хатыннары була торып, үз ипиебезне пешерә алмыйбызмыни?» дип уйладым шул чакта. Якташларның табынында бернинди химик матдәләр кушылмаган табигый ризык кына булырга тиеш, дип карар кылдым. Җирле кулланучылар җәмгыятеннән икмәк заводының иске бинасын сатып алдык та мөмкин булган җиһазларны төзәттек, төзекләндердек. Кредитлар алдык, кайбер механизмнарны лизинг ысулы ярдәмендә кайтардык. Җиһазлар сатып алуга барлыгы 30 миллион сум акча тоттык. Шунысын да искә алыйм: икмәк пешерү җиһазлары шактый кыйммәт, өстәвенә, даими куллана торгач, ватылып китәргә дә күп сорамый. Шуңа күрә мөмкинлек булганда үз илебездә ясалганын алырга тырышабыз. Дөресен әйткәндә, алар ешрак ватыла, ләкин безнең осталар кул астында булган материаллар белән нәрсәнедер үзләре дә төзәтеп куя ала. Бик кирәк булганда, бу җиһазларны җитештерүче заводка барып, бер тәүлек эчендә запас детальләр белән кире әйләнеп кайтырга да мөмкин. Бездә бит конвейерны беркайчан да туктатырга ярамый.

Икмәк заводын торгыза башлаганда, уйлап җиткермичә, ике ФТЛ-мичнең берсен сүтеп ташлавыма бүген бик үкенәм. Элегрәк Россияне нәкъ менә шундый мичләр ашаткан, дип сөйлиләр. Ул вакытта эшләрнең ничек барачагын чамалап бетермәдем, ә бу тармакта керемне тәүлегенә, кимендә, дүрт тонна икмәк җитештерә башлагач кына алып була икән. Бәхеткә, мичнең берсен саклап калган идек. Һәм аны яңадан җыйдык дисәк тә, арттыру булмастыр, яңа валлар, чылбырлар һәм башка кирәк-яраклар куйдык. Хәзер исә кирпеч рәвешендәге барлык ипи дә шунда пешерелә. Ул чын-чынлап өйдә пешерелгән кебек: шундый ук хуш исле, тәмле, тышы да кетердәп тора. Ашап туймаслык!

Беренче вакытларда без нибары 600 килограмм икмәк-күмәч эшләнмәләре пешерә идек. Хәзер ассортиментыбызда 50ләп төр ризык бар, ә тәүлеклек җитештерү күләме 9 мең килограммга диярлек җитә. Шушы тәмледән-тәмле ризыкларны 70ләп кеше әзерли, ә 20 машина йөртүчебез Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Зәй, Минзәләгә алып китә.

Рөстәм Нуруллин әйтүенчә, предприятиенең уңыш сере кадрларга гына түгел, ә ризык әзерләгәндә бик сыйфатлы ингредиентлар куллануга да бәйле:

– Без акчаны янга калдырабыз, дип, сыйфат мәсьәләсендә экономия ясамыйбыз, зур-зур керемнәр артыннан кумыйбыз. Әйләнеш күләмен арттыру хисабына үзебезнекен алабыз. Бу бик кулай ысул түгел, шактый хезмәт чыгымнары таләп итә. Ләкин азык-төлек продуктлары җитештерү тармагында эшлисең икән, һәр нәрсәне намус белән башкарырга кирәклегенә мин ихлас ышанам.

Генераль директорның планнарында – район үзәгендә сөт җитештерүне дә торгызу. Аның теләге – татарстанлылар табынына Сарман маен кайтару. Рөстәм Нуруллинның ышанычлы сүзләре бу ниятнең тормышка ашачагына өмет бирә: «Икмәк пешерү традицияләрен торгыздык, сөтнекен дә булдырырбыз. Тик хәзер йокы дигән нәрсәне бөтенләй онытырга туры килер, мөгаен…»

Реклама

Фото: Александр Ефремов

Җәлил ит эшкәртү комбинаты

– Һәр түшкәнең экспертизасы үз лабораториябездә уздырыла, димәк, клиентлар итнең барлык ветеринария-санитария нормаларына туры килүенә һәрвакыт тулысынча ышана ала.

КҮП НӘРСӘГӘ **КӨЧЕБЕЗ ҖИТӘ**

Җәлил ит эшкәртү комбинаты – фермер хуҗалыклары өчен дә, эре агрохолдинглар өчен дә алыштыргысыз структура. Монда мал чалу һәм ит эшкәртү белән бәйле җитештерү чыгымнарын мөмкин кадәр киметеп, авыл халкына инде әзер продукцияне кулланучыларга арзанрак бәядән җиткерү буенча ярдәм итәләр.

Рафис Купкәнов, Җәлил ит эшкәртү комбинатының генераль директоры

Рафис Күпкәнов, Җәлил ит эшкәртү комбинатының генераль директоры:

– Безнең предприятие ачылганда, төп максат, әлбәттә, мөгезле эре терлек чалу эшен бу малны үстергән урында – Татарстанның үзендә җайга салып җибәрү иде. Итнең суядан алып эшкәртелүгә кадәр узган юлы республика предприятиеләренең инде танылган бренды астында булсын, продукция тиешле сыйфат югарылыгын сакласын һәм һәркемнең хәленнән килерлек бәядә тәкъдим ителсен дигән теләк беренчел иде. Үз итебез татарстанлыларның табынына «чит» ярымфабрикатлар, казылыклар һәм башка ит продуктлары рәвешендә кыйммәтләнеп кайтмасын, дип тырышабыз. Сарман районында бердәнбер ит эшкәртү комбинаты буларак, без терлекчелек продукциясе җитештерә торган «АГРОСИЛА ГРУПП» ЯАҖнә хезмәт күрсәтәбез. Ул безнең төп тәэмин итүчебез, цехта чалынган малның яртысы аларныкы. Икенче яртысын «Ак Барс Агро» агрофирмасы, Сарман, шулай ук Азнакай, Мөслим, Минзәлә, Зәй районнарының шәхси хуҗалыклары тәэмин итә.

20 кешедән гыйбарәт зур булмаган коллективыбыз клиентларга малны барлык ветеринария-санитария кагыйдәләренә туры килерлек дәрәҗәдә, сыйфатлы итеп суеп бирүне гарантияли. Комбинатның хәзерге җитештерү куәтләре көн саен 25–30 баш мөгезле эре терлек чалуны тәэмин итә ала. Ит-сөякне аралау цехы булу блоклы (сөяксез) ит җитештерергә дә мөмкинлек бирә.

Продукциябезнең шактый өлеше социаль сферага йөз тота. Балалар бакчаларын, мәктәпләрне, сәламәтлек саклау учреждениеләрен тәэмин итеп, алар өчен ризык әзерли торган предприятиеләр белән ит эшкәртү комбинатының партнерлык мөнәсәбәтләре безгә карата ышаныч турында сөйли. Бу – кадерле нәрсә.

Хәләл продукциягә, шул исәптән хәләл иткә дә сорауның артуы үсеш стратегиябезне билгеләде, һәм без шул юнәлешне цехның тәүге эш көненнән үк саклыйбыз. Без ислам кануннарына тулысынча туры килгән продукция эшләп чыгарабыз. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитетыннан сертификат алып, мал чалу эшен бүген ислам кануннары нигезендә башкарабыз. Димәк, безнең цех аша узган барлык ит тә – хәләл. Аңа хәләл икәнлеген раслый торган тамга салырга тулы хакыбыз бар. Корбан бәйрәмендә халыкка сарык чалып бирү хезмәте дә күрсәтәбез.

Һәр түшкәнең экспертизасы үз лабораториябездә уздырыла, димәк, клиентлар итнең барлык ветеринария-санитария нормаларына туры килүенә һәрвакыт тулысынча ышана ала.

Якындагы планнарыбыз – ит ярымфабрикатлары һәм төрле казылык җитештерүне җайга салу. Мал суядан башлап, киң ассортиментта ит продуктлары эшләп чыгаруны колачлаган тулы җитештерү циклын булдыру, һичшиксез, кызыгырлык перспектива. Ләкин бу эш шактый зур финанс кертемнәре һәм дәүләт структуралары тарафыннан ярдәм таләп итә. Барысы да уңышлы килеп чыкса, ит продукциясе җитештерү белән бәйле планнарыбыз чынга ашар, дип уйлыйм. Безнең көчебездән килерлек ул. Чөнки базар үзе шартларын куя: чимал белән сәүдә итү эшеннән әзер ризыклар җитештереп сатуга күчәргә кирәк. Һәм республика җитәкчелегенең моны аңлап эш йөртүе бездә өмет уята.

Реклама

PRESSA.RU



БИСТӘ ХАЛКЫ ӨЧЕН **УҢАЙЛЫ ШАРТЛАР БУЛДЫРЫП...**

Шәһәр тибындагы бистә саналган Җәлилнең торак-коммуналь хуҗалык хезмәте инде ярты гасырдан артык – нефтьчеләр бистәсенә нигез салынган көннән башлап эшләп килә.

«Җәлил торак-коммуналь хуҗалыгы (Төзекләндерү)» ААҖ хезмәткәрләренә эш һәрвакыт җитәрлек. Предприятие күп фатирлы 78 йортка хезмәт күрсәтә. Җылылык һәм су белән тәэмин ителешне тәүлек дәвамында күзәтеп тору, подъездларны чистарту һәм җыештыру, ишегалларын төзекләндерү һәм яшелләндерү, алдан планлаштырылган һәм авария аркасындагы кичекмәс эшләрне башкару, бистәнең торак фондын кышка әзерләү – барысы да коммуналь хезмәт җаваплылыгында. Бу эшләр 77 кешедән гыйбарәт зур коллективка йөкләнгән. Аларның 19ы – төзекләндерү бүлекчәсе эшчеләре, җиде кеше – автомобиль участогында, алтысы каты көнкүреш калдыклары полигонында эшли.

Бүген коммуналь хуҗалык балансында биш махсус техника исәпләнә: ике трактор, грейдер, бульдозер. Алар барысы да төзек хәлдә һәм кышкы сезонга тулысынча әзер.

Бистәдән берничә чакрым ераклыкта урнашкан каты көнкүреш калдыклары полигоны – предприятиенең тагын бер җаваплы тармагы. Монда төрле чүпләрне – полиэтилен, пластмасса, макулатура, чүпрәк-чапрак, тимер-томырны аералар һәм эшкәртәләр. Пластик савытларны тураклау җайланмасында термопластик материалдан эшләнгән чүп-чар яңадан куллану өчен эшкәртелә. Полигонда ПЭТ-шешәләрне һәм макулатураны кысу өчен механик пресс та урнаштырылган. Чүп полигонында алты хеше хезмәт куя. Полигон территориясенда алар тырышлыгы белән 250 куак, 500 чыршы агачы, төрледән-төрле чәчәкләр утыртылган – җәлилләр һәркайда уңайлылык һәм матурлык хакимлек итәргә тиеш, дип саный.

Предприятиенең авария-диспетчерлык хезмәте тәүлек әйләнәсе телефонда дежур тора һәм, җәлилләрдән сигнал килүгә, эшкә керешә. Смс-хәбәрләр системасы да тиешенчә җайга салынган, ул бистә халкының һәртөрле җитешсезлекләр турындагы гаризаларына тиз арада җавап бирү мөмкинлеген тудыра. Бу максаттан торак хуҗалыгы штатында югары квалификацияле 13 слесарь хезмәт куя. Үтәлми калган гаризалар булганы юк. Бөтен йортларның да подваллары коры, су җыелып ятмый, дымлы урыннар да күрмәссең. Махсус антивандал йозаклар чит-ятларның подвалга кереп йөрүеннән саклый.

Торак-коммуналь хуҗалыкның һәр участогы үз эшен җиренә җиткереп башкара. Моны түбәндәге бер факт кына да дәлилли ала: бистәнең барлык 78 йортына да җылылыкны бер көн эчендә биреп бетергәннәр!

«Җәлил торак-коммуналь хуҗалыгы (Төзекләндерү)» ААҖ коллективы үз эшен алга таба да камилләштерергә ниятли. Нефтьчеләр бистәсе халкын торак-коммуналь хезмәтләр белән өзлексез рәвештә һәм ышанычлы итеп тәэмин итү – беренчел бурыч. Һәм ул бурыч уңышлы үтәлеп килә. Үз бистәләрендәге уңайлылык, яктылык, җылылык өчен Җәлил халкының рәхмәт сүзләре – моның иң яхшы дәлиле.

Фотолар: Александр Ефремов; «Җәлил торак-коммуналь хуҗалыгы (Төзекләндерү)» ААҖ

Реклама

Фото: Александр Ефремов

АВЫЛ ҺӘМ УҢАЙЛЫЛЫК – **ЯКЫН ТӨШЕНЧӘЛӘР**

Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча республика программасы кысаларында 2017 елда Сарманда 15ләп өй төзекләндерелгән.

Алмаз Мәүләвиев, «Сарман ИК» ҖЧҖ директоры

Алмаз Мәүләвиев, «Сарман ИК» ҖЧҖ директоры:

– Капиталь ремонтланган унбиш йортның җидесе – Җәлил шәһәр тибындагы бистәсендә, дүртесе – район үзәге Сарманда һәм тагын дүртесе Петровский Завод авылында урнашкан. Мондый киң колачлы эшне үзара финанслау ярдәмендә генә тормышка ашырып булды. Бу очракта торак хуҗаларының ТР Торак-коммуналь хуҗалык фондында тупланып барган акчаларына муниципаль һәм республика бюджетыннан да финанслар өстәлә. Сүз уңаеннан, шул ук программа буенча без киләсе елда тагын 12 йортны төзекләндерергә ниятлибез.

Капиталь ремонт йортларның тышкы ягын декоратив штукатурка белән өстәмә җылыту һәм матурлау, түбә яңарту, су торбаларын, подъездлардагы ишекләрне, тәрәзәләрне, болдыр түбәләрен алыштыру кебек эшләрне үз эченә ала. Торбалар шул килеш калды, чөнки алар әле яңа, алыштырылганнарына биш ел гына. 2012 елда Сарманда һәм Петровский Заводында күпфатирлы йортларның барысы да индивидуаль җылыту системасына күчерелде. Һәр фатирга кайнар су һәм җылылык белән тәэмин итә торган ике контурлы казаннар куелды. Халык өчен бу шактый саллы экономия, чыгымнары икеләтә диярлек азрак. Өстәвенә, бик җайлы да. Җылыту сезоны кергәнен көтеп, фатирда туңып утырасы яки, киресенчә, язгы җылы көннәрдә, үзәкләштерелгән җылылык системасы әле эшләп торганда, эсседән интегәсе юк.

Йорт яны территорияләрен, ишегалларын, балалар өчен мәйданчыкларны төзекләндерү эше дә дәвам итә. Шуңа да басым ясар идем: районыбызда торак хезмәтләре өчен хаклар республикада иң арзаннардан – 18 сум чамасы (капиталь ремонт белән бергә), ә Татарстан калаларында бу сан 30–31 сумны тәшкил итә. Әлбәттә, мондый акчага әллә ни иркен эш йөртеп булмаганлыгы аңлашыла, шуңа күрә без ишегалларын төзекләндерү белән бәйле эшләрнең күп өлешен, үзара салым бәрабәренә, авыл советы һәм күпфатирлы йорт хуҗалары белән бергә башкарабыз. Ишегалларын төзекләндерү-матурлауда нефтьчеләр дә ярдәм итә, алар ел саен районга берничә балалар уен мәйданчыгы алып бирә.

Ләззәт Зарипов (Җәлил шәһәр тибындагы бистәсендә яшәүче):

– Дөресен генә әйткәндә, мин Сармандагы апама кунакка килдем. Соңгы елларда торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәрләренең район үзәгендә башкарган эшләре шаккатыра. Бөтен нәрсә күз алдында үзгәрде. Менә монда, ишегалдында, әле бер ел чамасы элек кенә иске җимерек сарайлар тора иде. Оныгым белән йөреп керергә дә урын юк иде. Хәзер йорт үзе дә, ишегалды да карап кына торырлык: чиста да, матур да, чыгып керү – үзе бер бәйрәм. Балалар өчен менә диган уен мәйданчыгы да куелган. Ә фатир хәзер аерым җылытыла. Моның без, пенсионерлар өчен никадәр җайлы икәнен белсәгез иде! Хәзер торак хезмәткәрләре эшен иренмәгән һәркем тәнкыйтьли. Ә асылда бу кешеләр – тормышыбызны чыннан да уңайлырак итүчеләр, яхшыртучылар бит.

Реклама

PRESSA.RU

Фото: Олеся Бондаревская, «Светводканал» ЖЧҖ

МОНДА **СУ БАР** ҺӘМ БУЛАЧАК!

Фермаларны хәтта берничә сәгатькә дә сусыз калдырырга ярамый, югыйсә бик зур чыгымнар көтелә. Шул ук вакытта авыллардагы су белән тәэмин итә торган коммуникацияләрнең яше дә шактый. Димәк, су өчен җаваплы кешеләргә тәүлек буе диярлек вахтада торырга туры килә. Сарманның «Светводканал» ЖЧҖ директоры Дамир Галиев шундый графикта инде берничә дистә ел эшли.

Дамир Зөфәровичның бүлмәсендә дивարлардан стенасына тиң: күпсанлы грамоталар, рәхмәт хатларын инде элләр урын калмаган.

– Күп эшләргә генә түгел, ә һәрвакыт эшләргә туры килә, – ди «Светводканал» директоры, безнең ничек шулкадәр барысына да өлгереп була дигән сорабызга җавап итеп. – Менә сезнең янга да мин объекттан килдем – кое казый идек, аны караңгы төшкәнче тәгәлләргә кирәк. Предприятиенең бөтен штаты – 14 кеше, күчмә бригадада тагын 8 хезмәткәр бар. Ә без хезмәт күрсәтә торган челтәрләрнең озынлыгы 320 км, моннан Казанга кадәр ара белән чагыштырганда, бераз гына кыскарак. Шуңа берничә су манарасы һәм насослар да өстәлә. Чакыру килгәч, үземә дә чыгып китәргә туры килә. Барысын да булдырам: экскаватор белән дә эшли алам, эретеп ябыштыручы да, электрик та мин. Бездә бөтен хезмәткәрләр дә универсаллар, башкача бу эштә мөмкин түгел.

Су белән тәэмин итү инфраструктурасының күп өлеше ярты гасыр элек салынган. Аварияле участокларны төзекләндерү һәм алыштыру эше һәрдаим бара. Шул ук вакытта предприятие эшчеләре, мөрәҗәгать килүгә, кичекмәстән шунда юл тотарга тиешләр. Эретеп ябыштыручы Гөлүс Насыйбуллин, экскаваторчы Рамил Шәйхетдинов, машина йөртүчеләр Валерий Ильин, Мулланур Фатыйхов, Руслан Сәетшин, электриклар Рәшит Сираев һәм Рәис Җәләлетдинов, слесарь Данияр Гыйльфанов – алар барысы да районга, аның халкына тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ярдәмгә ашыгырга әзер.

– Мин хезмәткәрләремнең көн саен намус белән башкарылган эшләре өчен рәхмәтле, – ди Дамир Галиев, – Бездә катгый нормативлар куелган: авария урынына бер сәгать эчендә килеп җитәргә, ә ремонтны 2–3 сәгать эчендә тәгәлләргә тиешбез. Былтыр кышын бер агрофирмадан (без аларның барсына да – «Нөркәй»гә дә, «Сарман»га да, «Җәлил»гә дә хезмәт күрсәтәбез) шалтыраттылар: су юк, диләр. Бер сәгать эчендә шунда идек. Насос ватылганын ачыкладык. Ике сәгать эчендә ремонтны тәмамладык та – әле шул вакытта насосны тартып чыгарырга һәм кире 60 метр тирәнлектәге скважинага төшерергә дә кирәк иде. Заманча җиһазлар эшебездә бик нык булыша.

Өр-яңа техника оешма эшен камилләштерергә ярдәм итә. Әйтик, траншеяларны тизрәк тә, экологик яктан яхшырак, чыгымнар ягыннан арзанрак та итеп казу өчен горизонталь юнәлештә бораулау җайланмасы сатып алганнар.

– Районда авылларны су белән тәэмин итү программасы буенча һәр ел су манарасы куелып килә. Без бу эшләрдә дә катнашабыз, иске һәм яңа скважиналарга хезмәт күрсәтәбез, моңа скважиналарның саклагыч торбаларын юдыру да, насосларны төзәтү һәм профилактик карап тоту да керә. Скважиналарның барысына да автоматика көйләнгән, башня тулгач, ул суны аерып куя. Бу исә суны да, электр энергиясен дә янга калдырырга мөмкинлек бирә. Насосларның тузуын да киметә, – дип сөйли Дамир Галиев. – Моннан тыш, һәр су манарасына фильтр куелган. Районда су яхшы, краннан алып эчәргә була. Хакимият аның сыйфатын СЭСта тикшертеп тору өчен ел саен акча бүлеп бирә. Ләкин суның катылык дәрәҗәсе югарырак, шунлыктан без фильтрларны даими рәвештә чистарту эшен дә алып барабыз.

Эше никадәр генә тыгыз булмасын,Дамир Галиев социаль миссияләрне үтәр өчен дә вакыт таба. Шуларның берсе – хәйриячелек. Ялгыз яшәүче карт-корыларның өйләрендә һәм җир кишәрлекләрендә су торбаларын төзәтү эшен ул инде күп еллар бушлай башкара. Икенче миссиясе – Сарман әзерлек конторасы эшчәнлеген саклап тоту. Дамир әфәнде инде ун ел чамасы аның директоры булып тора. Бу эшен дә үзенә хас җаваплылык һәм эзлеклелек белән алып бара. Дару үләннәре җыюны оештырып җибәрүе генә дә ни тора! Героебызның намуслы, фидакарь хезмәте югары бәяләнә. Октябрь аенда Дамир Галиев «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исеменә лаек булды, аңа күкрәк тамгасын һәм таныклыкны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тапшырды.

Реклама

ХЫЯЛГА **ГРАНТ**

Җәүдәт Фәттахов ике ел инде бер ялсыз эшли, ягъни пенсиягә чыкканнан бирле. Аңа хатыны белән өч улы булыша, берсе хәтта төп эшеннән ял да алган. Әмма нәтиҗәсе шуңа торырлык, ди фермер: быел сарык көтүенең санын максат итеп куелган 500 башка җиткерә алганнар.

«Татарстан Республикасында 2015 – 2017 елларда крестьян-фермер хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» программасы шартлары буенча КФХ 2017 ел ахырына әнә шундый күрсәткечкә ирешергә тиеш булган. Хәзер Җәүдәт Фәттахов шушы программа буенча 2016 елда алынган грант акчасына ферма төзелешен тәмамлап килә. Сарыкларның баш саны буенча аның хуҗалыгы – районда иң эреләрдән.

– Элек бу урында ашлык саклау склады иде. Аннан калган корылманы без сарык абзары итеп кулландык. Баш санын арттырырга уйлагач, яхшы җилләтү системасы булган зуррак мәйданлы корылма кирәк булып чыкты, – дип сөйли фермер, безгә хуҗалык җирләрен күрсәтеп. – Шулай итеп, без хәзер яңа корылманы төзеп бетереп киләбез, көтүлектә йөргән төп мал-туарны кышка шушында күчерәчәкбез.

Без сарыклар бәрәннәре белән бергә тотылган корылма эченә үтәбез. Биредә җылы, идәнгә калын итеп салам җәелгән. Безне күргәч, терлекләр тынып кала. Иң кечкенә бер бәти генә арада иң кызыксынучаны булып чыкты – яныбызга ук килеп баса. Йоны кап-кара диярлек.

– Бу – Романов нәселе. Без башта төп нәсел шул булыр дип уйлаган идек. Аннан ит тә, йон да алалар. Ләкин йон хәзер берәүгә дә кирәкми, ә сарык тиресенең бәясе – 5 сум. Ә инде җитәрлек күләмдә ит алу өчен азык рационын да, абзардагы климатны да, шулай ук сарыкларның стресс кичермәвен дә, бәтиләрен имезүдән бизмәвен дә игътибар белән күзәтергә кирәк, – дип сөйли Җәүдәт Фәттахов. – Шуңа күрә без хәзер Романов нәселеннән курдюклы сарыкларга күчәбез. Аларның ите бик тәмле, бәтиләре тиз дә, яхшы да үсә. Моннан тыш, курдюк маена ихтыяҗ зур.

«Бәрәннәр абзары»ның икенче очында – ике дистәләп төргәге печән өелгән.

– Бу кышка запасмы?

– Сез нәрсә, бу чама белән ун көнгә генә җитә. Курдюклы сарыклар азыкка талымсыз булса да, ашату даими һәм балансл булырга тиеш. Шуңа да без печәнне күп әзерлибез, арпа үстерәбез. Хәзерге вакытта минем 72 гектар җирем бар, уңыш та җитәрлек, ул җирне һичьюгы 80 гектарга җиткерәсе иде, – дип аңлатма бирә фермер.

Хуҗалыкта урып-җыю өчен кирәкле бөтен техника бар, хәтта печәнне рулоннарга төрүче пресс-җыештыручы да.

– Элек бик яхшы иде: «Татнефть» ярдәмендә эшләүче «АгроИдея» Лениногорск компаниясе кече фермерларга техника сатып алу акчасын тулысынча кире кайтара иде. Хәзер алар моның өчтән беренә генә субсидия ясый. Тагын өчтән бере республика бюджетыннан бүлеп бирелә, ә өчтән берен фермер үзе түли. Әмма монысы да сизелерлек ярдәм. Безнең хуҗалык чагыштырмача зур булмаса да, проблемалар җитәрлек. Мәсәлән, сарык абзарының конструкциясе шундый – аның эченнән уза торган юл җыештыручы трактор өчен бик тар, шуңа да тирес чыгару өчен күп көч һәм вакыт китә, – дип сөйли фермер.

Әмма кыенлыкларга һәм хезмәтнең күплегенә карамастан, Җәүдәт Фәттаховның күңеле күтәренке.

– Мин һәрвакыт, башка берәүнең кул астында булмыйча, үз эшемне оештырырга тели идем. Авыл хуҗалыгында тәҗрибәм зур. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамладым, районда эшләдем, совхозга җитәкчелек иттем. Йортта һәрвакыт 50 баш терлек асрадык. Монда, билгеле, башка күләм, ләкин без булдырырбыз дип уйлыйм, – ди Җәүдәт Нуртдинович. – Терлекне һәм итне сатуда әлегә проблемалар күренми. Корбан бәйрәме алдыннан ихтыяҗ аеруча зур. Күрше районнардан, Зәйдән, Яр Чаллыдан сатып алучылар килә. Шулай да проектның уңышы минем җаваплылыкта. Петровский Завод җирле үзидарәсе советы рәисе булып эшләгән чагымдагы кебек…

Реклама
Фото: Олеся Бондаревская

PRESSA.RU

Фото: Александр Ефремов

«МӘРМӘР» ИТ ҖИТЕШТЕРҮ

Авыл хуҗалыгы эшчәнлеге зур тәвәккәллек белән бәйле, шулай ук җитди белем һәм күнекмәләр дә таләп итә, дип исәпли крестьян-фермер хуҗалыгын оештырган аталы-уллы Флёр белән Роберт Маликовлар. Ә бу эштә иң мөһиме – алынган акчаларны акыл белән, нәтиҗәле итеп файдалану.

Аларның крестьян-фермер хуҗалыгы 2009 елда оештырылган. 184 гектар сөрүлек җирләре булган хуҗалар мөгезле эре терлек симертергә уйлый, өстәвенә, ул чакта ашлыкка бәя дә тотрыклы булмый. Маликовлар, грант алып, Сарман районының Буралы Чишмә авылында яңа ферма төзиләр, бозаулар сатып алалар. Бүген хуҗалыкта 60 баш герефорд токымлы үгезләр симертелә. Ак башлы бу токым үгезләре бик юка май катламнары белән аралашкан гаҗәп тәмле «мәрмәр» ит бирә. Маликовларның кара-чуар төстәге терлекләре дә бар, ә менә бер ай элек кенә, симментал токымлы 23 тана сатып алып, көтүләренең баш санын арттырганнар.

– Гомумән, бүген бөтен дөнья элита сортлы сыер итенә өстенлек бирә, – дип аңлата Маликовларның кечесе. – Аларның ите бик тәмле була. Әмма токымлы бозаулар сатып алу – бу эшнең хәтта яртысы да түгел әле. Герефордларны без намус белән, күңел биреп – югары класслы ризык белән генә тукландырабыз. Ашлыкны сатмыйбыз диярлек – барысын да бозауларны ашатырга калдырабыз. Шунысы эшне җиңеләйтә: герефордлар безнең Татарстан кышлары өчен әйбәт яраклашкан. Аларның калын тиреләре шактый тыгыз йон белән капланган, бу токымга көчле суыкларда да саф һавада йөрү мөмкинлеге бирә. Иң мөһиме – аларны яхшы ашатырга һәм бары тик чиста су гына эчерергә. Без шулай эшлибез дә.

Бүгенгә көндә кырларыбызны киңәйтү эшен алып барабыз – хәзер җиребез 200 гектарга җитә диярлек. Арпа, бодай, арыш, үлән чәчәбез, сенаж чокырын тутырып торабыз. Терлекләр тулысынча сыйфатлы һәм балансллы ризык белән тәэмин ителгән. Бу эш өчен күп вакыт һәм акча соралса да, элиталы яшь терлекләр сатып алу белән шулай ук даими шөгыльләнәбез.

Бүген менә шундый вакыт килде: алга таба ничек эшләү турында җитди уйлана башладык. Эш шунда: без итне күбесенчә Әлмәт базарына чыгарабыз. Башта 5–10 баш үгезне, тананы бер машинада Әлмәткә, мал чалу цехына илтәбез. Аннары инде эшкәртелгән итне икенче машинада – базарга. Аңлашыла ки, монда югалтуларсыз булмый. Нәтиҗәдә, итнең бәясе төшә. Әлбәттә, без үзебез дә авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашабыз, әмма бу да проблемаларны хәл итми. Шуңа, әйтик, симменталларны тере авырлыгын 160 сумга куеп сатканда, менә бу фикергә килдек: ә ни өчен әле үзебезгә ит ярымфабрикатлары җитештерү белән шөгыльләнә башламаска? Фарш, купатлар, котлетлар һәрвакыт ихтыяҗга ия бит. Кулланучылык базарларын, сату нокталарын өйрәнергә, кирәкле җиһазлар сатып алырга ниятләп торабыз. Ит тотрыклы сатыла, киң клиентлар базабыз һәм, иң мөһиме, яхшы абруебыз бар. Продукция сатуда да проблемалар булмаска тиеш, дип өметләнәбез.

Әле күптән түгел генә илдә ит продуктларына сизелерлек кытлык күзәтелә иде. Хәзер хәл яхшырды, дияргә мөмкин. Әмма россиялеләрнең ихтыяҗын авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре нигездә кош һәм дуңгыз ите белән канәгатьләндерә. Ә без үз алдыбызга халыкны мөмкин булганча демократик бәяләргә сыйфатлы «мәрмәр» сыер ите һәм аннан эшләнгән продукция белән тәэмин итү бурычын куябыз.

Реклама



ТАБИБ ЮЛЛАРЫ

Күптән түгел экраннарга чыккан «Аритмия» Россия фильмының герое ашыгыч ярдәмдә хезмәт итә һәм ярдәмгә мохтаҗ булган кешеләрне коткару өчен барысын да эшли. Сарман районы ҮРХндә дә шундый ук принцип белән эшлиләр. Һәм, әйтергә кирәк, эшләрен бик яхшы билгесенә башкаралар.

Илдус Шакиров, Сарман районы ҮРХнең баш табибы

Эш шулай бара: «инсульт» яисә «инфаркт» диагнозы куелган авыруны регламентта билгеләнгән 3–4 сәгать эчендә районнан Әлмәт шәһәренә – кан тамырлары үзәгенә илтеп җиткерәләр. Анда пациентка тулысынча тиешле ярдәм күрсәтелә. Бурычны үтәргә Ford реанимобиле булыша, бу автомобильне ҮРХгә ТР сәламәтлек саклау министры Адель Вафин госпитальгә салганчы килеп чыга торган үлем очракларын киметү Татарстанда беренче урын алган өчен бүләк иткән.

– Мин биргә өч ел элек килдем. Ул чакта район сәламәтлек саклау буенча республика рейтингында 45 район арасында 43нче урында тора иде. Район башлыгы Фәрит Хөснуллинның актив ярдәме белән без 2015 елда – 24 нче, 2016 елда 18 нче урынга күтәрелүгә ирештек. 2017 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча иң яхшылар унлыгына керәбез. Әмма безнең омтылырдай максатлар бар әле, – ди хастаханәнең баш табибы Илдус Шакиров.

Бүгенге көндә ҮРХ бердәм көйләнгән механизмны тәшкил итә. Соңгы өч елда биредә Дәүләтнең бушлай медицина ярдәмен гарантияләү программасы күрсәткечләре 100%ка үтәлә. Йөрәк-кан тамырларына онкоскрининг, стент, аортокоронар шунт кую, ангиография буенча квоталар үтәлә һәм хәтта арттырып үтәлә. Диспансерлаштыру күләме буенча район республикада беренче, халыкны ташламалы дарулар белән тәэмин итүдә өченче урында тора. Райондагы 55 торак пунктның 51ендә үз фельдшер-акушерлык пункты бар.

– Телемедицина безгә республиканың башка медицина учреждениеләрендәге тар профильле белгечләр белән консультацияләр үткәрергә булыша. Без пациент турындагы белешмәләрне һәм анализ нәтиҗәләрен алдан җибәреп куябыз. Аннары табиблар авыру белән онлайн-консультация үткәрәләр, киңәшләрен бирәләр. Югары технологияле медицина ярдәме буенча без Әлмәттәге «Татнефть» медсанчастена беркетелгән. Ихтыяҗ булганда, каты авыруны вертолёт белән республиканың тиешле белгеч булган шәһәренә озата алабыз, – дип сөйли Илдус Шакиров.

Ике ел элек ул, тәвәккәлләп, Уфа күз авырулары ФТИ белән килешү төзегән. ҮРХндә катаракта бар дигән шик туган барлык пенсионерларны тикшереп, операциягә ихтыяҗ булганнарны ачыклаганнар һәм бер автобус белән Уфага җибәргәннәр.

– Мин ул чакта бик борчылдым: әгәр начар ясасалар? Әйбәт ясадылар. Икенче елда бу процедураны тагын кабатладык. Шул вакыт эчендә 395 операция ясалды. Операцияләрнең гомуми бәясе – чынлыкта бу район бюджетына кергән федераль инвестицияләр – 18,8 млн сумны тәшкил итте. Халыкка бөтен ярдәм бушлай күрсәтелде. Теләүчеләр булганда, эшне дәвам итәргә уйлыйбыз. Мөслим районы да үзендә бу тәҗрибәне кертә. Ә бездә хәзер шундый мәзәк йөри. Миңа район башлыгының кабул итү бүлмәсеннән шалтыраталар да: монда сезнең өстән шикаять язганнар, диләр. Ә мин: әлбәттә, хәзер бездә бөтен әбиләр дә яхшы күрә, дим… – дип сөйли Илдус Мөдәррисович.

Әле күптән түгел генә ул, Сарман районы прокуроры һәм дарухәнә мөдирләре белән бергә халык белән очрашу үткәргән, кемнең ташламалы дарулар алырга хакы барлыгын һәм ни өчен, акчасын алуга караганда, даруларны алу яхшырак булуын аңлаткан.

– 36 мең кешедән торган район халкының 13 меңе – пенсионер. Шуңа да пациентларны еш кына ахыргача тикшерелергә мәҗбүр итәргә туры килә. Безнең стационар маммографыбыз һәм күчмә флюорографыбыз юк, киң күләмле тикшерүләр һәм диспансерлаштыру вакытында халыкка график буенча Яр Чаллы медицина учреждениеләренең күчмә аппаратлары хезмәт күрсәтә. Маммографлар Җәлилдәге филиалда һәм биредә, Сарманда да бар. Нинди дә булса шик туса, пациентны контрольгә алып, диагноз куяр өчен, бөтен анализларын бирүне таләп итәбез, – ди баш табиб. – Узган ел, мәсәлән, авыруның 1–2 стадиясендәге 110 онкология очрагын, быел 118 очрагын ачыкладык, бу вакытта дәвалауның тактикасын сайларга мөмкин әле һәм прогнозлар уңай була. Гомумән алганда, узган ел белән чагыштырганда, без быел 87 кешегә азрак югалттык. Балалар туу саны да арта. Бу бик сөендерә!

Район өчен иң зур проблема – табиблар җитмәү. Ике ел эчендә «Земский доктор» программасы буенча 13 белгеч кабул ителде, аларның сигезе фатирлар белән тәэмин ителде. Район башлыгы карары белән 18 фатирлы яңа йорттан медикларга биш фатир бүлеп бирделәр. Әмма шул ук вакытта табиблар штаты нибары 61%ка гына тәэмин ителгән. Педиатрлар мәсьәләсе аеруча кискен тора. Аларның иң яшь дигәннәренә дә – бүген 55…

– Безгә яшь белгечләр бик кирәк. Без авыл үсәр, дип өметләнәбез, алга карап эшлибез. Хәзер Сарман район үзәгенең көньяк-көнбатышындагы яңа микрорайонда халыкка хезмәт күрсәтү өчен табиблык амбулаториясе төзелеше төгәлләнеп килә. Сәламәтлек саклау министры Адель Вафинга махсус хат белән мөрәҗәгать итеп, проектка Фәрит Мөнәвирович зур ярдәм күрсәтте, – ди Илдус Шакиров. – Хәзер амбулаториягә коммуникацияләр сузалар. Моннан тыш, без быел хастаханәләргә ремонт ясау буенча республика президент программасына кердек. Шул уңайдан Сарман хастаханәсенең өч бүлегенә, Җәлилдәге филиалның өч бүлегенә ремонт ясалачак.

Фото: Олеся Бондаревская

Реклама

ПРЕССА.RU

КУҖАКТА КУНАКТА, ЯКИ **ТАТАРСТАНЧА ХЮГГЕ***

Авыл халкының үзенең сүзенә караганда, Кужакта башлыча карт-коры яши. Әмма куҗаклылар үзләрен карт дип санамый. Әбекәйләр, кызларча чытлыкланып, үзләрен чынлап та яшь сылулардай тоталар, тормышлары да яшьләрчә – бәхетләре ташып тора. Чөнки алар, үзләре дә абайламый, тормышларына... хюгге керткәннәр.

***Хюгге.** Даниялеләр теленнән килеп кергән бу сүз рус теленә турыдан-туры тәрҗемә ителми. Шулай ук – татар теленә һәм башка телләргә дә. Даниядә бу төшенчә тулы бер фәлсәфәне үз эченә ала: уңайлы тормыш, комфорт, кунакчыллыкны. Килешәсездер, камин каршына, йә булмаса мич алдына барып утырып, кулыңа китапмы, бәйләмме (кемгә нәрсә күбрәк ошый) алып, шул мизгелдә җир йөзендәге иң бәхетле кеше булырга мөмкин.

Автор:
Алсу Троицкая

ӨЙ ЯМЕ – ТОРМЫШ ЯМЕ

– Менә, менә, төшерегез үзен тизрәк, – дип елмая Вәзилә апа, Рекс кушаматлы тешләрен ыржайткан яман кыяфәтле эткә ишарәләп. – Рексның кыяфәте, хуҗабикәсен күрүгә, мизгел эчендә үзгәрә, һәм менә ул инде, койрыгын болгый-болгый, сөенечен белдерә, елмая да кебек хәтта.

– Авылыбыз тарихын чын-чынлап берәү дә белми шул, мин инде күпме әби-бабайдан сораштым, китаплар да актарып карадым, берни тапмадым, – ди Вәзилә апа, безне өйгә чакырып. – Бәлки, «хуҗа» дигән сүздән килеп чыккандыр ул. Чынлап та, авылның хуҗасы, бик мәртәбәле кешесе булган дип сөйләгәннәрен ишеткәнем бар. Менә шуннан исеме дә килеп чыккан, күрәсең. Ә чигү мәсьәләсенә килгәндә, анысы бездә гомер-гомердән булды һәм хәзер дә бар. Һәр йортта чигәләр. Мин үзем җиденче класстан бирле чигәм, менә җитмеш ел була инде. Өйдә сез күргән эшләр – болар инде дүртенче партия. Хачлап та чигәм, тигез итеп тә. Чигүләр, туза төшкәч, кайсы мунчага күчә, кайсыларын туган-тумачага өләшәм. Җете төсләр белән чигәргә яратам. Чигүдән бит өй ямьләнеп китә, җылынып. Шуңа чигүгә киткән вакытны җәлләмим.

Дания дизайны, татар дизайныннан аермалы буларак, минимализмга якынрак, төсләрнең дә тоныгракларына өстенлек бирә. Вәзилә апа белән аның ахирәтләре табигый материаллардан тудырган матурлык күзне җәлеп итеп, сөендереп кенә калмый, ә өйне чынлап та кайтасы килә торган бер уңайлылык белән коендыра. Бу хюгге булмый нәрсә булсын инде, йә.

Фото: Александр Ефремов

1. Чигүдән өй ямьләнеп китә, җылынып.

2. – Мин үзем җиденче класстан бирле чигәм, менә җитмеш ел була инде, – ди Вәзилә апа.

3. Рәзинә апа безне яңа гына мичтән чыккан телне йотардай коймаклар белән каршылый, өстәлгә бал белән чәй дә менеп кунаклый. – Тормышта иң мөһим өч нәрсә бар: сәламәтлек, гаилә һәм күршеләр. Минем һәр өчесеннән бәхетем булды.

«Кемдер иңегезгә кулын сала, сезне үбә, йә булмаса битегездән сыпыра – әнә шул чакта күңелгә тып-тыныч һәм рәхәт шатлык тулуын сизми дә каласың. Кемнеңдер кагылуы организмда окситоцин бүленеп чыгуга ярдәм итә, ә окситоцин ул бәхет тойгысы өчен җаваплы, стрессны таратучы, курку белән борчу хисен җиңүче».

Майк Викинг, «Hugge. Дания бәхетенең серләре» китабы авторы.

БАЛ ЯНЫНА – ШИГЫРЬ

Кужак чигүчеләре дә безне бәхет гормоны окситоцин белән юмарт рәвештә баетты: сәламләп тә, беренче кат күргән кешеләре булуга карамастан, кочаклап та. Һәм менә ноябрьнең елап торган боек һавасы күзгә күренеп яктырды, җылынды. Өйдә дә җылылык – бүрәнә арасындагы мүкләр ап-акка буялган, идәнне келәмнәр бизи, диварларда фотографияләр тезелеп тора, ә ишек өстендә – дисбе. Рәзинә апа Садыйкова безне яңа гына мичтән чыккан телне йотардай коймаклар белән каршылый, өстәлгә бал белән чәй дә менеп кунаклый, әлбәттә. Рәзинә апа, шуларга өстәп, шигырь белән дә җылыта:

Безнең тормыш арасына
Кемнәр килеп кергәннәр?
Аркылы да, торкылы да
Күпер салыйк дигәннәр.
Яшьлек тәртип белән үткән –
Кычкырып көлмәгәнбез,
Үбешү, кочакланышу –
Без аны белмәгәнбез.
Сандугач булалмадым,
Түшеңә куналмадым.
Үкенәм үткәннәргә:
«Сау бул» дип хушлашмадым.

СӘЛАМӘТЛЕК, ГАИЛӘ ҺӘМ КҮРШЕЛӘР

– Хатын-кызлар тормышка яхшырак яраклашкан, шуңа гомерләре дә озынрак, – ди Рәзинә апа. – Юкса җиңел дә яшәмәдек инде. Сугыштан соңгы елларда ач-ялангач булдык, кияүгә чыгып, балалар алып кайттык. Ә 36 яшемдә мин инде тол калдым. Балалар үсеп таралышты, хәер, кайтып йөриләр, шөкер. Тормышта иң мөһим өч нәрсә бар: сәламәтлек, гаилә һәм күршеләр. Минем һәр өчесеннән бәхетем булды. Ахирәтләрем белән кунакка йөрешәбез. Сөйләшеп утыруы рәхәт, чәй эчә-эчә. Мин шигырьләр дә языштырам. Ә чигүне инде бик кулга алганым юк соңгы арада – күзләр элеккеге түгел. Сагындыра, кул чигү чиккән арада, баш әллә нәрсәләр уйлый бит...

Инде хәзер чикмим, дисә дә, Рәзинә апаның йорты тоташ чигүдән генә тора – җете төсләре белән балкып утыручы мендәр тышлары, дисеңме, эскәтер, җәймәләр...

ХӘРӘКӘТ, УҢАЙЛЫ КИЕМ ҺӘМ ГАДИ ШАТЛЫКЛАР

Хюггеның бу шартларын да җиренә җиткереп үти Кужак әбекәйләре. Авылда тормыш саф һавада уза, ә мал-туар асрагач, хуҗалык булгач, хәрәкәтсез булмый, билгеле. Гардеробка килгәндә, мода артыннан куып, кроссовки, свитшотлар белән дыңгычлап тулмаган ул, әмма төп трендларны үз эченә алган: уңайлылык, җылы һәм комфортны. Гади шатлыкларга килгәндә, Вәзилә апа белән Рәзинә апа аларны бармакларын бөкләп санап чыга ала: пенсия, этләр, тавыклар, яраткан шөгыльләре, тәрәзә артында үсеп утыручы агачлар, елларда һәм бәйрәмнәрдә кайтып йөри торган балалар белән оныклар – барысы да бар. Мич тә бар! Чит илләрдән кергән каминны үзебезнең мич алыштыра аламы соң!

Шулай итеп, хюгге дигән гади дә, файдалы да фәлсәфәне үз тормышына кертергә теләүчеләр өчен юллар ачык. Барып чыкмый икән инде, Кужак әбекәйләренә кайтып, дәрес алып килергә киңәш итәм. Апаларына, дәресрәге. Хәер, юк, сылуларына... Т

2

3

НИЧЕК БАРЫРГА:

Сарманнан көньякка – Җәлил бистәсенә таба юл алабыз да, 19 километр барганнан соң, Кужакка килеп җитәбез.

КАЙЧАН БАРЫРГА:

Хюгге өчен иң уңайлы сезон дип кыш санала. Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре вакыты. Кешеләр җылырак киенә, ә йортларга уңайлылык иңә, бәйрәм төсе керә. Гирляндалар, чыршы уенчыклары, тәм-томнар турында әйтеп торасы да юк.

Без Татарстан риваятьләрен туплауны дәвам итәбез, безнең якларда «яшәүче» андый риваятьләр шактый. Аларга Сарман районы да бай. Шуңа да бу яңа тарих – әлеге серле урыннардан.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: БАКЫР ТАУ СЕРЕ

Сарман районында борма-борма бакыр чыгару базларын һәм борынгы риваятьләрне саклаган Әхмәт тавы бар. Риваятьләрнең бер-икесе дөнья тарихына бөек яулап алулары белән кереп калган һәм «дөнья хакиме» дип йөртелгән Аксак Тимер исеме белән бәйле.

...Аксак Тимер, уйчан карашын кар каплаган тау битенә юнәлтеп, бармаклары белән кулындагы нефрит дисбесенең төймәләрен аралый. Ул бу якларның Баграж елгасы буендагы табигате нинди көтелмәгән кыенлыклар китереп чыгарырга сәләтле булуы турында уйлана. Хәтта Чулман аръягына да чыгып булмады. Җирле сугышчыларның батырлыгы да, көчле ныгытмалар һәм көтелмәгән засадалар да сәбәп түгел моңа, ә бәлки зәмһәрир суыклар һәм сөякләргә кадәр үтүче өшеткеч бизгәк. Яугирнең үз алдына куйган бөек максаты хакына корбан иткән кешеләрне санау гадәте булмаса да, монда ул уйга калды. Һәм аның өчен Пеләш тау өстендә төзелгән затлы сарай аерым бер чик сызыгына әверелеп, Аксак Тимерне моңа кадәр ирешкәннәреннән кирегә, кабат Азия далаларына юнәлергә мәҗбүр итте.

Икенче риваятьтә «дөнья хакимен» бу урыннан озаклап җибәрми торган тагын бер сер турында сөйләнелә. Таулар үз эченә борынгы серләрне яшергән. Иске бакыр базларына Аксак Тимер ышанычлы йөз сугышчысын җибәргән һәм алардан озаклап хәбәр көткән. Яуга чыгар алдыннан бер ышанычлы кешесе аңа Минзәлә елгасы буйлап сузылган бакыр базлары планы төшерелгән борынгы манускриптны китергән булган. Анда кайдадыр күпсанлы тармаклар эчендә гаҗәеп хәзинәләр ышанычлы итеп яшерелгән, алар арасында – иясенә мәңгелек яшьлек һәм көч бирүче күптән югалган тылсымлы төнәтмә рецепты да булган, имеш. Җирле үләннәрдән әзерләнгән бу могҗизалы төнәтмәне эчкән кешегә ул озын гомер генә түгел, бөтен дөньяга хакимлек итү мөмкинлеген дә вәгъдә иткән, ди.

Әмма серле манускрипттан тыш, юлчыларны Әхмәт тавы базларына дәшүче тагын нәрсәдер булган. Анда суы могҗизалы рәвештә үлем яраларын төзәтә, бөтен организмны яшәртә торган җир асты күле бар, дип сөйләгәннәр. Аксак Тимернең соңгы сугышларда каты яраланган берничә яудашы бакыр базларына төшкән. Һәм менә бусагада сөенечле хәбәр китергән җайдак пәйда булган: алар көч-куәтләре ташыган хәлдә кайтып кергәннәр, имеш...

Редакция сезнең туган якларыгыз, авылларыгыз риваятьләрен дә «бүләккә» рәхәтләнеп кабул итә. Җибәрегез аларны безгә – һәм бөтен ил сезнең туган ягыгыз турында белер.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 27нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Ирек Фәйзуллин, ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, декабрь аенда үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Фото с сайта Министерства строительства РТ

Тәлгать Абдуллин, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасының башкарма директоры

Татарстанлылар иминлеге хакына

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович!

Бай җитәкчелек тәҗрибәгез, профессиональлегегез, эшкә принципиаль якын килә белүегез һәм бүгенге көн чынбарлыкларына сизгерлегегез Сезгә, хөрмәтле Ирек Әнвәрович, иң катлаулы мәсьәләләрне хәл итәргә һәм куелган максатларга ирешергә мөмкинлек бирә. Юбилей көнегез белән котлап, бөтен көчегезне куеп башкара торган эшегез өчен рәхмәт әйтергә рөхсәт итегез. Хезмәтегез белән Сез хезмәттәшләрегез һәм эшлекле партнерларыгыз арасында абруй һәм хөрмәт казандыгыз.

Татарстанда лаеклы рәвештә танылу алган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды тормышка ашыра торган торак программалары буенча без бергәләп эшлибез. Бүген фонд Сезнең ярдәм белән республика халкы өчен арзанлы торак йортлар төзүне уңышлы алып бара. Тормыш бер урында тормый, шулай ук торакка таләпләр дә туктаусыз үзгәреп тора. Шуңа күрә без башкара торган эшләр озак еллар буена дәвам итәр әле. Уртак хезмәтебезнең җимешләре – республикада торак проблемасын хәл итү генә түгел, законнар чыгару базасын камилләштерү, архитектура төзелешендә югары технологияле эшләнмәләр куллану да ул.

Фондның һәр адымы эре компанияләрдән генә түгел, республика җитәкчелегеннән, шул исәптән Сездән дә ярдәм ала. Татарстанның торак сәясәтендә социаль юнәлештәге төбәк булып танылуында Сезнең дә өлешегез зур. Җаваплы һәм әһәмиятле эшегезнең нәтиҗәләре республика халкының уңайлы тормышын тагын да ныгыту һәм үстерү өчен зур роль уйный.

Сезгә ныклы сәламәтлек һәм гаилә иминлеге телим! Алга таба да эшләрегездә уңыш юлдаш булсын, ә һөнәрилегегез һәм тормыш тәҗрибәгез билгеләнгән планнарыгызны тормышка ашыруда ярдәм итсен!

Газинур Әхмәтов,
«АкТаш» ҖЧҖ
директоры

Төзү – иҗат итү ул!

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович!

«АкТаш» төзелеш компаниясе һәм шәхсән үз исемемнән Сезнең 55 яшьлек юбилеегыз белән иң ихлас котлауларымны кабул итегез.

Сез төзүче һөнәренең хаклы рәвештә иң күркәм, мактаулы һәм кирәкле профессия икәнен һәрвакыт ассызыклыйсыз. Ә төзелеш тармагы Татарстанның социаль-икътисадый үсешендә төп юнәлешләрнең берсе санала.

Яңа торак йортлар, социаль әһәмияткә ия объектлар, сәнәгать мәйданчыклары республикадагы төзелешнең, икътисад драйверларының берсе буларак, актив үсешен раслый. Әмма республиканың төзелеш һәм архитектура тармагы үсеше бай тәҗрибәсен, белемен һәм көчен үз эшенә багышлаучы нык профессионаллардан башка мөмкин булмас иде. Сезгә, Ирек Әнвәрович, һәрвакыт уйланган идеяләрне тормышка ашыру һәм заман белән бергә атлау хас.

«АкТаш», Татарстан Республикасы Хөкүмәте партнеры һәм, тулы цикл компаниясе буларак, төзелеш вакытында сыйфат һәм куркынычсызлык мәсьәләләренә игътибар аеруча нык таләп ителә торган дәүләт программаларын тормышка ашыруда даими нигездә катнаша. Бүген төзелеш эшләренең проектлау-монтажлау, җир эшләреннән башлап, бизәкләү һәм түбә ябу эшләренә кадәр барлык спектрын башкару көчебездән килә. «АкТаш» ҖЧҖ барлык эшләрне бик яхшы сыйфатлы итеп, төгәл вакытында башкаруны тәэмин итә. Зур һәм мөһим проектлар арасында Иннополисның күп кенә объектлары, Казандагы, Яшел Үзәндәге, Байлар Сабасындагы торак йортлар, паркинглар, «Бәләкәч» Президент программасы буенча төзелгән балалар бакчалары, спорт комплексларын реконструкцияләү һәм торак объектлары, авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать секторлары төзелеше бар. Боларның барысына да куәтле җитештерү потенциалы, заманча технологияләр һәм республика җитәкчелегенең һәм шәхсән Сезнең һөнәри ярдәмегез нәтиҗәсендә ирешелде. Хөрмәтле Ирек Әнвәрович, без республика халкы иминлеге хакына нәтиҗәле хезмәт итә алуыбыз өчен Сезгә нык рәхмәтле. Алга таба да хезмәттәшлегебез уңышлы дәвам итәр, дип ышанам.

Төзү – иҗат итү ул. Сезгә, хөрмәтле юбиляр, төзүче һәм архитектор һөнәренә әүвәлгечә тугрылыклы калуыгызны, ышанып тапшырылган секторның икътисадый үсеше дәвам итүен, кыю проектлар һәм ниятләрегезнең тормышка ашуын, куелган барлык максатларга ирешүегезне, күтәренке кәеф һәм яңа биеклекләр телибез! Сезнең максатчанлыгыгызны һәм күп мәсьәләләрне хәл итә белүегезне искә алып, алга таба да республикабыз өчен мөмкин булганның барысын да эшләячәгегезгә ышанам. Бу истәлекле көндә Сезгә ныклы сәламәтлек, бәхет, һөнәри эшчәнлегегезнең чәчәк атуын телим. Һәрвакыт уңыш юлдаш булсын, һәр көнегез иҗат һәм идеяләр белән тулып торсын, тәҗрибәгез озак еллар Татарстанның иминлеге өчен хезмәт итсен.

PRESSA.RU

Андрей Мочалов,
«Суварстроит» ҖЧҖ
генераль директоры

Яңа проектларга һәм идеяләргә!

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович! Һичшиксез, бу көнне хезмәттәшләрегездән, дусларыгыздан, республика халкыннан һәм җитәкчелегеннән бик күп матур сүзләр ишетерсез. Һәм Сез моңа бик тә лаек. «Суварстроит» ҖЧҖ коллективы төзүчеләре соңгы елларда Татарстанның төзелеш һәм архитектура үсешендәге уңай тенденцияләр Сезнең исем белән дә бәйле икәнен ышанычлы итеп әйтә алалар. Бу тармак актив рәвештә камилләшә бара. Гамәлдәге стильләрнең иң күркәм сыйфатлары заманча технологияләр белән бергә үрелә, һәм республиканың, һәм Казанның йөзе дә үзгәрә бара.

«Суварстроит» компаниясе – Татарстан Республикасындагы иң эре төзелеш компанияләренең берсе. Девелопер төп игътибарны арзан бәягә, табигый ландшафтны саклауда чагыла торган уңайлы инфраструктура һәм экологиягә, яңа ял итү зоналарына юнәлтеп, теләсә нинди катлаулы проектларны тормышка ашыра. Республикада торак төзелеше темплары буенча әйдәп баручыларның берсе буларак, барлык объектларны компания алдан расланган срокта төзеп бетерә һәм файдалануга тапшыра. Проектларда фатирларны эргономик планлаштыру, уңайлы транспорт чишелешләре һәм тапшырылган, шулай ук төзелеп ятучы бакчалар белән мәктәпләр рәвешендәге социаль инфраструктура каралган. Уртача алганда, торак комплекслардагы фатирларның 80%ы бүген тапшырылуга кадәр төзелеш стадиясендә сатыла. «Суварстроит» үз акчаларын гына файдалана, һәм бу төзелештә өлешләп катнашучыларны өстәмә гарантия белән тәэмин итә. Бүген компаниянең Россия һәм республика әйдәүче банкларының аккредитацияләре бар, шулай ук ул дәүләт «Төзелеш үсеше фонды» һәм «Ипотека буенча торак кредитлаштыру агентлыгы» белән хезмәттәшлек итә.

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович! Юбилей – Сезгә рәхмәтебезне һәм хөрмәтебезне белдерергә менә дигән сәбәп. Зур белемегез һәм һөнәрилегез нәтиҗәсендә алга таба да Татарстан халкы файдасына алдыгызда торган җаваплы һәм зур мәсьәләләрне уңышлы хәл итәчәгегезгә тирән ышанам. «Суварстроит» Сезгә күңел күтәренкелеге, яңа идеяләр һәм проектлар, эшлекле абруегызның тагын да ныгуын тели.

Үзегезгә һәм гаиләгезгә иминлек юлдаш булсын!

Реклама

Фотолар «Суварстроит» ҖЧҖнең рәсми сайтыннан (suvarstroit.ru).



Леонид Анисимов,
«Грань» ҖЧҖ төзелеш компаниясенең генераль директоры

Тармак тарихын үз кулларыгыз белән язасыз

«Грань» төзелеш компаниясе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне күренекле вакыйга – юбилей көнегез белән тәбрик итәм!

Хезмәт юлыгыз – әзлекле рәвештә төзелеш тармагының үзенчәлекләрен һәм идарә итү законнарын өйрәнә барып, гади хезмәткәрдән иң югары звено җитәкчелегенә кадәр күтәрелүегез.

Озак еллар дәвамында Сез республикабызның төзелеш комплексы файдасына хезмәт итәсез: төзелешнең өзлексез үсеше өчен кирәкле шартлар тудыру юнәлешендә эшлисез, тармак традицияләрен кадерләп саклыйсыз. Татарстан һәм Россия төзүчеләре Сезне сәләтле җитәкче, тотрыклы позицияләргә һәм принципларга таянып эшләүче, сайлаган һөнәренә тугрылыклы кеше буларак белә.

Бүгенге көндә Татарстан Россиянең төзелеш тармагы үсеше темплары буенча алдынгы төбәкләрнең берсе булып тора. Хезмәтегез белән Сез тармакның тарихын язасыз: Универсиада объектлары торгызылды, яңа сәнәгать җитештерүләре сафка басты, тормыш өчен әһәмиятле объектлар, торак-микрорайоннар төзелде, архитектура һәйкәлләре кабат торгызылды.

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович, Сезгә чын күңелдән җаваплы эшегездә уңышлар телибез, күтәренке күңел белән яшәргә, билгеләнгән проектларыгызны тормышка ашырырга насыйп булсын. Иминлек һәрвакыт тугрылыклы юлдашыгыз булып калсын!

Юлия Халитова,
«Инженерлык-төзелеш эзләнүләре» ҖЧҖ генераль директоры

Йортларыбыз – уңайлы, шәһәрләребез матур булсын өчен…

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович, «Инженерлык-төзелеш эзләнүләре» ҖЧҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән 55 яшьлек юбилеегыз белән тәбрикләргә һәм бу матур көннең Сезгә яхшы кәеф һәм матур хисләр генә алып килүен теләргә рөхсәт итегез! Республиканың төзелеш һәм архитектура тармагы үсешендәге, яңа биналар һәм корылмалар төзелешендәге, тарихи объектларны саклау һәм кабаттан торгызудагы уңышларны без Сезнең ару-талуны белмәс һөнәри эшчәнлегегез белән бәйлибез.

Югары квалификацияле белгечләргә ия булган предприятиебез бүген шактый гына инженерлык эзләнүләре (геологик, геотехник, геодезик, экологик, гидрометеорологик) уздыра. Эшләребезнең югары сыйфатлы булуы инженерлык-геологик эзләнүләр өлкәсендәге күпьеллык тәҗрибә һәм иң заманча җиһазлар булу белән гарантияләнә. Бораулау һәм тәҗрибә ясау җайланмалары паркы, кирәкле җиһазлар һәм лаборатория комплексы булу барлык эшләрне үзебезнең җитештерү куәтләре белән башкарырга мөмкинлек бирә. Без күп кенә төзүче-заказчыларның ышанычын акладык һәм абруй казандык. Партнерларыбыз арасында «Казан Гипронииавиапромы» АҖ, «КамТИСИз» ААҖ, «Казметстрой» ААҖ, «Леруа Мерлен» ҖЧҖ» «НефтегазИНЖИНИРИНГ» ҖЧҖ, «Грань» ҖЧҖ, «Сувар-Девелопмент» ҖЧҖ һ.б. бар. Эшебезнең төзелеш тармагы, республикабыз халкы өчен никадәр әһәмиятле икәнен аңлаган хәлдә, аны һәрвакыт вакытында һәм сыйфатлы итеп башкарабыз. Предприятиенең эшләү дәверендә заказчыларның бер тапкыр да канәгатьсезлек белдергәнен ишеткәнебез булмады.

Дөньяда, Россиядә, республикабызда нинди генә хәлләр булса да, йортларның җирдә нык торулары, аларда рәхәт һәм җылы, ә шәһәрләрнең һәмбистәләрнең матур һәм уңайлы булулары әһәмиятле. Сезгә карап, Ирек Әнвәрович, болар өчен мөмкин булганның бөтенесен дә эшләргә әзер икәнлегегезне күрәбез. Ихлас күңелдән тормышыгызның әлеге һәм алдагы көннәрендә дә дәрт-дәрман тоеп эшләвегезне телибез!

Реклама

Вячеслав Богданов,
«Ремстройсервис» ҖЧҖ һәм «Бастион» ҖЧҖ директоры

Безнең һөнәр – иң яхшысы

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович, Сезне 55 яшьлек юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез! Төзелеш һәм архитектура өлкәсендәге күпкырлы эшчәнлегегез, күпьеллык эш тәҗрибәгез белән Сез эшчәнлекләрен республика территориясендә алып баручы хезмәттәшләрегез һәм предприятиеләр арасында хөрмәт казандыгыз. Бу Татарстан төзелеш комплексының позицияләре көчле һәм киләчәге зур дигәнне аңлата.

Төзүчеләр Сезне тәҗрибәле профессионал гына түгел, башлыча алга куелган мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм күтәргә мөмкин булган лидер итеп тә күрә.

«Ремстройсервис» ҖЧҖ һәм «Бастион» ҖЧҖ төзелеш компанияләре тарафыннан Яшел Үзәндә яшәүче бәхетлеләргә мең квадрат метрлы торак йортлар проектланды һәм төзеп тапшырылды. Компания төзүчеләренең эшенә йөзләрчә гаилә бәя бирде. Һәм безнең заказлар туктаусыз төрләнә бара. Ә хәйрия проектлары безнең өчен аеруча кыйммәткә ия. Бу – тарихи мирас һәйкәлләрен торгызу һәм реставрацияләү, шулай ук республикада яңа социаль һәм культура объектлары төзү.

Компания хезмәткәрләре Раифа монастыре территориясен яхшырту эшендә дә актив катнашты, биредә алар кулы белән музей-тыюлык төзелде. Яшел Үзәннең Гоголь урамында мәчет төзергә дә ярдәм иттеләр алар. Кан юлларын дәвалау буенча яңа шифаханә шәһәрчеге, Раифада ябык типтагы махсус училищеда тәрбияләнүчеләр өчен спортзал, Свияжск утраушәһәренең бөтен буе тирәли декоратив койма... Йөрәгең аша үткәреп кенә тормышка ашырырга мөмкин булган мондый проектлар һәм объектлар безнең компания исәбендә бер генә дистә түгел. Шулай да иң күркәм, кызыклы һәм катлаулы объектларның берсе – Яшел Үзәннән ерак түгел урнашкан Романов күпере өстендәге 1913 елда төзелә башлаган часовня торгызылуын төгәлләү булды. Хәзер ул Яшел Үзәннең чын символы булып тора.

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович, мондый проектларны тормышка ашыру Сезнең тарафтан һәрвакыт хуплау тапты. Бу бик күңелле хәл, күп нәрсә турында сөйли торган күренеш. Иң мөһиме – Сез белемнәрегезне менә дигән итеп куллана беләсез һәм көчегезне республика бәхете хакына тулы куәтенә файдаланасыз.

Төзелеш һәм архитектура өлкәсендәге иҗади эшләргә алга таба да позитив карашыгызны саклап калачагыгызда шикләнмим.

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович, безнең төзүчеләр коллективы Сезгә чын күңелдән сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс энергия һәм киләчәктә дә тармак алдындагы мәсьәләләрне уңышлы хәл итүегезне тели. Безнең һөнәребез уртак – төзүче. Һәм ул – җирдәге һөнәрләр арасында иң яхшыларның берсе.

Реклама

Марат Нуриев,
«Уютный дом» ИК ҖЧҖ
генераль директоры

Үз җирендә кирәкле булу

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович, «Уютный дом» Идарә компаниясе коллективы һәм үз исемемнән 55 яшьлек юбилеегыз уңае белән иң җылы һәм ихлас тәбрикләүләребезне кабул итегез! Бу көнне Сез тулы көч, энергия белән Татарстанның төзелеш һәм архитектура эшендәге иң зур һәм кыю проектларны тормышка ашырып каршы аласыз. Хезмәт эшчәнлегегез республикабыз белән турыдан-туры бәйләнгән, һәм Сезне, һич арттыруларсыз, чын патриот дип атарга була.

Эшегезнең төп мәгънәсе – Татарстан Республикасы кешеләренең тормыш сыйфатын үзгәртү. Сез җитәкли торган министрлыкның уңышлы тормышка ашырылып килүче барлык программалары шуңа юнәлтелгән. Татарстан төзелеш комплексының бүгенге көндә тармак үсешенең төп күрсәткечләре буенча Идел буе төбәкләре арасында алда баруны дәвам итүе шуны раслый. Республика – илнең торак йортлар төзү буенча күләмен арттыручы сирәк субъектларының берсе.

Соңгы елларда Татарстан территориясендә төзек урамнар, парклар, скверлар торган саен күбәя, шәһәрләр һәм бистәләр матуррак һәм яшәү өчен уңайлырак була бара. Безнең 162 мең кеше яши торган 552 торак йортка хезмәт күрсәтүче компания шулай ук территорияләрне төзекләндерү (балалар һәм спорт мәйданчыклары) һәм энергия саклау буенча актив эш алып бара.

2006 елда төзелгән компания – Татарстанда гына түгел, бөтен Россиядә беренчеләр рәтендә – ул хәзер унъеллык чиген узып китте. Аның эшчәнлеге инновацион технологияләр үрнәге, Татарстанда һәм Россиядә торак-коммуналь хуҗалыгы үсешенең заманча этабында барлыкка килгән күп кенә идеяләрне тормышка ашыру мәйданчыгы булды. Төзекләндерү, ТКХ сферасындагы һәм энергонәтиҗәлелек өлкәсендәге иң яхшы предприятиеләр буенча Бөтенроссия конкурсларында алган югары дәрәҗәдәге дипломнар шуны раслый.

Үзенең җитештерү базасы, махсус техника паркы, торак-коммуналь хезмәт күрсәтүнең Россиядә тиңе булмаган күпфункцияле үзәге, ТКХның укыту үзәге – болар барысы да компаниягә югары конкурентлылыкка сәләтле заманча предприятие булырга мөмкинлек бирә. Болар барысы да – республиканың төп министрлыкларының берсе – Сез җитәкли торган министрлыкның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге төптән уйланган һәм исәпләнгән сәясәте нәтиҗәсе.

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович! Сезнең нәтиҗәле һәм зирәк җитәкчелегегез ярдәмендә республиканың төзелеш тармагы лаеклы рәвештә үсешен дәвам итә. Профессиональ кадрлар белән тулылана барып, ул үз аякларында нык басып тора. Үз җирендә кирәкле кеше булу, аның үсеше һәм чәчәк атуы өчен күп нәрсә эшләү – ир кеше өчен шуннан да яхшырак нәрсә булырга мөмкин? Бәйрәмегез көнендә Сезгә эшегездә уңышлар, сәламәтлек һәм күтәренке кәеф теләргә рөхсәт итегез!

PRESSA.RU

Андрей Симаков,
Татарстан Республикасы Ипотека буенча торак кредитлаштыру агентлыгы генераль директоры

Вакыт белән бергә атлап

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович! Татарстан Республикасы Ипотека буенча торак кредитлаштыру агентлыгы һәм үз исемемнән юбилеегыз белән котлауларыбызны кабул итегез!

Сезгә олы хөрмәтебезне белдерү өчен менә дигән мөмкинчелек чыгуга без бик шатбыз, чөнки озак еллар дәвамында Сез җитәкчелек иткән тармакның үсеше хакына бергәләп хезмәт итәбез, һәм торак йортларның сыйфаты яхшыра һәм арзанрак була баруына, инновацион технологияләр кертелүенә, регионның зур Россия проектлары өчен мәйдан булачагына ышанабыз. Татарстанның төзелеш өлкәсендәге уңышын күпчелек очракта Сез җитәкләгән команданың җайга салынган эше һәм үзегезнең шәхси сыйфатларыгыз – новаторлык агымын тоя, инициатива күрсәтә һәм вакыт белән бергә атлый белүегез тәэмин итә.

Зирәк акыл һәм югары профессиональлек белән баетылган белемегез һәм тәҗрибәгез, тапшырылган эшкә җаваплы караш, хезмәт сөючәнлек һәм катлаулы мәсьәләләрне хәл итә белү, намус һәм әдәплелек – боларның һәммәсен дә хезмәттәшләрегез белән бик юмарт бүлешәсез һәм аларны алга таба үсешкә рухландырасыз.

Без киләчәктә дә нәтиҗәле хезмәттәшлек итәрбез, дип ышанабыз. Сезгә һәм коллективыгызга тотрыклы үсеш, катлаулы дәүләт мәсьәләләрен хәл итүдә иҗади һәм үзенчәлекле карарлар кабул итүегезне телибез. Һәр көн хезмәт шатлыгы, идеяләрнең тормышка ашуына куаныч, фикердәшләр – хезмәттәшләрегез, дусларыгыз һәм якыннарыгыз белән аралашу бәрәкәте алып килсен!

Юрий Егорушкин,
«Татарстан махсус фәнни-реставрацияләү идарәсе» АҖ генераль директоры

Тарихи мирасны киләчәк буыннар өчен саклаганда

Хөрмәтле Ирек Әнвәрович, юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларыбызны һәм иң яхшы теләкләребезне кабул итегез!

Сезнең бөтен тормышыгыз төзелеш тармагы белән бәйле, вакыйгаларга бай хезмәт юлыгыз үз эшенә лаеклы хезмәт итү һәм чын профессиональлек үрнәге булып тора. Бүген Сезнең җитәкчелектә республиканың күп кенә проектларын тормышка ашыру ышанычлы рәвештә алга бара. Сездә теләсә кайсы проблеманың асылына бик тиз төшенә белү, эчкерсезлек һәм җылылык кебек сыйфатлар үзара нык бәйләнгән.

Безнең профессиональ берләшмә өчен «иҗат итү һәм төзелеш» сүзләре турыдан-туры мәгънәгә ия. Чөнки нәкъ менә тикшеренүчеләр яки белгечләр, архитекторлар, проектчылар, төзүчеләр, реставраторлар, инженерлар көче белән уңайлы яшәү шартлары барлыкка килә, республиканың йөзе үзгәрә, аның киләчәге төзелә.

Татарстан – башкаласы Казанның үзе кебек үк бик бай тарихлы республика. Биредә тарихи һәм мәдәни әһәмияткә ия гаять күп объектлар бар. Безнең предприятие, Татарстанның тарихи биналарны реставрацияләү белән шөгыльләнүче иң эре компанияләренең берсе буларак, 70 елга якын тарихы эчендә шундый 100дән артык объектны реставрацияләде. Алар арасында – Казан Кремле, Болгар һәм Свияжск, шагыйрь Евгений Боратынский йорты, «Казан» кунакханәсе... Безгә ерак үткәннән калган һәм кабатланмас бизәлешле объектларны саклап калу бик мөһим. Моның киләчәк буыннар өчен дә никадәр әһәмиятле икәнлеген яхшы аңлыйбыз. Шуңа күрә безнең реставраторлар, архитекторлар, белгечләр һәм инженерларны уникаль осталар дип исәпләргә була.

ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры, ТРның баш архитекторы буларак, Сезнең, Ирек Әнвәрович, моны тулысынча аңлап эш итүегез һәм предприятиегә зур ярдәм күрсәтүегез гаять күңелле күренеш.

Хезмәттәшләрем һәм шәхсән үзем Сезгә һәм якыннарыгызга чын күңелдән ныклы сәламәтлек, барлык планнарыгызның, яңа, мөһим һәм кызыклы проектларыгызның тормышка ашуын телибез!

Фото ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы сайтыннан

Николай Титов, ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары, декабрь аенда үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Стартегик яктан әһәмиятле мәсьәләләр

Вәгыйзь Минһаҗев,
«Россельхозцентр» ФДБУ филиалы җитәкчесе

Хөрмәтле Николай Леонидович!

Ир кеше өчен белемнәрен, күнекмәләрен һәм мөмкинлекләрен тулысынча тормышка ашырырга ярдәм итәрдәй яраткан эше белән шөгыльләнү мөһим. Сез республиканың авыл хуҗалыгы тармагында башкарган эш нәкъ менә шундыйлардан.

Бүген республикабызның агропромышленность комплексы Россия төбәкләре арасында әйдәп баручы позицияләрне били. Теләсә кайсы предприятиенең уңышы һәм үсеше үз һөнәренең остасы булган җаваплы һәм эшкә бирелгән кешеләр белән тәэмин ителә. Бу Сезгә тулысынча кагыла, Николай Леонидович.

Икътисадның агросәнәгать секторында эшләү елларында Сез хөрмәткә лаек шәхес булып өлгердегез һәм нык, эшлекле абруй казандыгыз. Республика файдасына хезмәт итү буенча бай тәҗрибә тупладыгыз, профессиональ коллективларны җитәкләү, социаль-икътисади мәсьәләләрне хәл итү, Татарстанда яшәүчеләрнең өстәлендә табигый җирле азык-төлек булуы турында кайгырту – болар барысы да Сезнең казанышларыгыз. Һәм бу әһәмиятле эштә хезмәттәшләрегез белән бергәләп хәл ителә торган азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре республика һәм аның халкы өчен стратегик әһәмияткә ия булып тора.

Юбилеегыз көнендә ихлас күңелдән ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, хезмәттәшләрегезнең ярдәмен тоеп яшәвегезне телим. Болар бит барысы да кешенең үсешен һәм алга барышын тәэмин итә. Иң изге теләкләр Сезгә, Хөрмәтле Николай Леонидович! Юбилеегыз котлы булсын!

Реклама 16+

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

instagram.com/protatarstan

PRESSA.RU

АЙ КӘЕФЕ: **БАЛЛАР**

БЕРЕНЧЕ БАЛ: **ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ КАЙТАРУ**

Золушканың туфлиен югалтып, принц табуы белән бәйле булган тарихтан гайре баллар турында без ниләр беләбез? Ә бит мондый бәйрәмнәрнең асылы безнең мәгълүмат белән шыплап тулган организмнарда генетик дәрәҗәдә сакланган. Әбиләребезнең әбиләре һәм бабайларыбызның бабайлары – ә бәлки әбиләре һәм бабайлары гынадыр – әдәбиятта тасвирланган данлыклы баллардагы кунакларның прообразлары булгандыр? Наташа Ростова белән аның беренче балында янәшә торганнардыр, Онегин белән «җиңел генә мазурка биегәннәрдер», Лермонтовның «Маскарад»ында, кыланчыкланып, йөзләрен маска астына яшергәннәрдер?..

«Хәзер баллар акварельләрдә генә калды», – дип авыр сулый хәтерләрендә әле дә полонез һәм катильон кайтавазларын саклаган әбиләребез... Шуңа күрә дә Пушкин балы – яшь лицеистларның быел беренче кар яуган көнгә туры килгән Казан ратушасындагы беренче балы – безгә бик кадерле. Оныклар һәрвакыт әбиләренә һәм бабаларына якынрак, алар берсүзсез мәңгелек вальсны да, раритетлы полонезны да, язмышларны билгеләүче мазурканы да бии ала, ә безнең хакта – баллар турында уйлап та карамаган, һәрчак эшкә ашыгучы урталыкта калган буын турында алай әйтеп булмый шул. Әгәр сезнең тормышыгызда шундый күңел кузгаткыч вакыйга – беренче бал булмаган икән, «Татарстан» сезгә аны күрсәтәчәк: карагыз да елмаегыз, яшь кызларның зифа буй-сыныннан һәм вальс әйләнүче егетләрнең оста па-хәрәкәтләреннән эстетик ләззәт алыгыз. Һәм, әлбәттә инде, балаларыгызда балларга мәхәббәт уятыгыз – бу безнең иң матур традиция – аны кире кайтарырга кирәк.

Фото: Ната Смирнова





Казанда Пушкин балы 15 нче тапкыр үтте. Анда Н.И. Лобачевский исемендәге Академик лицей укучылары катнашты. Быел бию кичәсе аерым үзенчәлеккә ия иде, чөнки 2017 елда А.С. Пушкинны искә алуның 180 еллыгы һәм Россиянең Царское Село лицеендагы беренче чыгарылышның 200 еллыгы билгеләп үтелә.
Пушкин балы традицион рәвештә Казан ратушасында уза һәм лицей тарафыннан Рус һәм Татар дворян җыелышлары белән берлектә оештырыла.

PRESSA.RU

АЛЕКСАНДРИЙСКИЕ
ДВЕРИ
г. Казань
ул. Карла Маркса, 3
тел: 8 (843) 292-89-89
8 (843) 292-06-76
ул. Достоевского, 50
тел: 8 (987) 225-69-69
ТЦ "Савиново",
Проспект Ямашева, 93
тел: 8 (843) 527-04-96
www.aldoor.ru
Реклама